# «МӘКТӘП СӘХНӘСЕ»

## РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ПЬЕСАЛАР ҺӘМ ТЕМАТИК СЦЕНАРИЙЛАР ҖЫЕНТЫГЫ

Казан – 2018

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы «Салават күпере» һәм «Сәхнә» журналлары редакциясе

# «МӘКТӘП СӘХНӘСЕ»
# РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ПЬЕСАЛАР ҺӘМ ТЕМАТИК СЦЕНАРИЙЛАР БӘЙГЕСЕ
# (АЛЬМАНАХ)

Казан – 2018

Ред. коллегия:
З.З.Хөснетдинов, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, язучы, «Сәхнә» һәм «Салават күпере» журналлары җитәкчесе-баш мөхәррире
Н.Ф.Насыйбуллина баш мөхәррир

**«Мәктәп сәхнәсе» республикакүләм пьесалар һәм тематик сценарийлар бәйгесе: альманах. – Казан: издательство, 2018. – 150**

Җыентыкта «2014-2020 елларга каралган Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында уздырылган «Мәктәп сәхнәсе» республикакүләм пьесалар һәм тематик сценарийлар бәйгесенең иң яхшы эшләре тупланып бирелде. Җыентыкта урын алган пьеса һәм тематик сценарийлар урта гомуми белем бирү оешмалары укытучыларына тәкъдим ителә.

**Эчтәлек**

1. Закирова Кафия Вәли кызы
«Үрдәк беренчелекне алган» ........ 5
2. Зыятов Айрат Фәрхат улы
«Гөлкәй мажаралары» ........ 9
3. Мостафина Нәзилә Камил кызы
«Театрның югалмас атасы» ........ 17
4. Җәләева Гөлфия Рифгать кызы
«Могҗизалар төне» ........ 25
5. Җамалдинова Лилия Рифкать кызы
«Буа-Алан мажаралары» ........ 33
6. Тарханова Гүзәлия Инсаф кызы
«Хан кызы» ........ 37
7. Зарипова Рәмилә Рәвил кызы
«Аулак өй» ........ 48
8. Ибатуллина Фәния Сәгъдулла кызы
«Каз өмәсе» ........ 54
9. Степанова Рәйхана Сахап кызы
«Керән базары» ........ 60
10. Гыйниятуллина Нәзилә Николай кызы
«Нардуган бәйрәме» ........ 66
11. Шәйдуллина Розалия Нургали кызы
«Орчык өмәсе бәйрәме сценарие» ........ 72
12. Зарипова Алина Павел кызы
«Ничек без Сөмбеләне эзләдек…» ........ 79
13. Миназова Эльвира Мәсхүт кызы
«Бездә бүген Сабантуй» ........ 84
14. Төхфәтулова Хәлимә Хәким кызы
«Ил язмышы - ирләр кулында!» ........ 89
15. Фирдәвес Әһлия
«Туган тел ачкычы» ........ 96
16. Закирова Гөлнара Шамил кызы
«Яңа ел мажарасы» ........ 99
17. Хәсәнова Ралия Ринат кызы
«Чын дуслык» ........ 105

Редакторы: Насыйбуллина Фәнзилә Габбаз кызы

| | |
|---|---|
| 1. Закирова Кафия Вәли кызы | “Үрдәк беренчелекне алган” |
| 2. Зыятов Айрат Фәрхат улы | “Гөлкәй маҗаралары” |
| 3. Мостафина Нәзилә Камил кызы | “Театрның югалмас атасы” |
| 4. Җәләева Гөлфия Рифгать кызы | “Могҗизалар төне” |
| 5. Җамалдинова Лилия Рифкать кызы | “Буа-Алан маҗаралары” |
| 6. Тарханова Гүзәлия Инсаф кызы | “Хан кызы” |
| 7. Зарипова Рәмилә Рәвил кызы | “Аулак өй” |
| 8. Ибатуллина Фәния Сәгъдулла кызы | “Каз өмәсе” |
| 9. Степанова Рәйхана Сахап кызы | “Керән базары” |
| 10. Гыйниятуллина Нәзилә Николай кызы | “Нардуган бәйрәме” |
| 11. Шәйдуллина Розалия Нургали кызы | “Орчык өмәсе бәйрәме сценарие” |
| 12. Зарипова Алина Павел кызы | “Ничек без Сөмбеләне эзләдек…” |
| 13. Миназова Эльвира Мәсхүт кызы | “Бездә бүген Сабантуй" |
| 14. Төхфәтулова Хәлимә Хәким кызы | “Ил язмышы - ирләр кулында!” |
| 15. Фирдәвес Әһлия | “Туган тел ачкычы” |
| 16. Закирова Гөлнара Шамил кызы | “Яңа ел маҗарасы” |
| 17. Хәсәнова Ралия Ринат кызы | “Чын дуслык” |
| 18. Мөхәмәтшина Эльмира Госман кызы | “Малай һәм кояш” |
| 19. Чирикова Эльвира Илһам кызы | “Сугыш авазы” |
| Ногманова Фирдәүсә Минап кызы | |
| Гәлиева Нурания Раил кызы | |
| Маштакова Александра Михайловна | |
| 20. Шәйхулова Гөлназ Фаяз кызы | “Туфан васыятьләрен үтәрбез” |
| 21. Вәлиуллина Зөһрә Энгел кызы | “Карурман хикмәтләре” |
| 22. Садыйкова Миләүшә Сәлих кызы | “Бездә бүген Нардуган” |
| 23. Кашапова Гөлүсә Вәсил кызы | “Кызыл алмалар” |
| 24. Гаффарова Зөлфия Рәфис кызы | “Әбиләрдә кунакта!” |
| 25. Мурзина Лилия Миннәхмәт кызы | “Сөрән - сабантуйга чакыру” |
| 26. Насибуллина Миляуша Рәүф кызы | “Кирлемән маҗаралары” |

***Закирова Кафия Вәли кызы***
*Татарстан Республикасы,*
*Казан шәһәренең 415нче балалар бакчасы методисты*

**“Үрдәк беренчелекне алган”**

**Катнашалар:** *Әтәч, Үрдәк, Тавык, Чебиләр, Кәҗә, Сыер, Акбай, Аю, Төлке, Тиен.*
*Матур кояшлы иртә. Койма белән әйләндереп алынган ишегалды. Арткы планда – авыл өе. Бер читтә бүрәнә ята. Икенче якта өстәл, эскәмия куелган. Уртада – агач тагарак. Читтәрәк, койманың алгы ягында – “күл”.*
*Горур кыяфәт белән, эре-эре атлап, сәхнәгә Әтәч чыга. Ул, җырлый-җырлый, ишегалды уртасына таба үтә.*

**Әтәч:**(*җырлый) Кикри-күк! Кикри-күк!*
*Мин уяндым бик иртүк.*
*Яңа хәбәр ишеттем,*
*Шуны әйтергә килдем.*

*Ишегалдына, кабалана-кабалана, алпан-тилпән атлап, Үрдәк керә.*

**Үрдәк***:* *Бак-бак-бак! Бак-бак-бак!*
*Килдем бик тиз атлап.*
*Шатлыклымы хәбәрең?*
*Шуны белергә килдем.*

**Әтәч:** Әйе, дускаем, күңелле хәбәр!

**Үрдәк:** Әйдә инде, әйт, тизрәк!!!

**Әтәч:** (*үрдәк янына ук килеп*) Ишетмәдеңмени? Иртәгә йорт хайваннары һәм кошлары өчен бәйге оештырыла, ди. Бәйгедә һәркем үз һөнәрен күрсәтергә тиеш.

**Үрдәк:**(*гаҗәпләнеп)* Кит аннан?! Менә шәп булган! Ә бәйгедә җиңүчеләргә бүләк булачакмы икән?

**Әтәч:** Әлбәттә, булачак! Кем үзенең һөнәрен яхшы күрсәтә, шул бүләк алачак.

*Ишегалдына, җырлый-җырлый, Тавык чыга. Ул як-ягына карана, чебиләрен эзли.*

**Тавык:** *Чеп-чеп-чебиләрем,*
*Чеп-чеп-чеп-чеп-чебиләрем,*
*Йомры йомшак йомгакларым,*
*Кайда соң сез, елакларым?*

*Сәхнәгә, бер-бер артлы тезелеп, йөгерә-йөгерә, Чебиләр керәләр. Җиңелчә музыка астында бию башкаралар. Бу вакытта Әтәч белән Үрдәк, Тавык бүрәнәгә барып утыралар, биюне күзәтәләр.*

**Тавык:** (*урыныннан торып, чебиләре янына килә*) И-и-и, менә бит минем нәниләрем, сары матур чебиләрем! Килегез, кил яныма, җим сибәм үзегезгә!

*Чебиләр әниләре янына йөгереп киләләр, барысы бергә кочаклашалар да, уң кулларын берсе өстенә берсен куеп, “Без-без-без идек” уенын уйныйлар.*

*Без-без-без идек,*
*Берничә чеби идек.*
*Тәмле итеп җим ашадык,*
*Тагарактан су эчтек,*
*Төрле якка сибелдек.*

*Сәхнәдән йөгереп чыгып китәләр.*

**Әтәч:** (*бүрәнәдән төшә, Тавык янына килә*) Хәләлем, син ишеттеңме әле, иртәгә йорт хайваннары һәм кошлары өчен бәйге оештырыла. Бәйгедә син дә катнаша аласың.

**Тавык:** Менә яхшы булган. Әлбәттә, катнашам!

**Үрдәк:** (*бүрәнәдән төшә*) Дусларым, әйдәгез, булачак бәйге турында башкаларга да хәбәр итик. Әзерләнергә бик аз вакыт калган бит.

*Тавык, Әтәч, Үрдәк сәхнәнең өч ягына китәләр, кулларын авыз турысына куеп, берсе артыннан берсе кычкыралар:*

*Эһе-һе-һей! Хөрмәтле дусларыбыз!*
*Тизрәк бире килегез!*
*Яңа хәбәр ишетегез!*

*Сәхнәгә, шаулаша-шаулаша, Кәҗә, Сыер керәләр, җырлыйлар.*

*Исәнмесез-саумысез,*
*Нигә кәҗә саумыйсыз?*
*Сыерыгыз каймак бирә -*
*Нигә чыгып алмыйсыз?*

**Кәҗә, Сыер:** (*бергә*) Сәлам бирдек дусларга!

**Әтәч , Тавык, Үрдәк:** (*бергә)* Алдык - кесәгә салдык.

**Кәҗә:** Безне нигә чакырдыгыз? Мә-ә-ә-ә!

**Сыер:** Нинди хәбәрегез бар? Тизрәк беләсе килә! Му-у-у-у!

**Әтәч:** Ишетмәгәнсездер әле, иртәгә зур бәйге уздырылачак!

**Тавык:**Бәйгедә теләгән һәркем катнаша ала.

**Үрдәк:** Һәркем үз һөнәрен күрсәтергә тиеш.

**Сыер:** (*уйланып)* Алай икән.... уйлап карыйсы булыр...

**Кәҗә:** Уйлап торасы юк. Менә мин җырлап күрсәтәчәкмен! Туйдым инде мээлдәп йөреп...

**Сыер:** Алайса, мин дә синнән калышмыйм. Му-му дип кычкырып йөреп, мин дә ардым. Йөгерү ярышында катнашырмын! Беренчелекне берәүгә дә бирмәм!

**Тавык:**Мин гел җырлап йөрим, бу юлы биеп күрсәтергә кирәк!

**Әтәч:** Ә мин... мин йөзәчәкмен. Минем йөзгәнне күреп, бөтенесе хәйран калыр.

**Үрдәк:** (*тыйнак кына*) Мин белмәгән эшкә тыгылмыйм. Сәхнәгә чыгам да, бак-бак итеп бакылдап күрсәтәм.

*Йорт кошлары, Сыер белән Кәҗә бүрәнәгә барып утыралар. Сәхнәгә күңелле музыка астында һәйәт әгъзалары - күзлек кигән Аю, кулларына кәгазь, ручка тоткан Төлке белән Тиен, Акбай керәләр. Тезелеп басалар.*

**Аю:***Мин - комиссия башлыгы,*
*Күзлегемне кидем мин.*
*Дусларымның һөнәрләрен*

*Бәяләргә килдем мин (өстәл артына барып утыра*).

**Төлке:**(*көязләнеп) Ярышларны күзәтергә*

*Мин дә килдем, күрегез.*

*Бәяләрбез һөнәрләрне*

*Бер хәйләсез, белегез* (*өстәл артына утыра*)!

**Тиен:***Мин дә килдем, чөнки беләм:*

*Мондый бәйгеләр сирәк.*

*Ярыш нәтиҗәләрен, тырышып,*

*Язып барырга кирәк (өстәл артына утыра*).

**Акбай:** *Утырышып бетсәгез,*

*Ярышларны башлыйбыз.*

*Иң беренче Кәҗә җырын*

*Әйдә, тыңлап карыйк без.*

**Кәҗә:**(*кычкырып җырлый*)

*Бар матур бакча,*

*Анда кәбестә үсә.*

*Менә шундый ул бик зур,*

*Менә шундый кечкенә! (реверанс ясый, баш ия.*)

*Җыр барышында комиссия әгъзалары колакларын каплыйлар, канәгатьсезлекләрен белдерәләр.*

**Акбай:***Чират җитте Сыерга. Ул да*

*"Му-у!"- дип кычкырмый бүген,*

*Ул бүген – йөгерә!*

Әйдәгез, бергәләп саныйк: *(комиссия әгъзалары бергә саныйлар)*

Бер, ике, өч! Башладык!

*Сыер йөгерә башлый, әмма абынып егыла.*

*Комиссия әгъзалары, гаҗәпләнеп, башларын тоталар.*

**Акбай:***Хәзер җырласын Тавык,*

*Тормасын ул мактанып*.

**Тавык:**(*кулында яулык*) *Мин дә кытакламыйм бүген,*

*Минем биисем килә!*

**Аю, Тиен, Төлке**:(*бергә) Әйдә, рәхим ит! Биюеңне*

*Бик тә күрәсе килә!*

*Бию көе яңгырый. Тавык бии башлый, әмма чалыш атлап, мәтәлеп китә.*

**Акбай:***Сүз бирелә Әтәчкә!*

*Матур "Кикри-күк" җырын*

*Һәркем көтә Әтәчтән!*

**Әтәч:***Барыгыз да шаккатырсыз,*

*Әгәр йөзеп күрсәтсәм.*

*Мин бүген кычкырмыйм әле,*

*Бүген йөзеп күрсәтәм!*

*Әтәч "күл" янына килә, "су"га керә, йөзеп китмәкче була, әмма бата башлый. Барлык хайваннар, йөгереп килеп, аны судан тартып чыгаралар.*

**Акбай:***Сүзне, Үрдәк, сиңа бирик,*
*Синең дә һөнәреңне күрик.*
**Үрдәк:***"Белмәгән эшкә тыгылма",*
*Дигән безнең халкыбыз.*
*Мин артыгын кыланмыйм,*
*Белгән эшемне эшлим.*
*Үз телемдә матур итеп*
*Рәхәтләнеп бакылдыйм:*
*Бак-бак! Бак-бак! Бак-бак!*

*Барысы да, гөр килеп, Үрдәккә кул чабалар. Үз телендә матур итеп сөйләгәне өчен, аңа сулы ләгән бүләк итәләр.*

**Аю:***(урыныннан торып)* Үрдәк туган, син бик матур итеп үз телеңдә сөйләдең. Телеңне яратканың, зурлаганың өчен без сиңа бәйгенең иң зур бүләген тапшырабыз. Рәхим итеп ал, туганкай! Юкка гына халкыбыз "Теле барның юлы бар" димәгән. Синең киләчәгең якты, өметле!

**Тиен:**(*җиңелүчеләргә карап*) Һәрчак шуны исегездә тотыгыз: белми эшләнгән эш – пешми калган җимеш ул!

**Төлке:**Сүзең белән мактанма – эшең белән мактан!

**Акбай:**Тыйнаклык һәркемне бизи!

*Кәҗә, Сыер, Әтәч, Тавык башларын, оялып, аска иyләр.*

*Тәмам.*

***Зыятов Айрат Фәрхат улы***
*Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы Өчиле төп гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## "Гөлкәй маҗаралары"

**Катнашалар:** *Гөлкәй, Үги әни, 1нче кыз, 2нче кыз, Патша, Принц, Вәзирләр, Алиһә.*

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

**Гөлкәй:**
(*моңлана*) *Үз әнием исән чакта*
*Һич булмаган икән кайгым;*
*Үги әни белән яшәп,*
*Эшли-эшли хәлдән тайдым.*
*Эштән курыкмыйм анысы,*
*Эшләп куанган көнем.*
*Сагынам шул әниемне,*
*Елап уза һәр төнем.*
**Үги әнисе:**
(*кырә*) *Сиңа әйтәм, әй, дим, кара,*
*Табак-савыт юарсың,*

*Үтүклә бу күлмәкләрне,*
*Шуннан токмач турарсың.*
*Ташыдыңмы су мунчага?*
*Утынны керт күп итеп,*
*Идәннәрне юып чыгар,*
*Бетергәнсең чүп итеп...*

*Үги әнисе чыга, кызлар керә.*

**1нче кыз:**
*(Гөлкәйгә көзгене биреп)*
*Гөлкәй, минем көзгене дә*
*Чистартырсың бүген, мә!*
*Әйбәт булсын, тап калмасын,*
*Ялт-йолт итсен, иренмә!*

**2нче кыз:**
*(мыскыллап карап)*
*Нинди Гөлкәй булсын, Көлкәй!*
*Кара бер рәвешенә!*
*Ничек шулай киенәләр?!*
*Кара бу кәвешенә!*
*Аламаның аламасы,*
*Кара бу күлмәкләрен!*
*Ник сулган бүлмә гөлләрем?*
*Сусыз бит чүлмәкләрем!*
*Күлмәгемнең төймәләрен*
*Тагып куй бүген кичтән.*
*Бер вакыт юк, өлгерәлмим,*
*Вакыт җитешми һич тә!*
*Тау кадәрле эш өелгән,*
*Кайсын эшләп аласы?*
*Тырнак буя, керфек буя,*
*Озак йоклап, бу арада,*
*Кызарган күз алмасы!*

**1нче кыз:**
*(чәчләрен сыйпаштырып)*
*Синең әле ярый, апа,*
*Чәчләрең шома, калын.*
*Менә минем чәчне кара –*
*Бүген иртән буяганда*
*Салдым буяуның барын!*
*Прическа ясарсың да,*
*Көлкәй, бүген чәчемә,*
*Бигудилар беркетерсең –*
*Ату тагын чәнчелә!*

**Гөлкәй:**

*Яхшы, ярар, апаларым,*
*Бар да булыр сез дигәнчә!*
*Үтүкләрмен күлмәкне дә,*
*Сулармын бар чүлмәкне дә;*
*Көзгең дә ялт иткән булыр,*
*Җирләренә җиткән булыр.*
*Чәчләреңне көдрәләрбез,*
*Торыр алар бөдрәләнеп.*
*Тәмле булып пешәр аш та,*
*(Кайсын эшлим икән башта?!)*
*Борчылмагыз бер дә юкка,*
*Сездән гүзәл бүтән юк та!*
*Сез - иң матур, сез - иң булган,*
*Икегез бит сез бертуган!*

*Әниләре керә.*

**Үги әни:**

*Өелешеп ятасызмы?*
*Эшегезне эшләгез, бар!*
*Көлкәй, кара, ишегалдын*
*Сарып алган буранлы кар!*
*Кар көрәргә чыгарсың да,*
*Ялт иттер, бар, ишегалдын.*
*Бар, бар, әйдә тизрәк бул,*
*Алларыңнан матур артың...*

*Көлкәй чыга.*

*Ай, кызларым, йолдызларым,*
*Минем сылу кондызларым!*
*Чибәрдер шул, матурдыр шул,*
*Минем асыл йолдызларым!*
*Горурланам сезнең белән,*
*Көлкәй түгел берегез дә!*
*Кара бу зат киемнәрне!*
*Үстердем мин, күр, кемнәрне!*
*Тукта, нинди тавыш тышта?*
*Пар ат белән килделәрме?*
*Егетләр ул, кәгазь тотып,*
*Безнең өйгә керделәрме?*

*Вәзир керә.*

**Вәзир:**

*Эһем, эһем, әфәнделәр,*
*Ханымнар һәм туташлар!*
*Патшаның бу әмерен*

*Ишеттерәм мин тоташтан!*
*Патшабыз бал уздыра,*
*Барчагызга килү тиеш!*
*Шул бәйрәмдә яшь принц*
*Кәләш сайлап ала, имеш!*
*Иң чибәрләр, иң гүзәлләр*
*Чакырыла бу бәйрәмгә.*
*Иң сылулар, иң матурлар*
*Җыелсыннар бер бәйләмгә!*
*Кемгә насыйп булыр икән*
*Яры булу яшь егетнең?!*
*Мин бу көнне, бу фәрманны*
*Нәкъ унҗиде ел буе көттем.*
*Балда булу - һәрбер кызга*
*Беркетелә Указ белән!*
*Матур күлмәк тектерегез*
*Ательеда заказ белән!*
**1нче кыз:**
*(шатланып) Нинди бәхет! Мин дә барам,*
*Принцның хушын алам!*
*Мине сайлап алачак ул!*
*Миңа гашыйк булачак ул!*
**2нче кыз:**
*(мактанып) Нишләп сиңа?! Мин яш(е)рәк.*
*Синең әнә билең юан!*
*Коры куык! Бар, көзгеңә*
*Карап әнә, әйдә, куан!*
*Принцның кәләше – мин!*
*Бүтән һичкем булмаячак.*
*Ишелә ул күктән бәхет:*
*Мин ул –кәләш, мин ул – курчак!*
**Әниләре:**
*Кызый, Көлкәй, яхшы кара!*
*Без китәбез өчәү балга!*
*Бөтен йорт-җир, кызый, Көлкәй,*
*Ялтырасын фирүзәдәй.*
*Кара аны, йоклап ятма!*
*Эшнең барсын үтәп бетер!*
*Ә кызларым-кондызларым,*
*Үсеп җитте инде, шөкер!*
*Кайсын сайлап алыр икән*
*Яшь принц бу кызларның?*
*Икесе дә менә дигән,*

*Икесен дә алам, дисә,*
*Анысына да ризамын!*

*Китәләр.*

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

**Гөлкәй:**
*Бәхетлеләр апаларым,*
*Китте  бүген алар балга.*
*Ә мин менә кырык эшнең,*
*Кайсын куйыйм икән алга?*
*Үз әнием булса әгәр,*
*Назлар иде инде мине.*
*Тукта, башта күлмәгемнең*
*Тегеп куйыйм әле җиңен.*
*Тузган инде алъяпкычым,*
*Бары эш шул – юанычым.*
*Шатлыгым да эш, бары – эш,*
*Эш шул бары куанычым!*
*Дөньяның бер бәхетсезе*
*Булдым инде мин ятимә.*
*Зарларымны сөйли алмыйм,*
*Хәтта мескен әтиемә!*
*Мине соң шул кемнәр назлар?*
*Эштә үтә кышлар, язлар!*

*Кая миңа балга бару,*
*Сагышлардан тик эш – дару!*

*Алиһә керә.*

**Алиһә:**
*Күрәм, дустым, моңланасың,*
*Чыланганнар керфекләрең.*
*Балкып тора, янып тора*
*Әнә синең ал йөзләрең!*
*Күңелләрең саф шул синең,*
*Бер мәкер юк, бер кинә юк!*
*Апаларың – явызларга*
*Төртмә сүзле бер инәң юк!*
*Кушканнарның барысын да*
*Үтисең син ялт иттереп.*
*Телисеңме, сине дә мин*
*Илтәм балга ат җиктереп.*
*Тылсымлы бу таяк белән*
*Кабаклардан фәйтун ясыйм.*
*Тычканнан – ат, күсе – кучер,*

*Дугасына яңгырап торган*
*Пар кыңгырау, әйдә, асыйк!*
*Менә кара, рәсемдәге*
*Барысы да көтә сине.*
*Хәзер, кызым, дикъкать белән*
*Тыңла, зинһар, һәр сүземне.*
*Сәгатьләр нәкъ уникене*
*Суккан чакта – бар да бетә:*
*Фәйтун – кабак, атлар – тычкан,*
*Кучер булыр күсе, әлбәттә!*
*Соңга кала күрмә, берүк,*
*Хурлыкларга калмыйм, дисәң.*
*Синнән гүзәл бер кыз булмас,*
*Бу күлмәкне әгәр кисәң.*
*Туфлинең дә иң затлысын,*
*Сеңлем, сиңа бүләк итәм.*
*Онытa күрмә! Нәкъ – унике!*
*Инде бар, кит, мин дә китәм.*

ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

*Бал. Бииләр.*

**Вәзир:**
*Эһем, эһем, әй, җәмәгать!*
*Патшадан – мөрәҗәгать!*
*Бар да бии, бар да көлә,*
*Ә принц – үзе белә!*
*Сайлап алыр берегезне,*
*Әйттек, димәк, сүзебезне!*
*Иң матуры, иң чибәре,*
*Балыбызның иң гүзәле –*
*Принцка кәләш була.*
*Маэстро! Вальс уйна!*

*Бию башлана, ишектән Гөлкәй керә. Бар да туктап, “Ah” итәләр. Принц аның алдында тезләнә.*

**Принц:**
*Кем син, сылу?*
*Кем син, гүзәл?*
*Юк әйтергә һичбер сүзләр!*
*Телсез иттең,*
*Хушсыз иттең,*
*Әлҗе-мөлҗе килә күзләр!*
*Мөмкинме дим, сезнең белән*
*Бергә вальс әйләнергә?*
*Менә минем кәләш, әткәм,*

*Телим шуңа өйләнергә!*

*Патша Вәзиргә нидер әйтә.*

**Вәзир:**

*Атаң риза бу сайлауга,*
*Сезгә ул тик тели бәхет.*
*Үзе үлгәч, сиңа кала,*
*Бөтен байлык, ошбу тәхет!*
*Бүген – бәйрәм, бүген – бию,*
*Күңел ачыйк, әйдә бергә.*
*Куанычлар алып килсен,*
*Бүгенге көн, яшьләр, сезгә!*

*Бииләр.*

**Үги ана:**

*Нинди чибәр кыз бала бу?*
*Сәер, таныш чалымнары.*
*Кара әле, нинди матур*
*Озын кара толымнары!*
*Әй, кызларым, сезне хәзер*
*Бу шаһзадә инде күрмәс.*
*Өметләрем акланмады,*
*Гашыйк булды аны күргәч.*

**1нче кыз:**

*(әнисенә елышып) Әни, кара, бу күлмәкне*
*Ул соң кайдан алды икән?*

**2нче кыз:**

*(туфлисенә кызыгып) Аның кигән зат туфләсе*
*Минекенә ярар микән?*

*Курантлар суга башлагач, Гөлкәй "дерт" итеп китә. Залдан йөгереп чыкканда, бер туфлие төшеп кала. Принц аның артыннан йөгерә, туфлины кулына ала.*

**Принц:**

*Принцтан фәрман шулдыр -*
*Әй, Вәзирләр, ишетегез.*
*Бу туфлинең хуҗасын сез,*
*Табып кире китерегез!*
*Кереп-кереп, һәрбер өйгә,*
*Сез табыгыз аны эзләп.*
*Табып, монда илтүчегә –*
*Вәгъдә – иман! Бүләк – миннән!*

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

*Вәзир һәм сакчылар үги әнинең кызлары янына киләләр.*

**Вәзир:**

*Ягез әле, яле, кызлар,*
*Күрсәтегез киеп карап.*

*Сез түгелме серле ул кыз?*
*Бәлки туфли торыр ярап.*
**1нче кыз:**
*(туфлине вәзир кулыннан алып)*
*Яле, кая, үзем киим,*
*Мин яратам ул туфлине.*
*Әни, кара, кертеп булмый,*
*Нишләтергә бу үкчәне?!*
**2нче кыз:**
*(туфлине тартып алып)*
*Ничек сиңа ярасын ул,*
*41ле размер кигәч!*
*Мин киям дә шул туфлине*
*Булам инде аңа бикәч!*
*Аһ, хәерсез, кечкенә шул,*
*Түгел икән һич кимәле.*
*Гөлкәй, зинһар, ярдәм итче,*
*Кидерт инде, мә, кил әле!*

*Гөлкәйнең кулына туфлине тоттыра.*

*Син бит безнең алтын куллы,*
*Һәрбер эшне булдырасың.*
*Син бит безнең күз карасы,*
*Син юасың, туйдырасың.*
*Я, Гөлкәем, ярдәм итче,*
*Ничек итсәң ит, тик кидерт!*
*Шуны киеп, кәс-кәс басып,*
*Күрсәтәсем килә биеп.*
*Әнә теге кыз шикелле*
*Хәтерлимсең, әни, балда.*
*Аны күреп  хәйран калды,*
*Сокландылар аңа бар да!*
**Вәзир:**
*Я, туктагыз, азапланма,*
*Туфлине дә азаплама!*
*Яле, туташ, сез киегез,*
*Шуны киеп, бер биегез.*

БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

*Бал. Бар да бииләр.*
*Уртада Принц белән Гөлкәй.*
*Тәмам.*

***Мостафина Нәзилә Камил кызы***
*Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре «Советлар Союзы Каһарманы М.Е.Сергеев исемендәге Норлат гимназиясе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**“Театрның югалмас атасы”**

Кереш сүз

Пьеса якташым, авылдашым Габдулла Кариев биографиясенә нигезләнеп язылды. Ул матур әдәбият белән кызыксынуны арттыру, татар театрының атасы, режиссер, актер, педагог, драматург Г.Кариев иҗаты һәм тормышы белән тирәнрәк таныштыру, аның “Артист” пьесасы хакында фикер йөртә белергә өйрәтү, туган телебезгә мәхәббәт уяту, милли мәдәниятебезне, сәнгатебезне, татар халкының күренекле вәкилләренең тормышын һәм хезмәтен тулырак өйрәнү, аларга карата ихтирам хисләре тәрбияләү максатыннан иҗат ителде. Пьесаны язганда, Г.Кариев исемендәге музей хезмәткәрләре, шәхеснең авылдашлары белән аралаштым, “Артист” Г.Кариев (Казан, 1924), “Г.Кариев турында истәлекләр” (Казан, 1967), “Г.Кариев” (1976), “Туган җире Кари Габдулланың” (Казан, 1996), “Г.Кариев исемендәге музей” (Казан, 2006), “Дуслык” газетасындагы (10, 21 февраль, октябрь, ноябрь 2006) мәгълүматларга таяндым.

**Катнашалар:** *Миңлебай, Габдулла – татар театрының атасы, актер.*
*Җамали – Габдулланың балачак дусты.*
*Малик - Габдулланың балачак дусты.*
*Гөлсем - Габдулланың балачак дусты.*
*Салих - Габдулланың балачак дусты.*
*Латыйфи – Габдулланың әтисе ягыннан туганы.*
*Сәхибҗамал – Гыйззәтуллина-Волжская “Сәйяр” труппасы артисты.*
*Шакир – Шамильский “Сәйяр” труппасы артисты.*
*Вәлиулла – Мортазин-Иманский “Сәйяр” труппасы артисты.*
*Мулла.*
*Хәрби кешеләр.*
*Станция начальнигы.*
*Тикшерүчеләр.*

*Вакыйгалар Колбай Мораса авылында һәм Җаек шәһәрендә бара.*

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Азан тавышы яңгырый. Пәрдә ачыла. Сәхнәнең бер почмагына милли бизәкләргә бай, тәрәзәле өй макеты урнаштырыла. Йөгереп килгән кешеләрнең аяк тавышлары ишетелә, үзләре берсен-берсе бүлеп сөйләшә. Беренче, әйдәп баручы малай, артка борылып, өлгермәүчеләрне ашыктыра.*

**Җамали:**
Әйдәгез инде, тизрәк, соңга калабыз.

**Малик:**

Йөгерәбез бит инде. *(Туктап)* Салихны чакырырга оныттык.

**Бергә**:

(*туктап, Маликка карап)* Әйттек бит, кердек бит аңарга. Са-лих...

*Сәхнә артыннан талчыккан, арыган, ләкин дусларыннан калышмаска тырышучы Салих йөгерә.*

**Салих:**

Мин мон-да-а-а-а-а....

*Йөгерүчеләр төркемен йомгаклап, иң ахырдан,авыз эчендә нидер сөйли-сөйли, Гөлсем йөгерә.*

**Гөлсем:**

*(йөгерүдән туктап, хәл алып)* Тук-та-гы-ы-ыз! *(Бар да борыла)* Мин дә монда-а-а-а... Миңлебайга килеп җитәбезме инде?

**Бергә:**

Әйе! Әйе! *(Йөгерүләрен дәвам итәләр)*

**Гөлсем:**

Миңлебай өйдә булмаса нишлибез? Аңардан башка кызык булмый бит!

*Күпмедер сәхнә буйлап йөргәннән соң, сәхнәдәге өй янына җитәрәк, барысы да бергә кычкыралар.*

**Бергә:**

Миң-ле-бай! *(Тәрәзәдән бер малай башы күренә)*

**Миңлебай:**

Нәрсә?

**Бергә:**

Безнең янга чык әле!

**Миңлебай:**

Хәзер чыгам.

*Миңлебай чыккан арада балалар, сәхнә уртасына җыелып, болынга баргач, нинди уеннар уйнаячаклары турында бик кызу сөйләшә башлыйлар.*

**Җамали:**

Бишташ уйныйбызмы?

**Бергә**:

Әйе! Әйе!

**Малик:**

Качышлы уйныйбызмы?

**Бергә:**

Әйе! Әйе! *(Бу арада башына түбәтәй, аягына чабата кигән Миңлебай күренә.)*

**Гөлсем:**

Миңлебай! Карагыз, Миңлебай килә. *(Барысы да малайны әйләндереп алалар һәм сәхнә уртасына тартып китерәләр.)*

**Бергә:**

Әссәламәгәләйкүм, Миңлебай.

**Миңлебай:**

Вәгаләйкүмәссәлам. Нәрсә булды?

**Җамали:**

Миңлебай, болын янында яшәүче Салих бабайның оныгы кайткан, барыбызны да уйнарга чакырган. Яңа уен өйрәнеп кайткан, ди. Аңарга синең турыда сөйләгәннәр, ди. Хәзер "үзе белән бик танышасы килә" дип әйтә, ди. Барасыңмы?

**Гөлсем:**

Нишләп бармасын ди инде, бара. Шулай бит, Миңлебай. Син бармасаң, анда мине ишетмиләр дә, тагын сугышып кына бетәчәкбез. Сине бит барысы да тыңлый, ул кунак малае синең кебек уенны да оештыра белмәс әле.

**Җамали:**

Гөлсем, тукта әле, Миңлебай сүз дә әйтә алмый бит! *(Көлешәләр. Гөлсем үпкәләгән рәвеш ясый.)*

**Миңлебай:**

Сез өй эшенә бирелгән догаларны ятладыгызмы әле? *(Балаларның кайсысы гаепле кеше кебек башын иеп, кайсысы әле яңа өй эше барын искә төшереп басып тора.)*

**Малик:**

Өйрәндек инде бераз, кайткач тагын кабатлыйбыз.

*Гөлсем алга чыгып, "Бетте баш!" дигән йөз ясый.*

**Гөлсем:**

Өйрәнәбез аны, шуны да өйрәнмәскә, кайтуга сабакка утырабыз. *(Кире балалар янына йөгереп килеп)* "Әйдәгез инде, соңга калабыз би-и-ит! Миңлебай, әйдә инде-е-е!"

**Бергә:**

Әйдә, Миңлебай, синең белән уйнаганда һәрвакыт кызык була.

**Миңлебай:**

Юк, дуслар, икенче юлы, минем өй эшен кабатлыйсым бар.

**Бергә:**

И-и-и, ярар, без киттек, килерсең!

**Миңлебай:**

Ярар.

*Миңлебай алга атлый, табигатьне карый. Шул чакта башкалар белән киткән Гөлсем кире килеп, Миңлебайның, уйланып, каядыр карап торганын күрә.*

**Гөлсем:**

Син кая карыйсың?

**Миңлебай:**

Безнең Колбай Мораса авылы табигате шундый матур, әйеме?

*Гөлсем, кулларын маңгаена куеп, тирә-якка карый.*

**Гөлсем:**

Әйе, шундый матур! М-м-м... Ничек әйтергә дә белмим инде. Менә шундый-шундый матур!

**Миңлебай:**

*(елмаеп)* Дөрес әйтәсең, Гөлсем. "Матур" дип әйтү генә дөрес булмас шул. Челтерәп аккан чиксез чишмәләрнең чылтыравын, Мораса елгасының ярларыннан ташып чыгардай, көмештәй мул суын, хуш исле болыннарын, мул игеннәрен, рәссам да ясап

бетерә алмаслык таң аткандагы, кояш баегандагы хозурлыкны бер сүз белән генә аңлатып биреп булмый шул!

**Гөлсем:**

Шулай, шулай, Миңлебай. *(Ашыкканын исенә төшереп)* Миңлебай, әйдә инде безнең белән. Синсез уйнауның яме дә булмый. Кирәк чакта ягымлы сүзең, урынлы шелтәләрең безне шундый дус, бердәм итә бит.

**Миңлебай:**

Рәхмәт сиңа. Мин, киресенчә, дусларым белән уңдым дип йөрим әле. *(Елмая.)* Әлегә барып булмый шул, бәлки соңрак килермен.

**Гөлсем:**

Ярар, мин киттем, аннары кил.

*Миңлебай читкәрәк китеп утыра да, догаларын кабатлый башлый. Аны авылның мулласы ишетә, тыңлап тора, укып бетергәч, малай янына килә.*

**Мулла:**

Өйрәнергә кушылган барлык догаларны да яхшы өйрәнгәнсең, олан. Миңа калса, Коръәнне белгән кешегә Миңлебай исеме туры килми, син бүгеннән Габдулла булырсың. Сезнең өй ягына бара идем, әйдә әле, минем белән атла.

*Миңлебай башы белән ишарәләп, бергә сәхнә артына кереп китәләр.*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Сәхнәгә, сөйләшә-сөйләшә, Җамали белән Малик килеп керә.*

**Җамали:**

Ишеттеңме, Габдулла кайткан, диләр?

**Малик:**

Нинди Габдулла?

**Җамали:**

Безнең Миңлебай инде, Хәйруллин!

**Малик:**

Ә, шулай диген. Ул нинди мәдрәсәдә укый әле?

**Җамали:**

Мотыйгия мәдрәсәсендә. Анда ниндидер Габдулла белән бер бүлмәдә яшиләр, ди. Ул шигырьләр яза икән, гәҗиттә дә бастырып чыгара, ди.

**Малик:**

Безнең Габдулла үзе язгандыр әле. Элек тә шигырьләр язгалый, кызык сөйләп, кәмит уйнап, безнең күңелләрне күреп йөри иде. *(Көлешәләр, шул чакта зәвык белән киенгән Габдулла килеп керә.)*

**Җамали:**

Габдулла? Синме соң бу?

**Габдулла:**

*(кунак роленә кереп)* Әссәламәгаләйкүм, хөрмәтле дус-ишләрем! Сезгә Җаек якларыннан кайнар сәламнәр алып кайттым. Кар-бураннарны җиңеп, сезнең хәер-фатихаларыгыз ярдәмендә исән-имин кайтып барыш. Күрәм, сез дә исән-сау, мине

зарыгып күтәсез, килегез яныма. *(Кулын җәйгән кыяфәт ясый, барысы да Габдулланың кыланышларыннан көлешеп, кул биреп исәнләшәләр.)*

**Малик:**

Бер үзгәрмисең, Габдулла. Чын артист инде үзең!

**Габдулла:**

Ничек хәлләрегез? Шундый сагынып кайттым үзегезне. Минем сезгә сөйлисе яңалыкларым, уртаклашасы искиткеч зур шатлыкларым бар, дуслар. Җаекта бик күп кешеләр белән таныштым. Язучылар, шагыйрьләр, артистлар... Алар белән аралашсагыз, сезнең күңелләргә дә хуш килерләр иде. Һәрберсе үзенчә талантлы, рухи яктан бай, иҗади шәхесләр. Алар сине рухландыра, канат үсти, терәк була беләләр. Нәкъ сезнең кебек тугъры сердәшчеләр дә алар. Алар белән танышуымның иң зур нәтиҗәсе, күптәнге хыялымны тормышка ашырырга ярдәм иттеләр. Без “Сәйяр” дип аталган театр труппасы да оештырдык. Шулай гөрләтеп яшәп ятабыз.

**Җамали:**

Менә сиңа артист! Шәп!

**Малик:**

Безнең хәлләр дә әйбәт кенә. Сине котлыйбыз! Афәрин! Булдырасың!

**Габдулла:**

Рәхмәт. Шулай да бит, барысы да сезнең кебек аңлап бетерми...

**Малик:**

Ник алай дисең?

**Габдулла:**

Бик күп каршылыклар аша үтәргә туры килә. Шулай да киләчәккә булган якты өметләр безгә алга атларга, уңышлы киләчәккә ышанырга көч бирә. Сөйләсәң, озак инде, әйдәгез безнең өй ягына таба атлыйк, ашыйсы да килә. *(Сәхнәдән китәләр.)*

*ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ*

*Авыл советына хәрби киемнән ике кеше килә. Старостаны сорыйлар.*

**Хәрби кешеләр:**

Исәнмесез! Добрый день! Без - Җаек шәһәреннән. Сезнең авылда туган, Җаек шәһәрендә оештырылган демонстрациядә катнашкан Хәйруллин Габдулланы эзли идек. Аны туган авылы Колбай Морасада күргәннәр икән. Ул биредәме?

**Латыйф:**

Исәнмесез! Бер дә белгән хәбәр түгел, андый кеше безнең авылда юк.

**Хәрби кешеләр:**

Без берничә көн авылда булабыз, кайда булуын белсәгез, хәбәр итәрсез. Сау булыгыз!

**Латыйф:**

Хәерле юл! *(Хәрби кешеләр чыгып китә, Латыйф үз-үзенә)* Бу малайга ничек тә булса хәбәр бирергә кирәк, авылда күренеп йөрмәсен. Дааа... Хәйруллин паспорты белән ерак та китә алмас, нәрсә булса да эшләргә! *(Уйланып, чыгу юлына атлый. Шулвакыт сәхнәгә Габдулла керә.)*

**Габдулла:**

Ни хәлләрдә, Латыйф абзый?

**Латыйф:**

Иии, энекәш, әле сезгә бара идем. Җаек шәһәреннән килгәннәр. Сине эзлиләр. Берәр хәл булдымы әллә, энем?

**Габдулла:**

Авылдан эзләрләр дип уйламаган идем. *(Кәефе кырылып)* Җаекта “Сәйяр” дип аталган театр труппасы оештырдык. Спектакльләр куя башладык. Безнең башкарган эшебезне, яңача юнәлештәге фикерләребезне аңламаучылар да барлыкка килде. Эзәрлекли башладылар. Инде монда да кайтып җиткәннәр.

**Латыйф:**

Энем, син Хәйруллин паспорты белән ерак китә алмаячаксың. Аны тиз арада алыштырырга, минемчә, Кариев дигән фамилия бик килешер үзеңә.

**Габдулла:**

*(уйланып тора)* Бу хәлләрдән башка чыгу юлы юк дисең инде, абый, шулаймы?

**Латыйф:**

Әйе, энекәш. Әлегә авылдан китеп, башка җирләрдә күренеп йөрергә кирәк түгелдер. Ничек уйлыйсың?

**Габдулла:**

Шулай да мин авылда озак торып бетә алмам шул, абый. Миңа Җаектагы ирекле, актив тормышым җитми. Андагы “Сәйяр” артистларым, уйнаган рольләрем, сүз ирегем җитми.

**Латыйф:**

Белмим инде, энекәш. Үз язмышың – үзеңнең кулыңда.

**Габдулла:**

Рәхмәт сиңа. *(Сәхнәдән кереп китәләр.)*

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Бер кечкенә чемодан күтәреп, сәхнәгә Габдулла килеп керә. Як-ягына карый. Паркның икенче ягыннан бер төркем яшьләр килүен күрә. Шулар арасыннан берсе аны таный.*

**Сәхибҗамал**:

Габдулла, синме соң бу? Карагыз әле, Габдулла ич бу!

**Габдулла:**

Кардәшләрем, сезне очратуга шундый шатмын! Нихәлләрдә яшисез? Театр куюны туктатмадыгызмы? Нинди яңалыкларыгыз бар? Сөйләгез! *(Габдулланы әйләндереп алган дуслары, кәефсез генә, паркта торган эскәмияләргә утыра.)*

**Шакир:**

Нинди театр ди?! Булган пьесаны әзерләүче кеше, репетиция ясарга почмагы, транспорты булса икән.

**Вәлиулла:**

Башлап җибәрергә кесәдә бер тиен акчасы, барып киңәшерлек оештыручысы да юк бит! Юк инде ул!

**Габдулла:**

Сез нәрсә? Әллә бездән булмас дисезме?! Мин бер пьеса яздым *(үзе көлә),* нәкъ безнең турыда. Әйдәгез, без элек яшәгән йортның хуҗасы белән сөйләшеп карыйк, бәлки

анда кереп рольләрне карый алырбыз. *(Сумкасыннан берничә бит ала, гөр килеп сөйләшеп, сәхнәдән югалалар.)*

*Поезд тавышы ишетелә, грим чемоданын, төеннәргә төрелгән роль өчен кирәкле киемнәрне кочаклап, "Сәйяр" артистлары йөгерә.*

**Сәхибҗамал:**

Габдулла, беребезнең кесәсендә бер тиен акча юк, төшереп калдырырлар инде, нишлик соң? Әле һәр вагон саен артистлар утырып бармыймы дип тикшереп йөриләр икән.

**Габдулла:**

Барабыз булгач барабыз. Сез бит артистлар, уйнагыз. Качышлы уйнагыз. Алдагы юлы, исегездәме, утын төялгән вагонга утырып бардык. Сизделәрме? Юк!

**Шакир:**

Анда бит җәй ае иде, хәзер көзге як, салкын.

**Габдулла:**

Безме инде салкыннан курыккан?! Муеныңа яхшырак чорна, тавышың гына туңмасын! *(Барысы да көлешеп, вагонга утыралар. Кемдер киеменнән бала ясап кочаклаган, кемдер йоклаган кеше рәвешен алган. Салкын. Барысы да булган әйберләренә чорнала башлый. Габдулланың бик каты колаклары өши, ул аптырап тормыйча кесәсендәге носкиларын колагына киеп куя да, җылынып, йоклап китә. Йокы аралаш бер станциядә тикшерү кергәнен дә сизми калалар.)*

**Тикшерүчеләр:**

Уяныгыз! Сез кулга алынасыз! *(Станция начальнигы янына алып китәләр, керәләр. Начальник язып утыра, тавышка башын күтәреп карый да көләргә тотына, артистлар югалып кала.)*

**Станция начальнигы:**

Сез чыннан да артистлар, ахрысы?! *(Кариев колагындагы носкиларны исенә төшереп, аларны тиз генә ала да, гаепле кеше шикелле басып торуын дәвам итә.)*

**Габдулла:**

Гафу итегез, без, чыннан да, артистлар шул, яңа пьесабыз белән гастрольгә барышыбыз иде.

**Станция начальнигы:**

Ярый, кәефне күтәрдегез. Әй, кем бар анда, керегез әле. *(Керәләр.)* Кунакларны чәй бүлмәсенә озатып сыйлагыз, җылынсыннар. Аннары станциягә озатып, утыртып җибәрегез үзләрен. *("Рәхмәт!" әйтеп чыгып китәләр.)*

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Сәхнәгә Җамали белән Малик чыга.*

**Малик:**

Җамали, бүген театр килә ди бит, барабызмы?

**Җамали:**

Барабыз, безнекеләрнең барысы да беләме икән? Гөлсемгә дә әйтергә. Ул тамаша карарга бик ярата бит. *(Шулай сөйләшеп торганда, Гөлсем белән Габдулла, тагын берничә таныш булмаган кешеләрнең алар ягына атлауларын күрәләр.)*

**Малик:**

Әллә Габдулла театр куярга артистлар алып кайткан инде?

**Гөлсем:**

Әйттем бит! Габдулла артист була дип! *(Үзе бер алдына - бер артына чыга)* Менә, карагыз, артистлар алып кайткан, бүген театр куябыз, ди. Үзе язган! *(Кыланып әйтә)* “Сәйяр” труппасы артистлары “Артист” дип аталган спектакль тәкъдим итә. *(Егетләргә карап)* Барабыз, барыбыз да бара, шулай бит, егетләр! *(Габдулла янына килеп)* Габдулла, мин Миңлебай булган вакыттан ук синең танылган артист, оста оештыручы булуыңа ышана идем. Синең сөйләвеңә, уйнавыңа кечкенәдән гашыйк идем. Син минем өметемне акладың. *(Бит очыннан үбеп ала да, оялып, башкалар янына барып баса. Барысы да Гөлсемгә карап көлешәләр.)*

**Габдулла:**

Рәхмәт, Гөлсем. Минем тугъры дусларым, фикердәшләрем! Һәрвакыт янымда булып, ярдәм иткәнегез өчен, ышанганыгыз өчен рәхмәт сезгә! “Без шундый театр төзербез, аның исемнәре алтын хәрефләр белән язылыр!”

**Бергә:**

Амин! Амин!

*Дустың булса, шундый булсын,*
*Утны-суны кичәрлек.*
*Тугърылыкка вәгъдә бирми,*
*Сине сатып китмәслек.*

*Пәрдә.*


***Җәләева Гөлфия Рифгать кызы***

*Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы Ютазы «Кояшкай» балалар бакчасы тәрбиячесе*


## “Могҗизалар төне”

**Катнашалар:**

*Ак әби - авылның хөрмәтле әбисе, Айнур белән Айгөлнең әбиләре.*
*Айнур - балалар бакчасында тәрбияләнүче малай, Ак әбинең оныгы.*
*Айгөл - балалар бакчасында тәрбияләнүче кыз, Ак әбинең оныгы.*
*Шүрәле – авылны гына түгел, татар телен дә саклаучы.*
*Әби белән бабай – Камырбатырның әти-әнисе.*
*Гөлчәчәк – әкият герое.*
*Убырлы – “Гөлчәчәк” әкиятеннән.*
*Сарык белән Кәҗә – әкият геройлары.*
*Сертотмас үрдәк – Алиш әкиятендәге үрдәк.*
*Үги кыз – “Үги кыз” әкиятендәге кыз.*
*Балалар – балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр.*

ПРОЛОГ

*Тышта ябалак-ябалак кар ява. Җиһанның бар халкы Яңа елны каршылый. Бу төнне һәрбер кеше ниндидер яңалык, могҗиза көтә. Нәрсә дә булса булыр кебек. Күңел җилкенә.Талгын гына көй яңгырый.*

*Өйнең эчке күренеше. Уртада матур итеп бизәлгән чыршы утыра. Ап-ак яулык бәйләгән Ак әби оныкларын йокларга яткырган. Өсләренә бер кат япкач, яннарына утырып, әкият укый башлый.*

**Айгөл:**

Әби, әби, әби, дим. Син нигә безнең белән гел татарча сөйләшәсең, менә әкиятне дә гел татарча сөйлисең?

**Әби:**

И-и-и, балам, телебез онытылып бара бит, менә сез дә, китәсез дә шул шәһәрегезгә, тагын онытып кайтасыз. Һәрбер кеше, балам, үз телен белергә, үзенең бабаларының тарихын, гореф-гадәтләрен, ничек яшәгәннәрен белергә тиеш.

**Айнур:**

Рәхмәт, әбием, сиңа, безгә шундый матур исемнәр куштыргансың. Әкиятләрнең дә бит син безгә иң әйбәтләрен, иң матурларын сөйлисең, тыңлыйсы гына килеп тора.

**Әби:**

Ярый, балалар, йоклагыз инде сез. Төн дә җитеп килә, тәмле төшләр сезгә, бәбкәйләрем. (*Чыгып китә.)*

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ.

*Әби китү белән өй уртасында утырган чыршының уенчыклары җемелдәшә башлый. Өй эче кинәт кенә ничек яктырса, шулай тиз караңгыланып китә. Яшен яшьнәгән, күк күкрәгән тавышлар чыга. Яктырганда, Айнур белән Айгөл һәм тагын ике бала бер-берләренә каранып, аптырап басып торалар. “Әкиятләр авылы” дигән элмә такта куелган. Балалар аны күрмичә үтеп китәләр.*

**Айгөл:**

Без кая килеп чыктык? Тирә-якта бер таныш әйбер дә күренми. Ой, ой, ой, Айнур, мин куркам. Нинди җир бу? Авылга да ошаган.

**Айнур:**

Курыкмый тор әле, әнә тегендә капка төбендә әби белән бабай күренә. Әйдә, шулар янына барыйк. *(Әби белән бабай янына баралар. Карасалар, әби белән бабай елап утыралар.)*

**Айнур:**

Нәрсә булды сезгә, бабакай, нигә елыйсыз? Без кая килеп чыктык ул? Бу нинди авыл?

**Әби:**

И, улым, сез әкиятләр авылына килеп эләктегез, монда татар халык әкиятләренең бөтен геройларын да күрергә була. Ә без еламас идек тә бит, сәбәбе бар. Әйе, әйе, безнең дә улыбыз бар иде бит. Камырбатыр исемле.(*Елап җибәрә.*)

**Айгөл:**

Ә хәзер кая улыгыз?

**Бабай:**

Ул күптәннән чыгып киткән иде инде. Менә хәзер авылга кайта алмый ята.

**Айгөл:**

Кызык инде. Нишләп авылга кайта алмый соң ул? Без әбиләргә гел кайтып йөрибез.

**Әби:**

Камырбатыр читтә йөреп, үз телебезне оныткан. Ә безнең Әкиятләр авылына татарча белмәгән кешеләрне кертмиләр. Нишләргә дә белмибез инде. Авылны җүнсез Шүрәле саклый. Әле ул Кәҗә белән Сарыкны да кертмәскә кушкан. Ничек сез аның аркылы үткәнсездер?!

**Айнур:**

Без Шүрәлене күрмәдек. Ә Камырбатырны кайтару өчен берәр җай бардыр инде ул, булмый калмас.

**Бабай:**

Бер шарты бар инде аның анысы. Камырбатырга үзебезнең телне искә төшерү өчен, татар халык мәкальләрен искә төшерергә кирәк. Бәлки, балалар, сез ярдәм итәрсез?

**Балалар:**

Әлбәттә, ярдәм итәрбез. (*Интерактив уен, балалар мәкальләр әйтәләр).*

**Бабай:**

Ну, булдырдыгыз, балалар.

**Айнур:**

Бабай, кирәк булса, без әле тагын беләбез.

**Бабай:**

Булды, балалар, булды. Шуның кадәр мәкаль ятласа, Камырбатырыбыз үз телебезне искә төшерер, боерган булса.

**Әби:**

Әйдә, бабай, Камырбатырга SMS җибәрик булмаса, кая телефоның?

**Бабай:**

Хәзер, карчык, хәзер, ашыктырма, күпкә көткәнне, әзгә генә калгач көтәр. (*Бабай Камырбатырга өйрәнергә дип мәкальләр яза башлый.)*

**Әби:**

И-и-и, рәхмәт инде, балалар. Исән-сау үз илләрегезгә кайтып җитегез.

*Шул чак аркасына агач мылтык аскан Шүрәле керә.*

**Шүрәле:**

Минем рөхсәттән башка нишләп йөрисез әле сез монда?

**Айнур:**

И, Шүрәле, Шүрәле. Без бит сине күрмәгәнбез. Исәнме, Шүрәле. Син үзең бу авылда нишлисең?

**Шүрәле:**

Сез минем турында язган, татар халкының бөек улы Габдулла Тукайны беләсезме соң? Аның әсәрләрен хәзер бөтен дөнья укый. Аның әсәрләрен татар, рус, инглиз телләренә тәрҗемә ясап чыгардылар. Вәт, татар язучылары, нинди үлемсез әкиятләр язып калдырганнар.

**Айгөл:** Шүрәле, без Тукай абыйның әкиятләрен дә, шигырьләрен дә яратабыз. Безгә Ак әби гел сөйләп кенә тора. Син нишләп соң әле Камырбатырны авылга кертмисең? Әле Кәҗә белән Сарыкны да кертмәскә кушкансың?

**Шүрәле:**

Кайтыр, кайтыр Камырбатырыгыз, өйрәнсен әзрәк туган телне. Авылдан китәләр дә, әллә кем булалар. Кәҗә белән Сарыкны әйтер идем инде. Менә үз телебездә шигырь яки экият сөйләп күрсәтсеннәр - кертермен.

**Айнур:**

Әйдә, Шүрәле, без болай итәбез. Син аларга табышмаклар уйлап тап, ә алар җавап бирсеннәр.

**Шүрәле:**

Ул табышмакларны уйлыйсы юк инде, үзебезнең татар халкында да бик күп бит алар. Әйдәгез, мин сезне Кәҗә белән Сарык янына алып барам.

**Балалар:**

Әйдәгез, барабыз. Киттек.

*Барысы да чыгып китәләр.*

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ.

*Урман аланы. Берничә агач үсеп утыра. Бәбәй итәкле матур күлмәк кигән, ак калфактан, читекләрдән бер кыз елап утыра. Аланга балалар белән Шүрәле килеп керә.*

**Шүрәле:**

Гөлчәчәк, акыллым, тагын явыз кайнанаңнан качып чыгып киттеңмени?

**Гөлчәчәк:**

Балалар, Шүрәле! Мине качырыгыз әле, үтенеп сорыйм, минем кайнанам Убырлы хәзер куып җитә. Әнә ул килеп тә җитте инде.

*Балалар һәм Шүрәле, Гөлчәчәкне уртага алып, җитәкләшеп басалар. Йөгереп, выжылдатып, Убырлы керә.*

**Убырлы:**

*Көлтә-көлтә койрыгым,*
*Болгый-болгый улаем.*
*Күмәчләремне бирмәсәң,*
*Калҗа-калҗа тураем.*

**Шүрәле:**

Убырлы, син әле һаман Гөлчәчәкне җәберләп яшисеңме? Андый заманнар күптән үтте инде. Хәзер бөтен кеше дә тигез, Гөлчәчәкне җәберләргә юл куймабыз.

**Убырлы:**

Үзем дә туйдым инде. Балалар миңа бер матур җыр җырлап, биеп күрсәтсәләр, мин бик шат булыр идем. (*Балалар, бии-бии, матур җыр җырлыйлар).*

**Убырлы:**

Менә, булдырдыгыз, балалар. Күңелләрем күтәрелеп китте. Ә син, Гөлчәчәк кызым, әйдә өйгә кайт. Анда сине минем улым көтә. Әйе, әйе, ялгыш ишетмәдең, ирең көтә. Кайт та, аннары бергәләп әниләрегезгә барырсыз.

*Гөлчәчәк яңалыкны ишеткәч, һуштан язып егыла. Барысы бергә аны тотып калалар, һушына китерәләр. Кемдер су бөрки, кемдер җилләтеп тора.*

**Гөлчәчәк:**

*(һушына килеп)* Әйдәгез, сез дә безнең белән, бәйрәм итәрбез бергәләп.

**Айнур:**

Юк, юк, Гөлчәчәк, безнең әле эшләребез бар, әйеме, Шүрәле?

**Шүрәле:**

Әйдәгез, Гөлчәчәк белән саубуллашыгыз да, Кәҗә белән Сарыкны коткарырга киттек.

**Балалар:**

Сау бул, Гөлчәчәк. (*Убырлыга)* Кара аны, Убырлы, Гөлчәчәкне рәнҗетсәң, хәзер килеп җитәрбез.

*Барысы да чыгып китәләр.*

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Урманда заманча җиһазландырылган урман өе. Заманына туры китереп киенгән (кара күзлекләрдән, джинсы чалбарлардан, икесенең дә кулларында телефоннар) Кәҗә белән Сарык диванда яталар. Чит ил музыкасы яңгырый. Ишек шакыйлар.*

**Кәҗә:**

Сарык, ишек шакыйлар, открой!

**Сарык:**

Нәрсә командуешь, үзең ач!

*Шүрәле, балалар - барысы бергә өйгә килеп керәләр.*

**Шүрәле:**

Ишек тә ачмыйча нишләп ятасыз монда?

**Сарык:**

И, Шүрәле абзыкаем, сез икәнсез, а мы думали опять бүреләр.

**Айнур:**

Без сезне авылга, әби белән бабай янына кайта алмыйсыз дип ишеткән идек. Сезгә ярдәм итәргә килдек.

**Кәҗә:**

Безгә бернинди дә помощь не нужна.Мы сами по себе.

**Шүрәле:**

Ярар, алайса, балалар, әйдәгез киттек, юкка вакыт үткәреп тормыйк бу җүнсезләр янында. *(Чыгып барган вакытта Сарык, йөгереп килеп, аларны туктата.)*

**Сарык:**

Туктагыз, туктагыз! Китмәгез инде, мине тыңлагызчы, зинһар.

**Шүрәле:**

Карагыз әле, үзенә кирәк булгач, ничек матур итеп татарча сайрый.

**Сарык:**

И, шүрәле абзый, шаярып торма әле, ичмасам. Шаярудан узган безнең хәлләр. Авылга бик кайтасы килә безнең, ләкин анда безгә юллар ябылган.

**Балалар:**

Нишләп?

**Сарык:**

Без бит әби белән бабайны ташлап, баерга дип чыгып киттек. Башта эшләр шәп барды безнең. Бүреләр белән бергә бизнес ачкан идек. Бүре башыннан башланган бизнес банкротлыкка чыкты. Әкренләп бүреләр качышып беттеләр, урманда бер бүре калмады. Хәзер менә күккә карап ятабыз. Ашарга әлегә бар анысы, ләкин алда ни булыр*(елап җибәрә*). Әбиләрне дә сагындык.

**Кәҗә**:

(*еламсырап*) Ярар, инде, Сарык, җае килер әле.

**Шүрәле:**

Аңламассың боларны. Әби белән бабай тегендә елыйлар, болары монда. Туктатыгыз балавыз сыгарга! Хәзер бер җаен табарбыз.*(Балалар белән түгәрәк ясап, киңәшләшеп алалар. Шүрәле Айнурга, блокнотыннан карап, нәрсәдер бирә).*

**Айнур:**

Кәҗә, синең скайптан сөйләшкәнең бармы? *(Кәҗә башын селкетә, Айнур телефон аша скайпны көйләп бирә. Бабай тавышы ишетелә.)*

**Кәҗә:**

(*экранга карап*) Бабай, әби, безне гафу итегез, без сезне яратабыз.

**Бабай**:

Балакайларым, кайтыгыз, сагындык сезне. Әнә әбиегез дә елый да елый.

**Сарык:**

Кайтабыз, бабай, кайтабыз болай булгач.

**Кәҗә:**

Югалдылар әби белән бабай, телефон тотмый башлады. Ярый, Сарык, җыен әйдә, авылга киттек.

*Барысы да чыгып китәләр. Урман буйлап авылга юл тоталар. Сарык белән Кәҗә, балалар, Шүрәле белән саубуллашып, икенче якка аерылып китәләр.*

**Айгөл:**

Сарык белән Кәҗәгә дип күпме табышмак әзерләдек, ә аларга кирәк тә булмады. Татар телен белмиләр, имеш. Бик тиз искә төшерделәр.

**Айнур:**

Ярар инде, Айгөл. Шәп булды бит әле бу. Бер-берләрен аңламыйча, күпме кешеләр чит-ят җирләрдә йөриләр. Бары бер җылы сүз җитә, бары бер аңлашу.

Туктагыз әле, әнә тегендә карагыз, кем ул анда алпан-тилпән атлап, бу якка таба килә? *(үрдәк турындагы җыр яңгырый.)*

**Айгөл:**

Кая, кая ул? Әнә, мин дә күрдем, бу бит үрдәк, урманга таба бара. Әйдәгез, аны туктатыйк, бармасын урманга, анда бит төлкеләр, бүреләр күп.

*Үрдәкне туктаталар.*

**Айнур:**

Бу бит күренекле татар язучысы Абдулла Алиш язган әкияттәге Сертотмас үрдәк. Әй, үрдәк, хәлләр ничек?

**Үрдәк:**

Исәнмесез, барыгыз да. Мин хуҗабызны эзлим. Ул Хуҗабикәне, балаларны да алып, Сабантуй бәйрәменә киткәннәр иде. Җитмәсә, этебез дә аңа ияреп киткән иде. Хәзер йорт-җирне саклаучы берәү дә юк. Аларны чакырып кайтырга иптәшләрем мине җибәрделәр. Ел да Хуҗа шул Сабантуй дип исе китә инде. Нәрсә бардыр шунда. Минем дә бер барып карыйсы килә шул Сабантуйларын, урман аша чыгасы бар, куркыта.

**Айгөл:**

Тукта, үрдәк, тукта. Өйдәге бөтен серне дә сөйләргә ярамый.

**Шүрәле:**

Житте инде сиңа, үрдәк, тукта, бакылдавыңнан. Урманга да барып йөрмә! Әнә өеңдә генә утыр.

**Үрдәк:**

Минем бит хуҗабызны эзләп табасым бар.

**Шүрәле**:

(*хәйләләп*) Үрдәккәем, сиңа дип балалар бик күп табышмаклар әзерләп алып килделәр. Шуларны чишеп бетергәч, урманыңа китәрсең.

**Үрдәк:**

Мин табышмак чишәргә бик яратам, китерегез табышмакларыгызны, хәзер чишеп бирәм.

**Айгөл:**

Яле, яле, чишеп кара әле *(табышмаклар язылган китапны бирә).*

**Үрдәк**:

(*укый)* Да-а (*башын кашый*), бик катлаулы булдылар әле болар.

**Шүрәле:**

Менә, менә! Ярар, үрдәк, син чишә тор, без китик инде. Чишеп бетергәч, урманыңа барырсың. Әле ул китапта татар халкының борынгы бәйрәме – Сабантуй турында бик матур итеп язганнар. Бәлки, икенче тапкыр очрашканда, бәйрәмгә бергәләп барырбыз, кунакларга да күрсәтербез ул гүзәл бәйрәмебезне.

*Балалар, үрдәк белән саубуллашып, юлларын дәвам итәләр. Авылга якынлашалар. Эт өргән тавышлар ишетелә.*

**Айгөл:**

Сез дә ишетәсезме ул? Этләр: “Үләргә киткән түтекәй баеп кайта, баерга киткән түтекәй үлеп кайта,”- дип өрәләр.

**Айнур:**

Бу бит “Үги кыз” әкиятеннән. Татар халык әкиятен хәтерлисезме?

**Шүрәле:**

Балалар, ә сез беләсезме, үги кыз бит безнең авылда яшәп ята. Әйдәгез, аның янына кереп чыгыйк.

**Балалар:**

Әйдәгез, әйдәгез (*китәләр*).

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Чип-чиста җыештырылган, матур итеп бизәлгән авыл өе. Үги кыз, җырлый-җырлый, чигеп утыра. Татар кызларына гына хас бәбәй итәкле күлмәк, чигүле алъяпкыч, калфак кигән. Аягында читекләр, чәчләрендә чулпылар. Ишек шакыган тавышка йөгереп барып, ишек ача.*

**Үги кыз:**

Кемнәр анда безне мактап йөриләр? Яңа гына чәй әзерләгән идем әле. *(Өстәлдә нәрсәләр генә юк: чәк-чәк, кыстыбый, тәбикмәк...)*

**Шүрәле:**

Татар халкы ашларының бөтен төрен дә пешергән әллә? Уңган да инде син. Менә, кызым, ачуланмасаң, сиңа кунаклар алып килдем әле. Бик әйбәт балалар.

**Үги кыз:**

Әйдәгез, балалар, өстәлгә рәхим итегез, шунда танышырбыз.*(Балалар, Шүрәле өстәл янына утыралар, чәй эчәләр).*

**Айгөл:**

*(өйдәге чиккән мендәрләргә, сөлгеләргә, суккан паласларга күрсәтеп)* Үги кыз, син бу матурлыкны үзең ясадыңмы?

**Үги кыз:**

Әйе инде, күбесе бирнә.

**Айгөл:**

Бирнә, нәрсә соң ул бирнә?

**Үги кыз:**

Һәр кыз кияүгә чыкканда бирнә әзерли. Әнә күрәсезме, түрдә минем сандыгым тора. Шул сандыкка тутырып чиккән сөлгеләр, мендәрләр, кульяулыклар, калфаклар, хәләл җефетемә дип чиккән түбәтәй - барысы да сыйган.

**Айнур:**

Айгөл, кара әле, безнең әбинең дә шундый сандыгы бар бит.

**Айгөл:**

Әйе шул, бар. Мин кечкенәдән аны актарырга ярата идем. И-и-и, әбине сагындым, өйгә кайтасы килә (*Елый башлый*).

**Айнур:**

Елама, Айгөл, елама. Әйдә барысы белән дә саубуллашыйк та, кайтыр юлларны карыйк. *(Шүрәле, Үги кыз балаларны озатырга чыгалар.)*

**Балалар:**

Сау булыгыз, дуслар! Үз илләрегездә исән-сау гомер итегез.

*Кинәт барысы да югала. Караңгы булып ала. Ак әбинең тавышы ишетелә.*

ЭПИЛОГ

**Ак әби:**

Балам, уян, тор әйдә. Саташып ятасың, ахрысы. Нәрсәдер быгыр-быгыр сөйләшәсең.

*Бөтен дөнья яктырып китә. Балалар йоклап яталар, Ак әби Айнур кырыенда утыра.*

**Ак әби:**

*(онычын уятып)* Зур эшләр эшләп кайткан кеше сыман, авыр сулап йоклап ята бит ул минем улым.

**Айнур:**

(*киерелеп*) Хәерле иртә, әбием! И-и, әбием, син беләсеңме без кайда булдык? Чып-чынлап могҗизалар төне булды бу, әйеме, Айгөл?

*Шул вакытта Айгөл дә уянып, әбисе кырыена килеп утыра.*

**Айгөл:**

Ни сөйлисең син, мин аңламыйм, мин беркайда да булмадым.

**Айнур:**

Без бит “Әкиятләр авылында” булдык. Әйе, әбием, без анда Камырбатырга, Кәҗә белән Сарыкка өйләренә кайтырга булыштык. Гөлчәчәк белән кайнанасын дуслаштырдык, урманга бармасын өчен Сертотмас Үрдәккә күп итеп табышмаклар биреп калдырдык. Ә кайберәүләргә ярдәм итәсе дә булмады. Үги кыз үзенең акылы, ярдәмчеллеге, эшчәнлеге аркасында бөтен кыенлыкларны үтеп чыгып, бик бәхетле булып яшәп ята. Аның өен күрсәң, чиккән сөлгеләре, мендәрләре, суккан паласлары, пешергән ризыклары, барысы да шундый матур! Ә, бирнәсе, бер сандык. Әби, ә, әби, синең дә бит шундый сандыгың бар.

**Әби:**

И, улым, гел туктатып булмый сине. Бигрәкләр дә матур төш күргәнсең. Әйе, минем дә шундый сандыгым бар. Барыгыз юынып ашагыз да, мин сезгә сандыкта нәрсәләр барын күрсәтермен.

**Айнур:**

*(һаман хискә бирелеп)* Менә нинди икән бит, син, минем халкым. Элек-электән үк җор телле, сөйкемле, акыллы, эшчән, уен-көлке яратучы, ярдәмчел булгансың. Без әле кечкенә булсак та, бар нәрсәне аңлап бетермәсәк тә, үз телебезне яратабыз, үз телебездә яратып сөйләшәбез.

*Барлык катнашучылар чыгып, кулга-кул тотынышып, Габдулла Тукайның “Туган тел” җырын башкаралар.*

*Тәмам*

***Җамалдинова Лилия Рифкать кызы***
*Татарстан Республикасы, Буа муниципаль районы Буа шәһәренең «Төремкәй» балалар бакчасы тәрбиячесе*

## “Буа-Алан маҗаралары”

**Максат:** Балаларны әкият геройлары аша кешедәге кимчелекләрне, тискәре һәм уңай сыйфатларны күрә белергә өйрәтү; татар телендә тулы, дөрес җөмләләр әйтеп сөйләшү күнекмәләрен камилләштерү;

Табигатькә, туган җиргә, туган якка мәхәббәт хисләре, туган ягыбыз байлыкларына сакчыл караш тәрбияләү;

Дуслык хисләрен, бер-береңне хөрмәт итү хисләренең тирәнлегенә төшендерү;

Бәйрәм дигән күңел ачу чараларының асылына төшендерү.

**Әзерлек:** әкиятне сәхнәләштерү, геройлар белән аерым шөгыльләнү, декорация әзерләү.

**Кулланыла торган мәкальләр:**

-Эш беткәч, уйнарга ярый

-Хезмәт кешене тәрбияли

**Катнашучы геройлар:**

**Буа-Аланда яшәүчеләр.**

*Әкәмәт – ябалак.*

*Зәлилә – күбәләк.*

*Елтыр – куян.*

*Көяз – төлке.*

*Фырый – керпе.*

*Рудин – гном.*

*Шалтай белән Балтай - усал малайлар.*

**Әкият барышы**

*Мажҗара Буа- Аланында бара.*

*Алан. Яшеллек, матурлык, кошлар сайрыйлар. Агачлар, куаклар, чәчәкләр үсеп утыра. Бик матур урын. Җәйге матур көн. Шул чакта аланга кычкырып, Зәлилә килеп керә.*

**Зәлилә:**

Дусларым, әй, дусларым!

*Әкәмәт, Елтыр, Көяз, Фырый, Рудин йөгереп чыгалар.*

**Зәлилә:**

Тизрәк, тизрәк бер хәбәр бар! Тагын теге тәртипсез ике малай монда киләләр. Учак якмакчы булалар. Кулларында шырпы, аттыргыч... тагын әллә ниләр! Ничек аларны аланнан куарга, акылга утыртырга?!

**Елтыр:**

*Ай-яй, яй! Нишләргә?!*

*Ни булса да эшләргә!*

**Көяз:**

*Хәзер кызык итәбез!*

*Акылга утыртабыз!*

**Әкәмәт:**

*Әйдәгез, куркытабыз!*

*Акылга утыртабыз!*

**Фырый:**

*Ни сөйлиләр, тыңлыйбыз!*

*Хәзер качып торабыз!*

*Аннан план корабыз!*

*Барысы да йөгереп чыгып китәләр.*

*Шалтай белән Балтай килеп керәләр. Аркаларында букча, кулларында аттыргыч, шырпы... Сөйләшәләр, көлешәләр... Рудин белән Әкәмәт күзәтеп торалар.*

**Шалтай:**

Кайсыбызның аттыргычы яхшырак? Әйдә, ярышабыз. Кем ничә кошны агачтан атып төшерә ала?

**Балтай:**

Әйдә, башта утыннар җыеп килик тә, учак ягыйк, тамак ялгыйк. (*Икәүләп китәләр.)*

*Шул чакта Әкәмәт сызгыра, дуслары (гном, күбәләк, керпе, төлке) аланга килеп керәләр.*

**Әкәмәт:**

Тизрәк, Зәлилә, оч тегеләр артыннан, ни сөйлиләр, тыңла! *(Зәлилә китә.)* Ә син, Көяз, сиздерми генә аттыргычларын алырсың. *(Көяз аттыргычларын ала.)*

*Аланга Зәлилә керә.*

**Зәлилә:**

Киләләр... Качыйк тизрәк, күрмәсеннәр. *(Барысы да чыгып китәләр.)*

*Аланга Шалтай белән Балтай йөгереп керәләр. Букчаларын актара башлыйлар.*

**Шалтай:**

Кая минем аттыргыч? Син алдыңмы? Китер, кая. Үзеңнеке дә бар бит.

**Балтай:**

Ә минеке кая? Минеке дә юк. Ник минекен яшердең?

*Икәү бер-берсенең кесәләрен карый, тарткалаша, тавышлана башлыйлар, ник алдың дип, әйткәләшә башлыйлар. Шул чак, кырыйдан күренми генә Фырый калын тавыш белән кычкыра.*

**Фырый:**

Әй, сез нишлисез, малай актыклары. Тавышланмагыз! Туктагыз!

*Шалтай, Балтай кинәт тарткалашкан җирдән туктап калалар. Тавыш килгән якка карыйлар, эзли башлыйлар.*

**Шалтай:**

Кем бу? Әллә монда агачлар да сөйләшәме?

**Балтай:**

Ярар, әйдә, аттыргычлар югалды. Агачларны сындырабыз да, учак ягабыз, шырпы бар бит. Әкәмәт монда: агачлар да сөйләшә, аттыргычлар да югала икән. Әллә нинди әкәмәт урын булды бу!*(Йөгереп барып агачка ябыша. Сындырырга маташа. Шул чак Әкәмәт килеп чыга.)*

**Әкәмәт:**

Нигә мине чакырдыгыз? Нигә мине дәштегез?

**Малайлар:**

*(аптырап калалар, икәү бергә)* Син кем? Нишләп йөрисең монда?

**Әкәмәт:**

Мин - Әкәмәт исемле. Әле генә "әкәмәт" дип дәштегез ич. Бу аланның хуҗасы мин. Ә менә сез нишләп йөрисез? Кошларны куркытасыз, тавышланасыз, агачларны сындырасыз. Хәзер мин сезне, тәртипсез малайларны, кызык итәм. Моның өчен сезгә җәза бирәбез! *(сызгыра)*. Әй, дусларым, чыгыгыз әле монда. Алда зур эшләр тора. *(Барысы да чыгып, малайларны әйләндереп алалар.)*

**Көяз:**

*(малайларга аттыргыч күрсәтеп)* Сез нигә аланга аттыргыч алып киләсез? Кошларга атарга, аларны үтерергә ярамый. Аларның нәни балалары кала. Аларны кем ашатыр? Сезме?

**Фырый:**

*(малайларга шырпы күрсәтеп)* Ник шырпы алып килдегез? Өйдән нигә рөхсәтсез шырпы аласыз? Учак ягып, аланда янгын чыгарга мөмкин. Аны кем сүндерә? Сезме? Үзегез харап буласыз.

**Елтыр:**

Нигә сез үсеп утырган агачларны сындырасыз? Нигә матурлыкны юк итәсез?Алар бит һаваны чистарталар. Аларны сындырганчы, агачларны үзегезгә утыртырга кирәк!

**Рудин:**

Ике малайдан никадәрле тәртип бозу! Боларны болай гына калдырырга ярамый. Кирәкләрен бирик! Сабак булсын!

**Шалтай, Балтай:**

Без аңладык, гафу итегез безне. Башка алай булмабыз. Әйдәгез, дуслашыйк. Нинди эш кушасыз, шуны эшлибез.

**Зәлилә:**

Әллә, дусларым, гафу итәбезме? Гаепләрен аңладылар шикелле. Әкәмәт, нишлибез? Син - аланның хуҗасы.

**Әкәмәт:**

Башта җыештырсыннар, эшләсеннәр. Хезмәт кешене тәрбияли генә. Әйдәгез, җыештырырга урын күрсәтәм. *(Шалтай белән Балтайны алып чыгып китә.)*

**Көяз:**

Әйдәгез, бәйрәм ясыйбыз. Дуслашу хөрмәтенә - дуслык бәйрәме. Ел саен дуслар белән бергәләп уздырырбыз.

**Дуслар:**

Бик дөрес, Көяз! Каян уйлап таба белдең. Әйдәгез, тегеләр килгәнче әзерләнәбез. *(Әкәмәт белән Шалтай-Балтай килеп чыгалар.)*

**Әкәмәт:**

Әйе, бик тырышып эшләделәр. Гафу итәргә була. Тагын да булышырга киләбез дип, сүз бирделәр.

**Зәлилә:**

Димәк, бәйрәм! Җырлыйбыз, биибез, күңел ачабыз... Эш беткәч, уйнарга ярый!

**Әкәмәт:**

(*матур музыка уйный) Бүген аланда бәйрәм,*
*Уйнашыйк әйлән-бәйлән.*
*Якын дуслар бүгеннән,*
*Барысы чын күңелдән.*

Дуслар, әйдәгез, үзебезнең милли бәйрәмнәребездә - Сабантуй, Нәүрүз, Сөмбелә бәйрәмнәрендә - яратып уйнала торган уеннарыбызның берсе - «Түбәтәй» уенын уйнап алабыз.

**Барысы бергә:**

Әйдәгез, әйдә. *(«Түбәтәй» уенын уйнау.)*

**Рудин:**

Җырлы-биюле уеныбызны да онытмыйк.
*Менә сиңа - уң кулым,*
*Менә сиңа - сул кулым.*
*Менә сиңа - якын дустым,*
*Менә сиңа - куш кулым!*
*Эх, Зиләм, Зиләле,*
*Сандугачым, кил әле!*
*Кил әле, дустым, кил әле,*
*Икәү әйләник әле!*

**Әкәмәт:**

Әгәр дә дусларым риза булсалар, без сезне үз командабызга алабыз. «Алан сакчылары» дигән эмблемаларны бүләк итәбез. *(Рудин муеннарына эмблема тага.)*

**Көяз:**

*Ышанычны аклагыз,*
*Туган якны саклагыз!*
*Без - табигать баласы,*
*Безгә үрнәк буласы.*

**Рудин:**

*Яшәсен урман-кырлар,*
*Күктә тургай сайрасын.*

*Гөлчәчәкләргә күмелсен,*
*Яшәсен Туган ягым!*

*Әкрен генә көй уйнатыла, геройлар түгәрәкләнеп басалар һәм күмәк «Кояшлы ил» җыры башкарыла.*

*Тәмам.*

***Тарханова Гүзәлия Инсаф кызы***
*Татарстан Республикасы, Казан шәһәре Вахитов районы 96 нчы гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## “Хан кызы”

**Катнашалар:**

*Ак хан – шаян, кешелекле хан.*
*Гөлсылу – Ак ханның кызы.*
*Ак вәзир – хан кебек яхшы күңелле, хан ярдәмчесе.*
*Булат батыр – вәзирнең улы.*
*Кара хан – зур корсаклы, ямьсез хан, сихерчеләр затыннан.*
*Кара вәзир – усал котыртучы, Кара ханның ярдәмчесе.*
*Кара ханның сакчылары*
*Өч башлы дию*
*Убырлы карчык*
*Аккош*
*Каракош (бөркет) – Кара ханның яңача гәүдәләнеше.*
*Кара карга – Кара вәзирнең яңача гәүдәләнеше.*
*Убырлының кара мәчесе*

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Булат батыр һәм Гөлсылу бакчада куышып уйныйлар.*

**Булат:** Гөлсылу, тукта әле, бер сүз әйтәм.

**Гөлсылу:**Я, ни диярсең?

**Булат:** Син минем кәләшем булырга ризамы?

**Гөлсылу:** *(оялып башын ия)* Риза. Булат, күр әле, дөнья нинди матур!

**Булат:** Ул син булганга матур, Гөлсылу.

**Булат батыр**:

*(җырлый) Йөрәгемә утлар салдың,*
*Сылуым, кызгансана.*
*Таң былбылым, алсу гөлем,*
*Гомерлек яр булсана.*

**Гөлсылу:**

*(җырлый) Сөям сине, Булатым,*
*Мәхәббәт утым сүнмәс.*
*Мин бәхетле синең белән,*
*Яратуым сүрелмәс.*

**Булат**: *(кинәт исенә төшереп)* Гөлсылу, мин бүген хан кушуы буенча чит җирләргә китәм.

**Гөлсылу:** Атам сине ник җибәрә?

**Булат:** Анда яшәүче дусларыбызга ярдәм итәргә кирәк. Гөлем, сиңа нинди бүләк алып кайтыйм?

**Гөлсылу:** Миңа бүләк кирәк түгел, үзең исән-сау кайт.

**Булат:** Мин озак тормам, Гөлсылу.

**Гөлсылу:** Мин сине көтәрмен. Тик син сак бул.

**Булат:** Минем хан һәм атам белән саубуллашасым бар.

**Гөлсылу:** Әйдә, алар янына бергә керәбез. *(Чыгалар.)*

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Ак хан сарае. Хан белән вәзир- икесе дә һәрвакыттагыча тапкыр, шаян, бер-берсен бер сүздән аңлыйлар.*

**Ак хан:** Вәзир, безнең балалар үсеп бетте, сизәсеңме?

**Ак вәзир:** Ә без картаябыз.

**Ак хан:** Нинди карт аю? Кайда ул? *(Эзләгән кебек кылана.)* Карт аю урманда гына яши.

*Ак вәзир рәхәтләнеп көлә.*

**Ак хан:** Ә синең уйлаганың бармы?

**Ак вәзир:** Ни турында, ханым-солтаным?

**Ак хан:** Минем кызым белән синең улың пар икән.

**Ак вәзир:**Бер-берсенә яр икән.

**Ак хан:** Ак хан белән вәзирнең...

**Ак вәзир:** Кода буласы бар икән. *(Көлешәләр.)*

**Ак хан:** Шәпме?

**Ак вәзир:** Шәбен шәп тә, хан белән вәзир баласының кавышканы юк әле.

**Ак хан:** Безнең балалар табышкан.

**Ак вәзир:**Табышкан да кавышкан.

**Ак хан:** Кайчан туй ясыйбыз?

**Ак вәзир:**Ата каз күкәй салгач, тышта кызыл кар яугач.

**Ак хан:** Акылың алтын икән, киләсе язның быелгы көзендә лутчы булыр.

**Ак вәзир:** Мин риза.

*Гөлсылу белән Булат керә.*

**Булат:** Ханым, миңа юлга чыгарга вакыт.

**Ак хан:** Әйе шул. Сез бик вакытлы кердегез әле, балалар.

**Гөлсылу:** Ни бар, атам?

**Ак хан**: *(икесенең дә кулыннан тотып)* Без сезне кияү белән кәләш дип игълан иттек.

**Ак вәзир:** Әйе, мин кул куйдым.

**Ак хан:** Мин мөһер суктым. Менә, күрегез. *(Кәгазьне күрсәтә.)*

**Булат, Гөлсылу**: *(аталары алдында тезләнеп)* Рәхмәт сезгә. *(Аталары балаларын кочаклап алалар.)*

**Аталары:** Бәхетле булыгыз, оланнар.

**Ак хан:** Булат, син кайткач, туй ясарбыз.

**Булат:** *(хан белән атасына баш иеп):* Баш өсте, ханым. Рәхмәт, атам.

*Булат белән Гөлсылу җырлыйлар.*

*Бергә үтте балачак,*
*Яшьлек көннәре җитте.*
*Сине миңа бүләк итеп,*
*Мәңгелек ярым итте.*

*Ак хан белән Ак вәзир җырлыйлар.*

*Балам минем, багалмам,*
*Бердәнберем, күз нурым.*
*Сөйгән ярың белән бергә*
*Үтсен гомерең юлы.*

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Кара хан сарае. Кара вәзир керә.*

**Кара хан:** Илдә ниләр бар, Кара вәзир?

**Кара вәзир:**Тирә-як әмирләре, ханнары җиңелде, гаскәрләре юк ителде.

**Кара хан:** Бар да түгел. Ак хан бик көчле, аны җиңү авыр булачак.

**Кара вәзир:** Сихереңне кулланып кара.

**Кара хан:** Мин сине кара каргага әйләндерә алам, шуннан да зуррак сихергә көчем җитми хәзер.

**Кара вәзир:** Син үзең дә зур бөркеткә – каракошка әйләнә аласың.

**Кара хан:** Ак ханны алай гына җиңеп булмас. Сихер көчемне арттыру өчен, яшәртә торган дару кирәк миңа.

**Кара вәзир**: *(хәйләкәр елмаеп)* Аны тапсак, син Ак хан кызы Гөлсылуга да өйләнә алачаксың.

**Кара хан:** Башың эшли, вәзир, тик Ак хан миңа кызын бирмәячәк.

**Кара вәзир:** Ә син хат яз, куркыт, көч куллан.

**Кара хан:** Бу шәп идея! Бар, каләмемне алып чык. *(Вәзир керә.)*

**Кара хан:** Ха-ха-ха. Ак хан илен басып алачакмын. Мин ул – бөек хан!

**Кара хан**:

*(җырлый) Кара хан мин, батыр хан,*
*Юлымда торма Ак хан.*
*Барыбер сине җиңәрмен,*
*Планнарыңны өзәрмен.*
*Чибәр кызың Гөлсылу*
*Минем кәләшем булыр.*
*Илең һәм байлыгың киткәч,*
*Исемең дә онытылыр.*
Ха-ха-ха.

**Кара вәзир:** Ханым, менә кара савыты белән каләм.

**Кара хан:** Яз.

**Кара вәзир:** Ни языйм?

**Кара хан:** Син минем вәзирем, үзең белеп яз.

**Кара вәзир**: *(тиз-тиз яза)* Менә булды да.

**Кара хан**: *(кесәсеннән тылсымлы таягын чыгарып)* Кара вәзир, мин сине каргага әйләндерәм, "әһ" дигәнче, хатны Ак ханга тапшырып кайт.

**Кара вәзир:** Баш өсте, Кара хан.

**Кара хан:** Әфсен-төфсен, сихерем көчәйсен. Кара вәзир бетсен, зур каргага әйләнсен. *(Таягы белән орына.)* Оч.

**Кара вәзир:** *(каргага әверелеп оча)* Ка-р, ка-р, ка-р.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Ак хан белән Ак вәзир балконда чәй эчеп утыралар. Кара карга очып куна.*

**Ак вәзир:** Күрче, нинди ямьсез карга. Көш-көш, сиңа башка урын беткәнме әллә?

**Кара карга:**Кума мине. Мин Кара ханның илчесе, илчегә үлем юк. Ак ханга хат китердем.

**Ак хан:** Кара, кара, сөйләшә торган карга. Бир хатыңны.

**Кара карга:** Кесәмнән ал. (*Вәзир хатны ала.)*

**Ак хан:**

Укы, ни язган? *(Вәзир укый.)*
*Мин, Кара хан, явыз хан,*
*Сүзем көмешкә торыр.*
*Чибәр кызың Гөлсылу*
*Минем ханбикәм булыр.*
*Әгәр риза булмасаң,*
*Җиңәрмен көчем белән.*
*Илеңне туздырырмын,*
*Үзеңне кудырырмын.*

**Ак хан:** Бу ни бу? Картаеп беткән Кара хан Гөлсылуга өйләнергә телиме?

**Ак вәзир:**Аһ, юньсез бу Кара хан, аһ, мәкерле Кара хан.

**Ак хан:** Бар дип тә белмим боерыгын.

**Ак вәзир:** Тотсын ишәк койрыгын.

**Ак хан:** Кара хан минем дә соңгы сүземне ишетсен. Мин әйтеп торам, син яз. (*Ак вәзир тиз-тиз яза.)*

**Ак хан:**
*Кара хан дигән явыз*
*Минем киявем булмас,*
*Кызымны күрә алмас.*
*Гөлсылуым, багалмам,*
*Бердәнберем, күз нурым,*
*Мәңге аңарга бармас.*
*Көчкә каршы көч булыр,*
*Минем илем нык торыр.*
*Бер пот тоз ашасаң да,*
*Син мине җиңә алмассың,*
*Сүзем алтынга торыр.*

**Ак вәзир:** Шәп әйттең, ханым-солтаным. Мә, ал хатны, Кара карга.

**Кара карга:** Сал кесәгә.

**Ак хан:** Җавап кирәк түгел. Бүтән монда килеп йөрмә.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Кара хан сарае. Кара карга очып кереп, Кара вәзиргә әйләнә.*

**Кара хан:** Әмеремне үтәдеңме?

**Кара вәзир:** Мә, Ак хан хат бирде.

**Кара хан**: *(укый, укыган саен ярсый бара)* Бер пот тоз ашасаң да, син мине җиңә алмассың, дигәнме? Аһ, син мине мыскыл иттең, Ак хан. Мин үч алачакмын!

**Кара вәзир:** Ничек итеп?

**Кара хан:** Хан кызын урлыйм. Кызын коткару өчен, Ак хан минем бар теләгемне дә үтәячәк. Син Гөлсылуны күрдеңме?

**Кара вәзир:** Күрдем. Бакчада иде.

**Кара хан:** Алып чык минем кара япмамны (плащымны).

**Кара вәзир:** Мә *(Кидерә).* Нишләргә уйлыйсың?

**Кара хан:** Карап тор, күрерсең. *(Кара япмасын бөркәнеп, каракошка әверелә. Гөлсылу утырган бакчага очып төшә дә, кызны алып оча. Ак ханга кычкыра.)*

**Каракош:** Ха-ха-ха. Ак хан, өч көн эчендә яшәртә торган дару тапмасаң, кызыңны мәңге күрмәссең. Ха-ха-ха. Мин, Кара хан, сине җиңдем. Ха-ха-ха.

**Ак хан:**Кызым, Гөлсылуым, бердәнберем.

**Ак вәзир**: Ханым, тынычлан. Безгә Гөлсылуны коткару турында уйларга кирәк.

*Булат кайтып керә. Атасының соңгы сүзләрен ишетеп кала.*

**Булат:**Гөлсылуны коткарырга? Кемнән коткарырга?

**Ак хан:** Кара хан кызымны урлап качты. Яшәртә торган дару табып китерергә кушты. Бар ышаныч синдә, Булат батыр.

**Булат:** Мин бүген үк юлга чыгам, тик яшәртә торган даруны кайдан табарга?

**Ак вәзир:** Ашыгып ашка пешмик, улым. Уйлап эшләргә кирәк. Мин сиңа барын да өйрәтермен. Юлга әзерлексез чыгарга ярамый. Ханым, син ял ит.

*Ике яктан ханны култыклап, тәхеткә утырталар.*

**Ак вәзир:** Улым, яшәртә торган даруны табу авыр. Сиңа акыл белән җиңәргә туры килер.

**Булат:** Атам, мин барын да эшләрмен.

**Ак вәзир:** *(кесәсеннән курай алып)* Бу - тылсымлы курай. Аңа әмер биреп уйный башлауга, дошманнарың син теләгәнне эшләр. Ә менә бу бәлзәм яраларыңны төзәтер, мә, ал. *(Шешә белән курайны бирә.)* Хәерле юл сиңа, Булат улым.

**Булат:** (*ук-җәя ала)* Мин киттем, атам, көтегез. *(Чыга.)*

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

*Булат керә. Аккош тавышы ишетелә.*

**Булат:** Адашкан аккош, ахры. Сине кем яралады, Аккошкай?

**Аккош:** Усал тилгән юлымны бүлде. Канатымны каерды, мине парымнан аерды.

**Булат:** Кайгырма, гүзәл Аккош. Син парыңны табарсың, мин синең яраңны төзәтәм. *(Бәлзәм алып, канатына сөртә.)* Булды, Аккошкай.

**Аккош:**Рәхмәт, игелекле егет. Мә, каурыемны ал, аны учыңа сал. Ул син нәрсә әйтсәң, шуны үтәр. (Аккош *очып китә.)*

**Булат:**Каурый, оч, миңа юл күрсәт.

*Каурый оча, Булат аның артыннан бара, өч башлы дию янына килеп чыга. Уң һәм сул башлары як-якка авышкан, ярым йокы хәлендә. Уртадагысы нык ютәлли.*

**Булат:** Дию иленә килеп чыктым. Исәнме, дию пәрие.

**Уң баш:** Адәм баласы, ник мине борчып йөрисең?

**Сул баш:** Ничек интегүемне күрмисеңме әллә?

**Урта баш:**Үләм, үләм. Тамагым авырта. *(Ютәлли, ул ютәллләгәндә, тегеләре читкә борылалар).*

**Булат:** Күрәм: эшегез шәптән түгел.

**Уң баш:** Коткар безне бу бәладан.

**Сул баш:** Биш көн, биш төн йоклаганыбыз юк.

**Уң баш:** Ашыйсы да килә.

**Булат:** Ни булды соң?

**Уң баш:** Менә бу комсыз бертуктаусыз туңдырма ашады.

**Сул баш:** Безгә дигәнне дә урлап йоткан. Тамагы шешеп, көн-төн ютәлли.

**Уң баш:** Башны кая алып качыйк?

**Сул баш:** Шундый хәлсезләндек, синең белән сугышырлык рәтебез дә юк.

*Болар сөйләгәндә, урта баш гел йөткерә.*

**Сул баш:** Егет, син коткармасаң, үтерә бу безне. *(Урта башка төртә.)*

**Уң баш:** Җитәр инде сиңа. *(Каты итеп төртә.)*

**Булат:** Ярый, коткарырмын, тик сез миңа яшәртә торган даруны ничек табарга икәнен әйтәсез.

**Урта баш:** Аны әйтергә ярамый. Ул - бөек сер.

**Булат:**Ярый, киттем алайса, хушыгыз.

**Уң, сул баш**:*(икесе бергә)* Зинһар, китмә. *(Урта башны ике яклап төрткәлиләр.)* Үләсең килмәсә, әйт, яшермә.

**Урта баш:** Ул дару... *(Ике баш тагын төртәләр.)* Аның турында Убырлы карчык кына белә. Ул әйтер.

**Булат:** Ярый. Мин сине терелтәм, тик тагын бер шартым бар.

**Өчесе бергә:** Анысын да үтибез, әйт.

**Булат:** Сез кешеләргә начарлык эшләмәскә тиешсез.

**Өчесе бергә:** Начарлык эшләмәбез, берсенә дә тимәбез.

*Булат бәлзәм алып эчертә. Урта башның ютәлләве бетә.*

**Булат:**Бу тылсымлы бәлзәм, тик син туңдырманы күп ашама.

**Өчесе бергә:** Рәхмәт, батыр егет. Хәзер без рәхәтләнеп йоклый алабыз.

**Булат:**Мин курай уйныйм, сез тынычлап йоклагыз. (*Уйный. Дию пәриенең башлары тавыш чыгарып исниләр, йоклап китәләр.)*

**Булат:** Йоклыйлар. *(Учына каурый сала).* Каурый, юл күрсәт, Убырлы карчык янына алып бар. *(Каурый артыннан чыга.)*

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Убырлы карчык өе. Булат керә.*

**Булат:** Исәнме, әбекәй.

**Убырлы:** Нинди әби булыйм мин сиңа? *(Боргаланып, зур күзгедән карый.)* Миңа әле 200 яшь тә тулмаган. Ник килдең?

**Булат:** Миңа яшәртә торган дару кирәк.

**Убырлы**: *(Булатның мускулларын капшый-капшый әйләнеп чыга)* Син болай да бик яшь. Нишлисең аның белән?

**Булат:** Кара хан минем кәләшемне урлады. Яшәртә торган дару китермәсәм, ул аны сихерләячәк.

**Убырлы:** Теләгән даруыңны бирермен, тик өч шартымны үтә.

**Булат:**Әйт шартыңны.

**Убырлы:**Минем кара мәчем өч көннән бирле агач башыннан төшми.

**Булат:** Кыйнадыңмыни?

**Убырлы:** Сүз тыңламый. Хәзер менә җиргә дә төшми. *(Булат угын мәчегә төзи.)*

**Убырлы:** Атма.

**Булат:** Мин аңа атмыйм, куркытам гына. Карап тор, ничек төшкәнен сизми дә калырсың. *(Мәче, куркуыннан мияулап, Убырлы кулына сикереп төшә.)*

**Убырлы**: *(мәчесен орышып)* Кара аны, тагын бер тапкыр сүземне тыңламасаң, тычканга әйләндерермен.

**Булат:** Икенче шартыңны әйт.

**Убырлы:** Өч көн ашаганым юк. Мәчем белән минем тамагыбызны туйдыр. Өстәлдә төрледән-төрле ашамлык, җиләк-җимеш булсын.

**Булат:** Ярый, үзем дә ашап алырмын. *(Каурыен чыгарып, әмер бирә.)* Каурый, ашамлык тулы өстәлгә әверел. *(Төрле ризык белән тулган өстәл барлыкка килә.)*

**Булат:** *(өстәл янына утыра)* Утырыгыз, рәхәтләнеп ашагыз.

**Убырлы:** Шәп өстәл. Мондый ашамлыкларны гомердә күргәнем юк. *(Ашый.)* Өч көнлек ашадым, селкенә дә алмыйм. Өстәлеңне миңа калдырырсың.

**Булат:** Юк, калдыра алмыйм. Ул минем әмерне генә үти. Өстәл җыел, каурыйга әйлән. *(Каурыйны кесәсенә сала.)* Ә син, Убырлы, бушка ашатканга риза бул.

**Убырлы:** Алайса, өченче шартымны үтә. *(Оча торган кисмәген күрсәтә.)* Минем оча торган машинамның руле ватылды. Тизлеге дә начарайды. Төзәтә аласыңмы?

**Булат:** Шәп машина. Чит илнекеме? Себеркең кайда соң?

**Убырлы:** Ә, рульне әйтәсеңме? Мә.

**Булат:** Рулең яхшы синең. Рычагың гына черегән. Аны алыштырырга кирәк. Әнә теге корыган таякны бир. *(Егет аны кисмәк эченә тыга.)* Булды. Оч рәхәтләнеп.

**Булат:** Убырлы, яшәртә торган даруыңны бирәсеңме?

**Убырлы:** Бирер идем дә, миндә түгел бит ул.

**Булат:** Аһ, син мине алдамакчы буласыңмы?

**Убырлы:** Андый дару минем үземә кирәк. Эшең бетте, бар, юлыңда бул.

**Булат:** Син яхшылыкка начарлык белән җавап бирәсеңме?

**Убырлы:**Мин – эгоист. Үзем турында гына уйлыйм.

**Булат:**Алайса, мин сине акылга утыртам, бертуктамыйча бие дә бие.

*Булат курай уйный. Убырлы үзеннән-үзе бии башлый, һич туктый алмый.*

**Булат:**

Бие, бие, Хәйбулла, биегән кеше бай була.

**Убырлы:**

Тукта, зинһар, уйнама, үтерәсең. Даруны бирәм мин сиңа. *(Булат туктый. Убырлы кесәсеннән шешә чыгарып бирә.)*

**Булат:**

Рецепты бармы?

**Убырлы**:

*(ах-ух килә, билләрен уа)* Карт кеше бу даруны бер йотым эчә дә, яшь кешегә әверелә. Артыгын эчсә, яшь балага әйләнә.

**Булат:**

Әллә кайчан шулай эшләргә иде. Тагын биисеңме?

**Убырлы:**

Юк-юк, зинһар, кит, мин кереп ятыйм. Мәчем дә арыган.

**Булат:**

Сау бул, әбекәй. *(Учына каурый салып)* Каурый, мине Кара хан янына алып бар. *(Каурый артыннан чыга.)*

СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Кара хан Кара вәзир белән сөйләшеп утыра.*

**Кара хан:** Гөлсылу бүген дә ни ашамады, ни эчмәде.

**Кара вәзир:** Ачка үлмәгәе.

**Кара хан:** Аның кирелеген ничек җиңәргә? Бар, чакыр бирегә, тагын бер сөйләшеп карыйм әле. *(Вәзир чыга һәм Гөлсылуны алып керә.)*

**Кара вәзир:** Ханым, алып кердем. Почмакка карап утыра, мәрткә киткән диярсең.

**Кара хан:** Соңгы кат сорыйм: минем кәләшем булырга ризамы син?

**Гөлсылу:** Мин үлсәм үләрмен, тик беркайчан да синеке булмам.

**Кара хан:** Тиздән мин яшәртә торган дару эчеп, яшь егеткә әйләнәчәкмен.

**Гөлсылу:** Күпме тырышсаң да, минем сүзем бер: мин мәңге синеке булмам.

**Кара хан**: *(ачуына буылып)* Риза булмасаң, иртәгә каргага әйләндерәм мин сине.

**Гөлсылу:** Миңа барыбер.

**Кара хан:** Сакчы, зур манарага кертеп яп. Миңа булмый икән, башкага да булмас.

**Сакчы:** Баш өсте, ханым. *(Гөлсылуны алып чыга)*.

**Кара вәзир:** Бу кыз сиңа рәхәт күрсәтмәс. Атасына кайтарып җибәр, ханым.

**Кара хан:** Юк, мин риза түгел. Өч көн үтте. Бүген Ак хан яшәртә торган дару җибәрергә тиеш. Әмеремне үтәмәсәләр, бу кызны манарада бикләп тотачакмын.

**Сакчы:** *(керә)* Ханым, бер егет керергә тели.

**Кара хан:** Керсен (*Булат керә).*

**Кара хан:** Син кем?

**Булат:** Ак хан кушуы буенча сиңа яшәртә торган дару китердем.

**Кара хан**: *(сикереп тора)* Кайда ул, китер тизрәк.

**Булат:** Ак хан иң элек кызы Гөлсылуны күрергә кушты. Исәнме ул?

**Кара вәзир:** Исән, исән. Алып керикме, ханым?

**Кара хан:** Алып керегез. *(Сакчы белән Гөлсылу керә).*

**Кара хан:** Күр, егет, бу – хан кызы. *(Булат кызга күз кыса. Кыз аңлый, дәшми кала.)* Китер даруыңны. Гөлсылу, мин хәзер яшь егеткә әйләнәчәкмен, карап тор.

**Булат:** Тик бер генә йотым эч.

**Кара хан:** Өйрәтмә мине, үзем белермен. Бу даруны мин озак эзләдем. Башкаларга калмасын. (*Кара хан даруны эчеп бетерә. Бар да карап торалар.)*

**Кара хан:** Эчеп бетердем. Күрегез, мин хәзер яшь егеткә әйләнәм.

*Кара хан юкка чыга. Тәхеттә яшь бала барлыкка килә. Ул елый.*

**Кара вәзир:** Егет, син нишләттең ханны? Бу бит Кара хан түгел, сабый бала.

**Булат:** Ишеттең, мин аңа әз генә эчәргә куштым. Ул барын да эчеп бетерде.

**Гөлсылу:** *(рәхәтләнеп көлә)* Бар иде хан, юк булды хан. Комсызлык яхшыга илтми. Кара вәзир, сиңа бәби ханны үстерергә кала.

**Кара вәзир:** *(бәбине алып, кызга суза)* Гөлсылу, син аңа ана булырсың, ал.

**Гөлсылу:** Үзеңә ал, ул синең ханың. Минем үз балаларым булыр.

**Булат:** Дөрес, Сылуым.

**Кара вәзир:** Бу хыянәт. Сакчылар, тотып бәйләгез үзләрен.

**Булат:** *(кураен чыгарып)* Тик торыгыз. Кураем, уйна. Боларны йоклат.

**Кара вәзир:** *(баланы кулына ала)* Нишләрмен мин, Кара хан? Ничек үстерермен сине? Сабыем, йокла инде, елама, ә-ә-ә. (*Үзе дә, башкалар да йокыга талалар.)*

**Булат:**

Киттек, Гөлсылу. Болар безгә куркыныч түгел хәзер. *(Әмер бирә.)* Каурый, безгә Ак хан сараена туры юлны күрсәт. *(Ак хан сараена килеп чыгалар.)*

**Гөлсылу:**

*(атасын кочаклап ала)* Атам, мине Булат Кара ханнан коткарды.

**Ак хан:**Ул явыз тагын килмәсме соң?

**Булат:**Ханым, Кара хан үсеп җиткәнче, күп еллар узар әле.

**Ак вәзир:** Ни сөйлисең, улым?

**Булат:** Ул яшәртә торган дару эчеп, яшь балага әйләнде. *(Бар да көлә.)*

**Ак хан:** И балалар, гыйбрәт алыгыз. Яшьлекнең дә, картлыкның да үз вакыты бар. Кара хан яшьлегенең кадерен белмәде. Күңеле начарлыкта булды.

**Ак вәзир:**Яшьлектә матур итеп яшәгез, балалар. Дөресме, Ак хан?

**Ак хан:** Дөрес, Ак вәзир. Безнең кебек матур яшәгез, балалар. Күңелегез ак булсын, чиста булсын.

**Ак вәзир:**Бер-берегезне, ата-аналарыгызны яратыгыз! Намуслы яшәгез!

**Булат, Гөлсылу:** Ә без бүген бәйрәм итәбез. Барыгыз да рәхим итегез!

*Күңелле музыка уйный. Бар да бииләр.*

*Тәмам.*

***Зарипова Рәмилә Рәвил кызы***

*Татарстан Республикасы, Алабуга муниципаль районы “1нче гимназия – Милли белем бирү үзәге”нең беренче квалификацион категорияле тәрбиячесе*

## “Аулак өй”

**Максат:** балаларда халкыбызның йола бәйрәмнәренә кече яшьтән кызыксыну уяту.

**Бурычлар:** - балаларны милли йолалар белән якыннан таныштыруны дәвам итү;

- сөйләм телен үстерүгә һәм иҗади сәләтләрен ачарга булышлык итү;

- халык авыз иҗаты әсәрләренә кызыксыну уяту, туган телебезгә, халкыбызның йола бәйрәмнәренә хөрмәт хисләре тәрбияләү.

**Зал бизәлеше:** зал түрендә өйнең эчке күренеше - мич, анда борынгы сандык, чиккән мендәрләр, сөлгеләр, бишек, идәнгә тукылган палас җәелгән, өстәлдә самовыр белән чынаяклар.

*Талгын гына татар көе уйнап тора, сәхнә ачылып китә. Әни кеше баласын тибрәтә һәм “Бишек җыры”н көйли башлый. Әти кеше итек ямый. Әби каба янында йон эрли. Кызлар үз эшләре белән мәшгульләр.*

**Әти:** Кара әле, әнисе, булды бу. Тагын ямыйсы итекләр бармы?

**Әни:** Менә Милананыкын да ямап куй әле, икенче кышка әзер булып торсын.

*Әти кеше эшен дәвам итә.Талгын гына көй уйный.*

**Әти:**Мә, әнисе, алып куй *(әти торып баса, як-ягына карана, кызларны сөеп ала).* Кара әле, әнкәсе, мин әйтәм, әллә берәрсенә кунакка барып кайтыйкмы? Көннәр дә бик матур тора. Язгы эшләр башланганчы дип әйтүем.

**Әни:** Бик яхшы булыр иде, әтисе!

**Әти:** Юраш җизниләрне дә күптән күргән юк.

**Әни:** Әйе шул, көн салкын дип, беркая чыккан юк. Бик яхшы булыр иде.

**Әти:** (*әбигә борылып*) Әни, син дә барасыңмы?

**Әби:** Юк, юк, балакайларым, барыгыз үзегез генә йөреп кайтыгыз. Без кызлар белән өйдә генә калабыз. Әйеме, кызлар?

**Кызлар:** Әйе, әйе.

**Әти:** *(киенә)* Ярар, мин ат җигә торам, чыгарсыз (*чыгып китә*).

*Әни, баласын бишектән алып, җырлый-җырлый төрә башлый. Кечкенә баланы әби кулга ала. Әни киенә.*

**Әни: (***кызларга)* Кызым, берүк без китте дип, егетләр җыеп, аулак өй ясап ята күрмәгез тагын!

**Милана:** Юк, әнием, юк, бер дә борчылмагыз!

**Әни:** *(әбигә)* Ярый, әни! Исән-сау гына торыгыз, без барып кайтыйк инде. Кызлар синең белән кала .

**Әби:** Иркенләп йөреп кайтыгыз, безнең өчен бер дә борчылмагыз. Күп итеп сәлам әйтегез.

*Чыгып китәләр, әби озата чыга. Ат кешнәгән тавыш, кыңгырау чыңлаганы ишетелә. Кызлар тәрәзәдән озатып кала.*

**Милана (***телефонын алып*) И бу телефон тагын әллә нишләгән?

**Элина:** Көн буена уйнагач, шулай була ул.

**Гөлназ:** Ярар, әйдәгез, гел телефонда утырмагыз. Эшләрегезне карагыз.

*Тыштан утын күтәреп, әби килеп керә. Утынын мичкә ата да, кызлар янына килә.*

**Әби:** Я, кызлар, нишлибез инде хәзер.

**Элина:** Әбием, әйт әле, нәрсә соң ул “аулак өй”? Әни нигә шулай дип кисәтте?

**Гөлназ:** Чыннан да, әбием, сөйләп бир әле.

**Әби:**И кызым! Аулак өй ул – җыелып, уен- көлке, җырлар, уеннар уйный торган бер урын иде. Менә шундый аулак өйнең берсендә бабагыз белән танышып кавыштык та инде. (*Музыка бара, әби сөйли, аңлата, сандыгыннан кул эшләре алып күрсәтә.)*

**Милана:** Әбием, әйдәгез без дә аулак өй ясап, күңел ачып алыйк.

**Әби:** Юк, кызым, әти – әниеңнәр ишетсә, орышырлар бит.

**Кызлар:** Әбием – әбекәем, зинһар өчен *(кочаклыйлар, ялыналар)*.

**Элина:** Әбием, без сиңа багышлап бер җыр өйрәндек.

**Әби:** И, хәйләкәр дә инде үзләре, ягез, тыңлап карыйм.

Җыр: “Әбием – әбекәем”

**Әби:** И, рәхмәт, кызларым! Бигрәк матур җыр тыңлаттыгыз. Ярый инде алайса, мин Хөсникамал әбиеңнең хәлен белеп чыгармын, ә сез берничә иптәш кызларыгызны чакырып, кич утырып алыгыз. Егетләр кертәсе түгел! Әнә, Гөлназ апагызга өйрәткән чигү үрнәкләрен исегезгә төшереп, кул эше эшләрсез *(төенчегеен алып чыгып китә)*.

**Кызлар:** Ура-ура! Аулак өй, аулак өй! *(Урын-җирләрен рәтлиләр, өстәлне күчереп куялар, почмактан почмакка йөгереп, телефоннан кызларны чакыра башлыйлар)*.

- *Алло, Сафия, ишетәсеңме, бездә бүген аулак өй, кил, яме!*
- *Алло, Розалина, бездә бүген аулак өй, кил яме! Зәлия белән Амираны да ал, ярыймы?*
- *Алло, Алсу апа! Бездә бүген аулак өй, керегез яме, керегез!*

*Җиңелчә көй яңгырый, кызлар керә,кулларында пешкән ризыклар.*

**Кунак кызлары:** Хәерле кич, кызлар!

**Милана:** Әйдәгез, кызлар, рәхим итегез!

**Гөлназ:** Ягез, кызлар, бераз кулларны язып, чигеп, җырлап алыйк булмаса. (*Чигәргә утыралар, җырлыйлар* )

Җыр “Кулъяулыклар чигәм”

*Еракта егетләрнең “Эх, сез матур кызлар”җырын җырлаганы ишетелә.*

**Милана**: Кызлар, кызлар, егетләр килә! (*Кызлар өс-башларын тәртипкә китерәләр.)*

*Егетләр ишек шакыйлар.*

**Малайлар:** Кызлар, аулак өйгә безне дә кертегез әле!

**Кызлар:** Юк, кертмибез.

**Малайлар:** Кертегез инде.

**Кызлар:**Юк, кертмибез.

**Малайлар:**Ярар инде, кыланмагыз.

**Кызлар:**Кызлар нишлибез?
**Кызлар:** Кертик.
**Гөлназ:** Кергәнсез бит инде.
**Малай:**
*Кызлар, исәнмесез, саумысыз,*
*Нигә кәжҗә саумыйсыз?*
*Әтәчегез күкәй салган,*
*Нигә чыгып алмыйсыз?*
**Кызлар:**Һи, булмаганны, әтәч күкәй саламени?
**Малайлар** *(көләләр)*.
**Кызлар:** Бездән сезгә ни кирәк?
**Малайлар:** Чигелгән яулык кирәк.
**Кызлар:** Аның белән нишлисең?
**Малайлар:** Әнигә килен кирәк (*малайлар көлә*).
**Кызлар: (***усаллашып***)** Нәрсә дисез?
**Малайлар:**Шаярттык кына (*көлешәләр*).
**Малайлар:**Кызлар, әссәламүгаләйкүм! (*эчкә атлыйлар*).
**Кызлар:** Вәгаләйкүмәссәлам.
**Кызлар:** Егетләр, сез бии беләсезме?
**Малайлар:** Әлбәттә, беләбез. Әйдәгез, бер биеп алыйк!
**Балалар:** Әйдәгез!
**Малай:**
*Тыпыр-тыпыр тыпырдатып,*
*Бергә басаек әле.*
*Уйнап, көлеп, җырлап, биеп,*
*Күңел ачаек әле.*

Күмәк татар биюе

*Биюдән соң утыралар.*

**Малай:** Менә мине тыңлагыз әле. Мин сезгә “Шүрәле” биштәреннән бер такмак сөйлим.

**Малай:**
Әтәч белән тавык.
*Әтәч менгән киртәгә,*
*“Кикрикүк” итәргә.*
*Әтәчкә дә хәбәр килгән,*
*Армиягә китәргә.*
*Әтәч әйтә, “бармыйм”, - ди,*
*Тавык әйтә, “калмыйм”, - ди.*
*Син армиягә китсәң,*
*Бер күкәй дә салмыйм, - ди.*
**Малай:**
Ә минеке болай.
*Чабатага төялеп.*

*Ике карга карап тора,*
*Себеркегә сөялеп.*
**Малай:** Ә минекен беләсезме соң?
*Ике чеби алып киткән,*
*Безнең чишмә улагын.*
*Берсен әтәч тотып алып,*
*Борган, диләр, колагын.*

*Шигырьләрдән соң рәхәтләнеп көлешәләр.*

**Кыз:** Кызлар, малайлар, әйдәгез, “Чума үрдәк, чума каз” уенын уйнап алабыз.
**Балалар:** Әйдәгез! (*Малайлар кызлар белән парлашып басалар).*

“Чума үрдәк, чүма каз” уены

**Кыз:**
**(***малайларга***)** *Табышмак әйтәм, тыңлагыз,*
*Авызларыгызны ачып тормагыз!*
*Җәен урманда патша,*
*Кышын кардан да аста. (аю)*
*Ишектән керер,*
*Түргә менеп утырыр (суык)*
*Гөлдер, гөлдер, гөлдер бу,*
*Кызыл тәпи - кемдер бу? (күгәрчен)*
*(малайлар дөрес җавап бирәләр)*
**Милана:** Ай-яй, сез бигрәк зирәк икәнсез!
**Булат:**
*Сезне дә сынарга кирәк.*
*Лампа түгел, яктырта,*
*Мич түгел, җылыта? (кояш)*
*Өй артында дөп-дөп кое казый (тамчы)*
**Булат:** И, булдырдыгыз, кызлар.
**Кыз:**
*Ал да булыр чагыбыз,*
*Гөл дә булыр чагыбыз.*
*Без җырламый, кем җырласын,*
*Безнең җырлар чагыбыз.*
-Әйдәгез, кызлар, малайлар! Такмаклар әйтешәбез!
**Балалар:** Әйдәгез!

Такмаклар

**Кыз:** Кызлар, малайлар, әйдәгез, “Капкалы уены”н уйнап алабыз!
**Балалар:** Әйдәгез!

“Капкалы”уены

**Гөлназ:**
Егетләр икешәр кашык белән нәрсә ашарга килдегез?
**Малайлар:** Ашарга түгел, оркестрда уйнарга.
**Гөлназ:** Ягез әле, уйнап күрсәтегез!

Агач кашыклар оркестры

**Малай**:

*Мои ложки росписные,*
*Просто так не удержать.*
*Выбивают позывные –*
*Приглашают танцевать!*

Күмәк рус халык биюе

**Алсу:**Кызлар, егетләр! Әйдәгез әле, бер уен уйнап китик. Уенга ике бала кирәк: кыз, малай. Күзләрне бәйләгән килеш бер-беребезне эзлибез. “Сәлим син кая? Сәлимә син кая?” дип кычкырып, бер-беребезне табабыз. Калган балалар түгәрәккә басып, кулга-кул тотынышалар.

“Сәлим - Сәлимә” уены

*(1-2 бала уйнагач, әби килеп керә, күзен бәйләгән бала (малай) әбине тотып ала. Калган малайлар кайсы кая качып бетә).*

**Әби**: *(көлә)* -И-и-и, яшь чагымда егетләр кочакласа ояла идем, кит әле, кит. Бәрәкалла, тукта әле, кем соң бу? Әллә, чыннан да, малай инде? *(Чалбарын күреп шакката, борылып караса, тирә-юньдә бик күп малай күрә).* И, сөбханалла, монда күп икән бит болар. *(Кызларга таба борыла.)* Сез бит, кызым, миңа кызлар белән генә кич утырабыз дигән идегез. *(Өстәл астыннан бер егетнең чалбарлы аягы күренеп тора).* И-и, ходаем, бусы кем тагын? *(Егетләр качкан җирләреннән чыгалар.)*

**Кызлар:**И-и, әбекәй, без бик тәртипле генә утырдык.

**Кыз:** Син безгә ачуланма инде, әбекәем, үзең дә бит яшь чагыңда аулак өйгә йөргәнсең. Сөйләп кызыктырдың бит.

**Әби:**Йөрдем, балакайларым, йөрдем, менә бит яшь чакларымны искә төшердегез *(күз яшьләрен сөртеп ала)*.

**Кыз:**

*Җырлыйк әле, җырлыйк әле,*
*Җырлап ачыла күңел.*
*Җырлап ачылмаган күңел,*
*Мәңге ачылачак түгел.*

**Әби:** Дөрес әйтәсең, кызым! Җыр кешене юата да, елата да. Менә без яшь вакытта мондыйрак җырлар җырлый идек.Тыңлап китегез әле.

Татар халык җыры “Бөрлегән”

*Ат кешнәгән тавыш һәм кыңгырау чыңлаганы ишетелә.*

**Милана:** (*тәрәзәдән карый да*) Әтиләр кайтты, нишлибез? (*малайларга*) Качыгыз!

*Бер малай аңламыйча уртада кала, аптырап нишләргә дә белми.*

**Әни:** Әллә аулак өй оештырганнар инде?

**Әти:** Кара син боларны...

*Әти, керә-керешкә, теге уртадагы малайны куа башлый. Малай абынып китә, әти аңа таба егыла.*

**Әби:** Тукта әле, кем, улым, үзеңнең яшь чагыңны исеңә төшер... Үзегез дә бит кич җыелып утырыша идегез (*Әби әтине туктатып кала, малайлар качкан җирләрдән чыгалар.)*

**Әти:**
*Ак тавыгым бар иде,*
*Йомыркасы шар иде.*
*Безнең дә бит сезнең кебек,*
*Яшь вакытлар бар иде!*
**Әби:**
*Сандугач кунган киртәгә,*
*Канат кагар иртәдә.*
*Безнең болай утыруны,*
*Сагынырбыз иртәгә.*

**Әби:** Менә шулай итеп, безнең "Аулак өй" кичәбез ахырына якынлашты. Халкыбызның тормыш бизәге булган шундый матур милли бәйрәмнәребез онытылмасын, гореф-гадәтләребез бүгенге көндә дә үз урынын тапсын иде.

***Ибатуллина Фәния Сәгъдулла кызы***
*Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы Шушмабаш балалар бакчасы тәрбиячесе*

**"Каз өмәсе"**

**Максат:** Балаларның татар халык йолалары, бәйрәмнәре турында белемнәрен баету, татар фольклоры белән таныштыруны дәвам итү; каз өмәсе йоласы турында әңгәмәдә катнашу; элекке гореф-гадәтләрне искә төшерү; бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Җиһаз:** «Каз» йолкыр өчен тазлар, чигүле сөлгеләр, бию өчен каурыйлар, урындык, өстәл, самавыр, микрофон, компьютер һ.б.

**Бәйрәм барышы**

*Талгын гына «Каз канаты» көе (татар халык җыры) яңгырый. Зал түрендә авыл өенең эчке як күренеше:өстәл,өстәл өстендә самавыр,сәке тора,чигүле сөлгеләр эленеп тора.*

**Алып баручы:** Хәерле көн, кадерле кунаклар! Бүген без татар халкының онытылып бара торган бер йоласы - Каз өмәсенә җыелдык. Авыл халкы элек-электән күп көч сорый торган эшләрне ирекле рәвештә җыелышып, күмәкләшеп башкарган. Күп каз асраган гаиләләрдә каз өмәсен оештыруны тормыш үзе таләп иткән. Өмәдә, барыннан да элек, кызларның уңганлыгы сыналган. Булачак кайнаналар үзләренә ошаган кызларны шунда билгеләп куйганнар. Борынгы әби-бабаларыбыз казларны бик яратканнар. Күрүебезчә, каз өмәсе - авыл тормышының бер бизәге. Бу гадәтебез яшь буынга кире әйләнеп кайтыр дип ышанасы килә.

**Алып баручы:**
*Көзге байлык! Көзге муллык!*
*Авылда каз өмәсе.*
*Яше-карты, бала-чага -*
*Шау-гөр килә һәммәсе!*

*Бүген бездә каз өмәсе,*
*Каз өмәсе бүген бездә!*
*Каз йолкырга килгән кызлар,*
*Уңыш юлдаш булсын сезгә.*

**Әби:** *(үз-үзенә сөйләнеп керә)* И-и-и, бу эш дигәне гел бетми, һич кенә дә житешеп булмый. Аллага шөкер, казып алган бәрәңгеләрне базга урнаштырдык, инде зур эшләрнең берсе генә калып бара. Авылыбызда каз өмәсе дә бетеп килә, урамда су буеннан кайтучы казлар да кимеде. Алла боерса, бүген чират бездә. Күрше кызларын да чакырдым. Озакламаслар, бик җитез кызлар үсеп килә. (*Ишектән тавыш ишетелә*)

**Алинә:**Исәнме, әбекәй! Әллә казларыңны йолкып та бетердеңме?

**Әби:** Исәнме, кызым. Килеп тә җиттегезмени? Бик иртә кердегез әле.

**Гөлнур:** Шундый матур көз иртәсендә йоклап ятып буламени, әбекәй. Үзең дә әнә барысын әзерләп куйгансың, әллә казан астына да яктыңмы?

**Әби:** Әйе, кызым, суым хәзер кайнап чыга, сез кереп утырыша торыгыз, бабагыз казларны алып кереп бирер, пешекләп йолкый башларбыз.

**Бабай:** *(казлар тотып керә)* Безнең уңган күрше кызлары кереп тә җиткәннәр. Менә сезгә казлар, жырлый-жырлый армыйча эшләгез *(Чыгып китә).*

**Әби:** Балакайларым, иң элек култык астыннан канатларын йолкып алыйк. Аннары яндырырбыз. Хәзер калган канатларын йолкыйбыз. Кая әле, балалар, һәрберегезгә каз бирәм.

**Алинә:**
*Казларыгыз бигрәк матур*
*Таза булып үскәннәр.*
*Ә йоннары, каурыйлары*
*Мамыкланып беткәннәр.*

**Гөлнур:**
*Әбекәем иртә-кичен*
*Нык карады аларны.*
*Тилгәннәрдән, каргалардан*
*Көне буе саклады.*

**Лилия:**
*Үсә төшкәч, су буйларын*
*Бигрәк якын иттеләр.*
*Күрше казлар белән бергә*
*Дуслашып та киттеләр.*

**Алинә:**
*Кызлар, ә сез беләсезме?*
*Каз ярата елганы.*
*Йөзә дә ул, чума да ул,*
*Су үстерә бит аны.*

**Әби:** Бабасы, ал әле гармуныңны, кызлар жырлый-жырлый эшләсеннәр.

«Каз канаты» (татар халык җыры)

*Каз канаты кат-кат була,*
*Кат-кат була, нык була.*
*Чит җирләрдә бик күп йөрсәң,*
*Туган җирләр ят була.*
*Каз канаты каурый-каурый,*
*Коймак майларга ярый.*
*Уйнамагач та, көлмәгәч,*
*Бу дөнья нигә ярый.*

**Бабай:** *(кызлар янына килеп)* Карчык, кара әле, бу кызлар кечкенә генә булсалар да, ничек шәп эшлиләр, кая, мин дә йолкыштырып карыйм әле.

**Әби:** Кит инде, карт җүләр, ир-ат эшеме ул – каз йолку? Кызлар кулы бит ул каз өстендә йөгереп кенә йөри.

**Бабай:** Ярар-ярар. Абзарга чыгып, сарыкларга печән салыйм. Иркенләп, тынычлап эшләгез *(Чыгып китә).*

**Әби:** Балалар, казларның мамыгын аерым, каурыйларын аерым салыгыз. Аллаһы боерса, быел каз мамыгыннан гына мендәр ясыйм әле. Сабир бабагыз яңа, йомшак мендәр сорый *(Көлешәләр)*. Әй, ул каз мамыгыннан гына торган мендәр… Аңа яту белән эреп китәсең инде.

**Гөлнур:** Бабакай эрепләр китәр инде яңа мендәрдә *(Көләләр),* иртән йоклап калмасын.

**Бабай:** *(Гармун тотып керә)* Әйдәгез әле, кызлар, тагын берәр җыр җырлап алыгыз *(Урам якта капка тавышы ишетелә).*

**Илдар:**
*Шыгыр-шыгыр капканы*
*Шыгырдатмый япмабыз.*
*Каз өмәсе булган җирдән,*
*Беребез дә калмабыз.*
*(Керәләр)*

**Малайлар:**
*(бер-бер артлы) Исәнмесез, барыгыз,*
*Бездән сәлам алыгыз.*
*Сәлам, Хәния әбигә,*
*Сәлам, Сабир бабайга,*
*Сәлам, матур кызларга.*

**Бергә:**
Өмә күрке – казларга *(Көлешәләр)*

**Алинә:** *Егетләр, сезгә ни кирәк?*

**Рәмил:**
*Пешкән симез кыз кирәк.*
*Юк ла,симез каз кирәк.*
*Тагын матур кыз кирәк!*

**Алинә:** *Каз казанга төшмәгән.*

**Бергә:** *Егет үзе пешмәгән.(Алинә Рәмилгә сөлге белән суккалый.)*

**Рәмил:**
*Җитәр инде пешердең,*
*Шыбыр тиргә төшердең.*
*Мине, чибәр, итмә инкарь,*
*Елмаеп кара, зинһар!*
**Бабай:** Ай-һай, телгә оста икәнсез.
**Әби:** Безнең заман егетләре түгел инде болар. Үтегез, балакайларым.
**Лилия:** Әбекәй, мин бит күрше егетләрен үзем чакырган идем. Онытмаганнар! Рәхмәт, килгәннәр. *(Малайларга карап)* Казларны йолкып та бетердек. Кызлар, әйдәгез, казларны монда куйыйк. Сабира әби эчләрен караганчы уйнап-җырлап алыйк. *(Казларны өстәлгә, урындыкларын ян-якка алып куялар).*
*(Малайлар, кызлар кара-каршы басалар).*

«Дүдәк» (татар халык җыры)

**Алинә:**
*Күчтәнәчләрем аз гына*
*Үрдәк белән каз гына.*
**Бергә:**
*Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,*
*Басма өстендә каз-үрдәк.*
**Кызлар:**
*Кыйгак-кыйгак,*
**Малайлар:**
*Бак-бак-бак,*
**Бергә:**
*Басма өстендә каз-үрдәк шул,*
*Басма өстендә каз-үрдәк.*
**Рәмил:**
*Җаным кебек дусларыма,*
*Җырлап бирим аз гына.*
*Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,*
*Басма өстендә каз-үрдәк.*
**Илдар:**
*Каз өмәсе бик шәп бәйрәм,*
*Күңел ачыйк әле.*
*Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр*
*Бергә басыйк әле.*

Күмәк парлы бию (заманча көй)

**Әби:** Балакайларым, казлар әзер. Барыгыз, су буена төшеп чайкап менегез. Җылы киенегез.
*(Казларны көянтәләргә элеп күтәрәләр һәм түгәрәккә басалар. Су буена төшәләр.)*
*(Килеп җиткәч, кызлар каз чайкыйлар).*
**Рәмил:**
*Каз чайкыйлар безнең кызлар,*

*Куллары эшкә ята.*
*Мактаудан башка бер сүз юк,*
*Бу кызларга карата.*

*(Кызлар туңдыра башлады бит әле, биеп алыйк булмаса диешәләр. Казларны бәкеч итенә куеп бииләр).*

«Парлы татар биюе» (татар халык җыры)

**Гөлнур:** Казларыбыз да чистарды. Җылынып та алдык. Әйдәгез, кайтабыз.

*(Казларны алып түгәрәккә басалар. Музыка астында кайталар. Аларны әби каршы ала. Түгәрәк эченә керә.)*

**Әби:** Кайтып та җиттегезмени, балакайларым? Кая казларыгызны алып куйыйм әле. Бигрәк унган балалар булдыгыз. Мин әле коймакларымны да пешереп бетермәдем.

**Алинә:** Ярар, әбекәй, борчылма, без уйный торабыз.

**Бабай:** Әбисе, коймагыңны аннан пешереп бетерерсең, әйдә әле балаларның уеннарын карыйк.

**Әби:** Яшь чакларны искә төшерик дисеңмени, карткаем? Ярар, ярар.

**Алинә:** Кызлар,егетләр әйдәгез бераз күңел ачабыз. Кара-каршы басыйк та, уеныбызны башлыйк.*(Такмак җыр башкаралар)*

**Лилия:**
*Канат сатам, канат сатам,*
*Ап-агын сайлап, карап.*
*Кемгә кирәк, алыгыз,*
*Ничек акча ягыгыз?*
*(Малайлар канатларны карыйлар).*
**Рәмил:** *Канатыгыз кыйммәтме?*
**Алинә:** *Канатыбыз бер алтын.*
**Әсхәт:** *Кыйммәт икән: бер алтын!*
**Бергә:** *Канатлар сездә калсын.*
**Гөлнур:**
*Егет саран булмасын,*
*Акча жәлләп тормасын.*
**Илдар:**
*Әйдә, сезнеңчә булсын,*
*Акчабыз да юк-югын.*
**Лилия:**
*Ник аптырап торасыз,*
*Җырлап түләп алырсыз.*

Җыр “Җайдаклар”

**Барысы бергә:**
*Канат сату - кызык уен,*
*Каз өмәсендә була.*
*Таныштыра, дуслаштыра,*
*Яшьләрне иске йола.*

**Әби:** Балалар, «Чума үрдәк, чума каз»ны уйный беләсезме соң? Сезнең кебек чакта бик яратып уйный идек без аны.

Уен «Чума үрдәк, чума каз» (татар халык уены)

**Рәмил:** Кызлар, канатлар белән дә биеп күрсәтсәгез иде.

Бию «Каз канаты»

**Алинә:**

*Гөрләп үтте, шаулап үтте,*
*Авылда каз өмәсе.*
*Бу айларны, бу көннәрне*
*Көтеп ала һәммәсе.*

**Илдар:**

*Менә шулай каз өмәсен*
*Татарда үткәргәннәр.*
*Ә яшь кызлар күңел биреп,*
*Бу эшкә өйрәнгәннәр.*

**Әби:** И, балалакайларым, коймагым да пеште, әйдәгез, каз майларына манып, коймак ашыйк, матур итеп күңел ачып, тәмләп чәй эчик әле (*Бәйрәм чәй табыны артында дәвам итә).*

**Алып баручы:**

*Авылларда бүген кызлар җыры,*
*Тальян моңы чыңлый өйләрдә.*
*Күңелләрдән күңелләргә күчеп,*
*Кабат яңгырый иске көйләр дә.*
*Мамык кына гүя очып куна,*
*Кызлар җыры, назы күңелдә.*
*Иске йолаларны изге итеп,*
*Муллык җыры җиргә түгелә.*

Кадерле дуслар! Хөрмәтле кунаклар! Менә сезнең белән саубуллашыр чак та җитте. Бу бәйрәм тамашасы сезнең күңелләрегезгә дәрт өстәсен! Татар халкыбызның бәйрәмнәре, милли гореф-гадәтләре онытылмас һәм яшь буынга кире әйләнеп кайтыр дип ышанып калабыз.

***Степанова Рәйхана Сахап кызы***
*Татарстан Республикасы, Кукмара шәһәре*

## “Керән базары”

**Алып баручы:**

Хөрмәтле кунаклар! Бүген сезнең белән инде онытылып беткән бәйрәмнәрнең берсе Керән бәйрәменә - “Керән базарына” җыелдык.

Язны каршылап, язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган гүзәл “Масленица”, “Нәүрүз” бәйрәмнәре төркеменә “Керән базары” да керә. Ул - керәшен, татар, удмурт, рус, мари халыкларының уртак бәйрәме.

Ябалак-ябалак җепшек кар явып торган март аеның бер якшәмбесендә зур авылларда “Керән базарына” җыелганнар. Исеменнән үк күренеп тора: “Керән базарына” көздән яхшылап әзерләп куелган, яхшы итеп кышны чыккан иң тәмле, иң яхшы сортлы җиләк-җимеш, яшелчәләр күпләп сатылган. Керән базарында, хәтта керәнне дә эзләп табарга булган. Монда яшьләр бер-берсе белән танышканнар, кәләш күзләгәннәр. Кайсы “Керән базарында” кыз урлаулар да булган.

Бу көнне авылда җигүле атларда әйләнеп йөргәннәр. Атны аллы-гөлле тасмалар белән бизәп, тәрәзәләргә кер себеркесе элгәннәр. Яшьләр елга ярында төрле уеннар уйнаганнар: җыр, шаян сүз бетеп тормаган.

Ә базар көн алдыннан һәр өйдә берничәшәр пар кунак булган. Икенче көнне хуҗа кунаклары белән бергә базарга киткән. Аннан кайткач, табынга утырганнар, туган-тумачаларга, дус-ишләргә ашка барганнар. Моны, “Әртилле йөрү” дип атаганнар.

Ә балалар “Керән базарын” бигрәк тә көтеп алганнар. Хыялларында гына йөргән уенчыклар, тәмле-тәмле ризыклар шул “Керән базарыннан” кайткан инде.

Ә бәйрәмнең үзе сөрән салудан, бәйрәмгә чакыру такмакларыннан башланып киткән. Әнә сөрән салучылар үзләре дә киләләр инде.

**Сөрән салучылар:**

*1.Торыгыз, тор, хуҗалар,*
*Бәйрәм җитте, беләмсез!*
*Сөрән салучылар килде,*
*Ни сөенче бирәсез?*
*2. Ай диләр, вай диләр,*
*Сезне бигрәк бай диләр.*
*3. Һай, һай, һай, – диләр,*
*Гали абзый бай, – диләр,*
*Берәр кашык май, – диләр.*

*4.Пич, пич, пич – бабай,*
*Пич башыннан төш, бабай.*
*Пич башыннан төшмәсәң,*
*Илле сумыңны давай.*
*5. Апа, әни, җиңгиләр,*
*Бәйрәм мөбәрәк булсын!*
*6. Килә бәйрәм даулап, шаулап,*
*Бәхет-муллыклар яулап.*
*Аягың җиңел гөрләп торсын!*

**1нче хуҗа:** Пожалуйста, гости дорогие, пожалуйста проходите!

**2нче хуҗа:** Хуш киләсез, рәхим итегез!

**1нче хуҗа:**

*Собирайся народ,*
*Вас много интересного ждет.*
*Много песен, много шуток*
*И веселых прибауток.*

**2нче хуҗа:**

*Карап тормый ара еракка,*
*Дуслар килә безгә кунакка.*
*Дуслык – безнең тормыш үзәге,*
*Дуслык – безнең бәйрәм бизәге.*

**1нче хуҗа:**

*Внимание, внимание,*

*Ярмарка открывается.*
*Приходите, приезжайте*
*Все, что надо покупайте.*

**2нче хуҗа:**

*Тыңлагыз, тыңлагыз!*
*Шаккатып утырмагыз!*
*Әби белән бабушканы*
*Чакырыгыз бәйрәмгә.*
*Оныткannar алар, ахры,*
*Ярминкәгә килергә.*

*Ике якта ике өй: берсендә әби, икенчесендә бабушка яши.*

**Татар кызы:**

*Чәп-чәп-чәбәкәй,*
*Өйдәме син, әбекәй?* (*Ишек шакый.*)

**Әби:**

Өйдә, кызым, өйдә!

**Татар кызы:**

*Бөтен авыл ярминкәдә*
*Беләсеңме, әбекәй?*

**Әби:**

Һай, белми калганмын бит!

**Татар кызы:**

*Мулла абый акча чутлый,*
*Абыстайга күлмәккә.*
*Ятма йоклап, йөгер тизрәк,*
*Сатыла баллы прәннек тә!*

**Әби:**

Марусә әбиегезгә әйттегезме соң?

**Рус кызы:**

Бабушка, проснись скорей!

**Бабушка:**

Волки что ли у дверей?

**Рус кызы:**

*Ты открой скорее дверь*
*И в мои слова поверь.*
*Ярмарка у нас сегодня,*
*А на ярмарке игрушки:*
*Трактора и погремушки.*
*Есть и красные флажки,*
*Росписные сундуки.*
*И ватрушки, и платочки,*
*И со всех концов земли,*
*Все на ярмарку пришли.*

*Әби белән бабушка өйләреннән чыгалар, исәнләшәләр.*

**Әби:**

*Рано утром – иртә белән,*
*Пошел – киттек базарга.*
*Надо – кирәк бидрә – чиләк*
*Скорее – тизрәк.*

**Бабушка:**

Я сейчас, корзину возьму!

**Әби:**

*Пошли скорей базарга*
*Вкусный пряник алырга.*

*Әбиләр базарда товарларны мактыйлар.*

**Җыр:**

**Пряник сатучы:**

*Пряники, пряники,*
*Покупайте пряники.*
*Пряники русские*
*Сладкие, мятные.*
*К чаю ароматному*
*Угощение знатное.*

**Әби:**

Маруся, әнә анда пряник саталар! Әйдә, пряник алабыз, кызыл – красный пряник.

**Бабушка:**

Чего говоришь-то?

**Әби:**

Пряник продают, красный пряник дим.

**Бабушка:**

А-а, пойдем, пойдем!

"Пряники русские" рус биюе башкарыла.

**Тасма сатучы:**

*Тасма сатам, тасма сатам,*
*Әйдә, сайла, алларын.*
*Чәч үргече кирәк икән,*
*Алып җибәр аппагын!*

**Әби:**

И-и, менә монысын алам, күлмәгем дә коричневый!

**Бабушка:**

Больно длинный ведь, а!

**Әби:**

Кайгырма Маруся, озын булса, яртысын сиңа бирермен! Маруся, кая син! Әйдә, тасманы кәрзинеңә салыйм әле! Сумкамны өемдә онытканмын!

**Бабушка:**

Ты ну вечно забываешь!

**Әби:**

Тасма авыр булса, үзем күтәрермен, Маруся!

Җырлы-биюле “Тасма салам” уены.

**Алып баручы:**

*Әй әбиләр, бабушкалар,*
*Йөрисез дә, йөрисез!*

**Алып баручы:**

Карагыз әле, безнең удмурт әбиләребез нинди такмаклар җырлыйлар. Алар үзләренең оныклары белән килгәннәр. (*Удмурт такмаклары һәм бию башкарыла*)

**Бабушка:**

Уговорили так и быть, я тоже спою вам частушки.

*1. Веселы, мы веселы*
*Милые подружки.*
*Я сегодня пропаю*
*Веселые частушки.*

*2. Я на ярмарке сегодня*
*Накупила овощей.*
*Много будет витаминов,*
*И для супа и для щи.*

**Әби:**

Маруся, ты усталадыр инде, теперь минем чират биергә! *(Әби бии.)*

**Көнбагыш сатучы:**

*Көнбагыш сатам, семечки*
*Кыздырылган ул майда.*
*Вакытың әрәм булса да,*
*Алып җибәр син ай да.*

*Әбиләр, сатулашып, көнбагыш алалар.*

**Яшелчә сатучы:**

*Кишер, суган, кәбестә,*
*Шалкан, кыяр һәм керән -*
*Барысы да бик файдалы*
*Витаминнары белән.*

**Әби:**

*Шалкан быел бик уңган.*
*Самавыр хәтле булган!*

**Кыз:**

Кызлар, малайлар киләләр!

*Малайлар җырлап керәләр:*
*Уйныйбыз да, җырлыйбыз да,*
*Гармун кулларыбызда.*
*Алсу гөлләр чәчәк атсын,*
*Йөргән юлларыгызда.*
*Без андый малай түгел,*
*Без мондый малай түгел.*
*Кая барсак та ярыйбыз,*
*Күгәргән калай түгел.*

*Өскә бактым – ак күрдем,*
*Түбән бактым – тай күрдем.*
*Зур базарның эчендә*
*Үземә насыйп яр күрдем.*

*Малайлар бер кызны урлап чыгып китәләр.*

**Әби:**

Их, ник бирдегез, урладылар бит, кызны урладылар! И-и-и Маруся, беләсеңме шуны, мине дә Самигуллакаем шушы Керән базарыннан урлап киткән иде бит! Бу кыз да, минем шикелле, уңган, булган, чибәрдер инде.

**Бабушка:**

*Жених-то, а жених -*
*Удалой молодец.*
*Сильный, смелый и умный,*
*И проводный, и красивый.*

**Әби:**

Ник, ул проворный булганга урлаган бит инде аны. Аның җебегәне кыз урлый алмый. Эх, минем Самигуллакаем, бигрәкләрдән дә проворный иде шул!

*Сатучылар товарларны мактыйлар.*

**Конфет сатучы:**

*Алып җибәр чуклы конфет,*
*Өстәлеңә ямь булыр.*
*Өеңә кайтып җитмәсә,*
*Авызыңа тәм булыр.*

**Әби:**

Маруся, ал дим, ал канфит. Бу канфит белән бер самавыр чәй эчеп була бит!

**Чикләвек сатучы:**

*Сап-сары гәрәбә кебек*
*Урман чикләвеге бар.*
*Тешләреңне сынмый дисәң,*
*Стаканлап сатып ал.*

*Әбиләр чикләвек алалар.*

**Алып баручы:**

*Кая барсаң - товар, товар,*
*Кешесе күп, урыны тар.*
*Безнең Керән базарында,*
*Күгәрчен сөте дә бар.*

*Малайлар керә, җырлыйлар.*

*Кыңгыраулар чаң кага,*
*Урамнар да таң кала.*
*Ике яшьнең бәхетенә*
*Бөтен авыл таң кала.*

*Бию.*

**Кызлар:**

Малайлар, сезгә ни кирәк?

**Малайлар:**

Безгә матур кыз кирәк!

*Кызлар киттек су буена, атлар бик сусаган.*

*Без уйнаган уеннар да, шул су буенда калган.*

**Әби:**

Матур кызлар! Малайлар сорыйлар бит, әйдәгез, чыгыгыз!

Маруся, яшьләр уйный торсыннар, күңел ачсыннар, алар су буеннан кайтканчы, әйдә коймаклар пешереп куйыйк!

**Бабушка:**

*Мы давно блинов не ели,*
*Мы блиночки захотели.*
*Ой, блины, блины, блины,*
*Ой, блиночки мои.*

*Әби белән бабушка чыгып китәләр.*

**Алып баручы:**

Ягез әле, малайлар, кызлар, Керән базарыннан нәрсәләр алдыгыз?

*"Эх, дүдәк-дүдәк" көенә җыр башкарыла.*

*1.Ике конфет сатып алдым,*
*Сукыр бер тиен акчага.*
*2.Әти китте базарга, шул,*
*Безгә калды ашарга.*
*3.Эх сумсаның кайнары, шул,*
*Алды Кукмара байлары.*
*4.Майны салдым, чүлмәккә лә,*
*Кызыгып калдым, күлмәккә.*

*Әби белән бабушка керәләр.*

**Бабушка:**

*Моя родная сестричка,*
*Печь блины-то мастерица.*
*Напекла она поесть,*
*Сотен пять наверно есть.*
*На поднос блины кладет,*
*И сама к столу несет.*
*Гости, будьте же здоровы,*
*Вот блины мои готовы.*

**Малайлар, кызлар:**

Сый-хөрмәт өчен рәхмәт сезгә!

*Күмәк җыр башкарыла.*

**Алып баручы:**

*Киштәләрдә товар бетте,*

*Күктә алтын ай калка.*
*Күңелле Керән базары*
*Челтәр капкасын яба.*

**Алып баручы:**

Сезнең алда чынбарлык – 50 нче еллардагы Кукмарада булган “Керән базары” тасвирланды. Бәйрәм күренеше Кукмара районы авылында яшәгән Ләбибә Шакирова сөйләве буенча төзелде.

***Гыйниятуллина Нәзилә Николай кызы***
*Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре 15 нче урта гомуми белем мәктәбе укытучысы*

## “Нардуган бәйрәме”

**Максат:** укучыларны татар халык бәйрәмнәренең берсе - Нардуган бәйрәме белән таныштыру.

**Бурычлар:**

1. Укучыларның сөйләмен үстерергә ярдәм итү. Бәйрәмнең исемен, гамәлен атый белергә өйрәтү.
2. Гореф-гадәтләрне, йолаларны өйрәтү.
3. Бәйрәмнәргә кызыксыну уяту һәм мәхәббәт тәрбияләү.
4. Укучыларда өлкәннәргә карата хөрмәт хисе тәрбияләү.

### Бәйрәм барышы

*Зал бәйрәмчә бизәлгән Зал уртасында зур итеп ясалган “Ай” һәм “Кояш” макетлары эленгән. Тәрәзәләрдә кар бөртекләреннән пәрдәләр эленгән. Сәхнәдә авыл өе эче сурәтләнгән макет, әзерләнгән табын, тәрәзә каршында әби йон эрли.*

**Алып баручы:**

(*слайдлар күрсәтелә.)* Хөрмәтле укытучылар, кадерле балалар, килгән кунаклар! Бүген бездә зур бәйрәм – Нардуган бәйрәме. Нардуган – ул кышкы бәйрәм. Татар халкы яши торган кайбер төбәкләрдә борынгы заманнарда ук Яңа ел көннәрен Нардуган вакыты дип йөрткәннәр. Гадәттә, ул 22 нче декабрь – кышкы торгынлык көне. Бу – елда иң кыска көн.

Кышкы кояш торгынлыгын борынгы халыклар кояшның “үлеп кабат терелүе” яки “яңадан тууы” рәвешендә күзаллаганнар һәм аны ел саен бик зурлап тантаналы төстә билгеләп үткәннәр. Мондый календарь бәйрәм татарларда “Нардуган” дип йөртелгән. Аның атамасы монголча “нар” (кояш) һәм татарча “туу” сүзләреннән ясалган дип аңлату бар. Димәк, нардуган, “кояш туган” дигән сүз була. Нардуган бәйрәме декабрь ахырыннан – гыйнвар башына кадәр дәвам иткән. Кешеләр төрле киемнәр, битлекләр кигәннәр. Алар бәйрәм белән котлаганнар, изге теләкләр теләгәннәр. Яшьләр Нардуган уеннары уйнаганнар. Укучылар ярдәме белән әлеге бәйрәмгә күзәтү ясыйк.

*“Шома бас” көе яңгырый. Балалар җырлап керәләр. Араларында бер малай гармун тоткан. Башкалар аны хуплап җырлыйлар, бииләр.*

*Уйнат, уйнат гармуныңны*
*Авазлары чыңласын.*
*Кояш бәйрәме җырын,*
*Иптәшләрем тыңласын.*
*Эх, шома басабыз,*
*Биеп күңел ачабыз.*
*Әйдә, әйдә, катырак бас,*
*Биегәнне күрсеннәр.*
*Баскан җирдә ут чыгара,*
*Бу балалар дисеннәр.*
*Эх, шома басабыз,*
*Биеп күңел ачабыз.*

*Җырлаучылар йорт ишеген шакыйлар.*

**Бала:** Әби-бабай, өйдәме сез? Саумысыз?

**Әби:** Сау, бәбкәчләр.

*Балалар битлекләрен киеп, шигырьләрен сөйлиләр.*

**1нче бала.**
*Нардуганыгыз нар булсын,*
*Эче тулы нур булсын.*
*Нардуган җырын кем җырласа,*
*Шул бик бәхетле булсын.*

**2нче бала**.
*Нардуганым нарына,*
*Бакма кеше ярына.*
*Кеше яры яр булмас,*
*Үз ярыңа тиң булмас.*

**3нче бала.**
*Нардуганым нар булсын,*
*Эче – тышы нур булсын.*
*Нардуган башы кемгә тияр,*
*Ул бик бәхетле булсын.*

**Бабай:** Һай, рәхмәт, балалар. Теләгән теләкләрегез мең кат үзегезгә кайтсын. Исән-имин йөрегез, балакайлар. Нардуганыбыз котлы булсын!

*Балалар рәхмәт әйтеп, җырлап чыгып китәләр.*
*Әби белән бабай балаларны озаталар.*

**Бабай:**И-и-и, карчыккаем, бик моңсу булып калды бу балалардан соң. *(Бабай сәкегә ятып, уйга кала.)*

**Әби:** Дөрес әйтәсең, картым, үземә дә бик күңелсез. Элегрәк бик күңелле иде. Әллә, мин әйтәм...

**Бабай:**Чү, син әллә мин уйлаганны уйлыйсыңмы? *(Әбигә якынрак барып, карчыкны оялта.)* Әһә, белгән идем бу көн җитәсен мин... *(Сандыктан, шатланып, нидер эзләнә.)*

**Әби:** Нәрсәне белгән идең? Ни сөйлисең? *(Сандык актара торган бабай янына бара.)*

**Бабай:** Сагындым, бик сагындым мин синең белән үзебезнең Нардуган ата һәм Нардуган ана булып йөргән көннәребезне. Эшебезне тәмамлаганнан соң, кешеләр гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны онытып баралар, балалар һәм оныкларыбыз телебезне аңламыйлар, табигатебезгә карата сакчыллыгыбыз кими. Ә иң мөһиме – кешеләр үзләренең кем икәнен оныталар.

**Әби:** Хак әйтәсең, картым! Тик икәү генә без нишли алабыз соң?

**Бабай:** Икәү генә булдырмабыз, монысы билгеле. Әмма яхшылыкны эшли башларга гына кирәк, фикердәшләр табылыр, иншалла.

*Әби белән Бабай киенгәндә, дөмбер-шатыр музыка уйный, төсле утлар ялтырый. Шул арада Нардуган ата һәм Нардуган ана биюе башкарыла. Өйнең эчке күренеше алына, авыл урамы күренеше: берничә йорт.*

*Урамда яшьләр “Ай җаный, вай җаный”ны җырлап баралар.*

*Җырла, җырла, дип әйтәсез,*
*Сезгә нинди җыр кирәк?*
*Эй,сезгә нинди җыр кирәк?*
*Сезнең алда җыр җырларга*
*Сандугач теле кирәк.*
*Ай җаный, вай җаный,*
*Сандугач теле кирәк.*
*Уфа - Казан юлларының*
*Баганалары чыршы.*
*Эй, баганалары чыршы.*
*Башларыңа моңнар төшсә,*
*Сез дә булырсыз җырчы.*
*Ай, май үтә, май үтә,*
*Май үтә дә, җәй җитә.*
*Эй, май үтә дә, җәй җитә.*
*Май үткәнгә кайгырмагыз,*
*Безнең яшь гомер үтә.*
*Ай җаный, вай җаный,*
*Безнең яшь гомер үтә.*
*Безнең юллар куе үлән,*
*Карап үтәргә кирәк.*
*Эй, карап үтәргә кирәк.*
*Җыр белмәгән, җыр сөймәгән,*
*Безнең татарда сирәк.*
*Ай җаный, вай җаный.*

*Нардуган ата белән Нардуган ана яшьләрне агач артыннан күзәтәләр.*

**Нардуган ата:** Менә бу балалар безгә ярдәм итәрләр.

**Нардуган ана:** Ничек итеп? Болар бары тик күңел ачарга ярата торган авыл яшьләре ич... Болардан файда булмас...

**Нардуган ата:** Файда булса, карчыккаем, шулардан гына инде. Ярдәмгә Кояш белән Айны гына чакырасы иде тагын.

*Нардуган ата белән Нардуган ана сөйләшүен яшьләр күрә.*

**Егет:** Сез кем буласыз? Авылда күргәнебез булмады. *(Нардуган ата белән Нардуган ананы түгәрәккә чолгап алып карый башлыйлар, киемнәренә игътибар итәләр.)*

**Кыз:** Киемнәре бик үзенчәлекле. Матур итеп бизәлгән. Бераз тылсымлыга да ошаган.

**Егет:** Дөрес, минем андый киемнәрне рәсемдә генә күргәнем бар. Хәзер, хәзер *(ниндидер китап битләрен актара.)* Таптым, таптым. Бу бит... *(шаккатып карап тора.)*

**Яшьләр:** Кем?

**Егет:** Бу бит Нардуган ата белән Нардуган ана.

*Яшьләр Нардуган ата белән Нардуган ананы түгәрәккә алып бии башлыйлар. Нардуган ата белән Нардуган ана уртада бииләр. Биюгә Ай белән Кояш килеп кушыла.*

**Ай:** Бездән башка әллә бәйрәм итәсез?

**Кояш:** Әллә бәйрәмгә соңга калдыкмы, Нардуган анакай?

**Нардуган ана:** Исәнмесез, дусларым. Ничек тормыш итәсез? Бәйрәмебезгә рәхим итегез. Вакытында өлгердегез. Әллә уйнап та алабызмы?

*Залдан уенчыларны алып, "Чума үрдәк, чума каз" уены уйнала.*

*Чума үрдәк, чума каз,*
*Чума үрдәк, чума каз.*
*Тирән күлне ярата шул, ярата,*
*Тирән күлне ярата шул, ярата.*
*Алия үзенә иптәш эзли,*
*Алия үзенә иптәш эзли,*
*Белмим кемне ярата шул, ярата,*
*Ул Рәмисне ярата шул, ярата.*

*(Уен ахырында калган бала җыр җырлый, Нардуган ата белән Нардуган ана, Ай белән Кояш бу вакытта бииләр.)*

**Нардуган ата:** Бәйрәм көнне кыш ел фасылын һәм кышкы айларны искә төшерми булмас. Матур шигырьләрне тыңлап алыйк.

**1нче бала:**

*Менә салкын кыш җитте,*
*Җиргә ап-ак кар сипте.*
*Без кышны күптән көттек,*
*Ак карны сагынып беттек.*
*Бөтен дөнья ак булган,*
*Әйтерсең, ап-ак юрган.*
*Агачлар да ак мамыктай,*
*Бәсле шәлен ябынган.*
*Куана бала-чага,*
*Кыш килүгә шатлана.*
*Чана – чаңгылар алып,*
*Алар баралар тауга.*

**2нче бала:** Кыш. Нинди матур! Урамда, бөтерелеп, ап-ак кар ява. Барысы да ак юрган астында калган. Агачлар, өй түбәләре кыш буена тирән йокыга талдылар. Урамдагы һәр нәрсәгә сокланып карыйбыз. Энҗе кар бөртекләре ява башлау белән Яңа елны көтә башлыйбыз. Кыш бабай тәрәзәгә матур – матур бизәкләр ясап куйды. Күптән кышны көткән бала-чага, чаналарын тартып, урамга чыга. Без, кышның матурлыгына сокланып, аның узып киткәнен сизми дә калабыз.

**3нче бала:**

*Декабрь!*
*Төренде дөнья акка –*
*Кыш килде туган якка.*
*Башланды суык көннәр,*
*Көннәрдән озын төннәр.*

**4нче бала:**

*Гыйнвар!*
*Кар өстендә күпме эз!*
*Күрмәсәгез, күрегез.*
*Куян азык эзләгән,*
*Төлке аны күзләгән.*

**5нче бала:**

*Февраль*!
*Суык бабай кич – иртә*
*Борыннарны өшетә.*
*Ә көндез кояш көлә:*
-*Түзегез, - ди, - яз килә!*

*"Ява карлар" җыры яңгырый. Нардуган ата белән Нардуган ана, хискә бирелеп, вальс бииләр. Залдан егет һәм кызлар, парлап, аларга кушылалар.*

*Тагын бер ел иңләп узды,*
*Язмышым урамнарын.*
*Кайгыларны адаштыра,*
*Яңа ел бураннары.*
*Ява карлар, яңа карлар,*
*Яңа елның кары ява.*
*Кар өстендә учак булып*
*Яшьлек елларым яна.*
*Тагын бер ел шаулап узды,*
*Туздырып ап-ак карны.*
*Ак кар булып уйнап оча,*
*Яңа ел шатлыклары.*
*Ява карлар, яңа карлар,*
*Яңа елның кары ява.*
*Кар өстендә учак булып,*
*Яшьлек елларым яна.*
*Тагын бер ел иңрәп узды,*

*Тик хәтер булып калды.*
*Аклык булып җанга иңә,*
*Яңа ел болытлары.*
*Ява карлар, яңа карлар,*
*Яңа елның кары ява.*
*Кар өстендә учак булып,*
*Яшьлек елларым яна.*

**Кыз:** Йөзек салу уенын уйнап алыйк әле. *(Уен уйнала. Отылганга татар халык биюен биергә дигән җәза бирелә. Башкалар биюгә кушыла.)*

**Нардуган ата:** И балакайлар, шундый күңелле булды бәйрәмебез. Рәхмәтләребез сезгә мең кат сәламәтлек, бәхет булып әйләнеп кайтсыннар.

**Нардуган ана:** Иң элек үзегезнең кем икәнегезне онытмагыз, әби-балаларны, әти-әниләрегезне, өлкәннәрне хөрмәт итегез. Милләтегезне хурламагыз, телегезне онытмагыз! Табигатебезгә карата мәрхәмәтле булыгыз!

***Шәйдуллина Розалия Нургали кызы***
*Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы «Үрнәк балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең музыка җитәкчесе*

## “Орчык өмәсе бәйрәме сценарие”

**Максат:** Балаларны татар халкының милли бәйрәме «Орчык өмәсе» белән таныштыру.

**Бурычлары:**

1. Балаларга татар халкының тормышы, көнкүреше, милли киемнәре, бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләре турында мәгълүматләр бирү.

2. Балаларның бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, үз фикерләрен тулы итеп әйттерүгә ирешү, милли бәйрәмнәргә, гореф-гадәтләргә карата кызыксынучанлыгын арттыру.

3. Балаларга рухи-әхлакый тәрбия нигезләре бирү һәм татар халкының милли бәйрәмнәренә, гореф-гадәтләренә карата соклану хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Кабалар, орчыклар, җеп йомгаклары, йон, сандык, бәйләнгән киемнәр, чигелгән сөлгеләр һәм кулъяулыклар, эскәмияләр, өстәл, самавыр, чәйнек, чынаяклар, чигүле мендәрләр белән караватъ, сугылган паласлар.

**Техник чаралар:** Музыка үзәге.

**Залның бизәлеше:** Авыл өе күренеше.

**Балалар белән алдан эшләнгән эш:** Балалар белән халык авыз иҗаты әсәрләрен (табышмаклар, мәкальләр, санамышлар), татар халык җырларын, уеннарын, биюләрен өйрәнү. Балаларга милли бәйрәмнәр, өмәләр турында сөйләү. Каба, йон, орчыклар, йомгаклар карау, аларны ничек куллануларын аңлату.

**Музыка җитәкчесенең алдан башкарылган эше:** Татар халкының милли бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре, уен-йолалары турында мәгълүмат җыю. Татар халык авыз иҗаты әсәрләре туплау. Татар халык киемнәре, җиһазлар әзерләү. Җырлар, биюләр, уеннар сайлау.

**Бәйрәм барышы**

*Авыл өенең эчке күренеше. Як-ягына матур итеп тукылган сөлгеләр эленә. Идәндә сугылган паласлар. Өстәлдә – самавыр, чынаяклар, ашамлыклар. Идәндә – сандык. Анда кулдан бәйләнгән киемнәр, чигелгән сөлгеләр, кулъяулыклар, йомгаклар. Эскәмияләрдә йон бәйләнгән кабалар, орчыклар. Карават өстендә чигүле мендәрләр.*

**Алып баручы:**

Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар! Татар халкында милли бәйрәмнәр күп. Аларның кайберләре телдән-телгә күчеп безнең көннәргә кадәр килеп җиткән, кайберләре, кызганычка каршы, бөтенләй онытылып юкка чыккан. Ә бит борынгы әби-бабаларыбызның рухи хәзинәсе булган милли бәйрәмнәребезнең балалар тәрбияләүдә әһәмияте чиксез зур. Шуны истә тотып, бүген сезнең игътибарыгызга «Орчык өмәсе» бәйрәмен тәкъдим итәргә булдык. Бәйрәмебезгә рәхим итегез!

*Җыр «Сандугач, күгәрчен»(татар халык җыры)*

**Раушания әби:** И-и-и, күршекәем, син гел шулай тигез итеп, йон эрлисең. Кулың ятып тора шул эшкә, син эрләгән җептән бәйләгән оекбашлар, бияләйләр бик матур, җылы һәм чыдам була.

**Алия әби:**Аның бөтен сере – синең бабаң ясаган орчыкларда бит! Орчыклар шундый җайлы, кулга ятып торалар.

*Бер-берсенең эшләрен макташалар. Кызлар ишеккә шакыйлар.*

**Гөлнара апа:**Карагыз әле, кызлар килделәр бугай?!

**Илсөя апа:**Керсеннәр, керсеннәр, эшләгәннәре кеше өчен булса, өйрәнүләре үзләре өчен булыр.

**Алия әби:** Әйе, дөрес.

*Кызлар керә.*

**Зөһрә:** Исәнмесез! Өегезгә бәрәкәт иңсен. Бүген сездә «Орчык өмәсе» була дип ишетеп килдек. Безгә дә сезгә булышырга ярыймы?

**Илсөя апа:**Узыгыз, кызлар, узыгыз, бик вакытлы килдегез. Рәхим итегез, утырыгыз.

*Бергәләшеп эшли башлыйлар. Шул вакытта ишек шакыйлар, малайлар керә.*

**Малайлар:**

Исәнмесез, саумысыз?

**Кызлар:**

Нигә кәҗә саумыйсыз?

**Малайлар:**

*Әтәчегез күкәй салган,*
*Нигә чыгып алмыйсыз?*

**Кызлар:**

Я, шуннан?

**Малайлар:**

Кәбестә белән суган.

**Кызлар:**

Я, шуннан?

**Малайлар:**

Утырган да шуган...

**Илсаф:**

*Бәйрәмсез бик күңелсез бит,*
*Бәйрәмнәр кирәк безгә.*
*Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә,*
*Кирәк һәммәбезгә дә.*

**Раушания әби:**

Карале, бу малайларны! Бигрәк шуклар! Кызларның өмәгә килгәннәрен белеп килеп тә җиткәннәр. Әйдәгез, утырыгыз!

**Азамат:**

*Халкыбызның йолаларын*
*Искә төшерик әле.*
*Күңелле итеп бүген*
*«Орчык бәйрәмен» үткәрик әле.*

**Надир бабай:** Әйдәгез, малайлар, түргә узыгыз. Мин сезгә орчык ясарга өйрәтермен.

**Гөлнара апа:** Күпме булышчы! Сөбханалла. Болай булгач, язылмаган бер йон да калмый инде. Эш башланганчы, бер җыр җырлыйк әле.

**Зөһрә:**

*Җырлыйк әле, җырлыйк әле,*
*Җырлап ачыла күңел.*
*Җырлап ачылмаган күңел,*
*Мәңге ачылачак түгел.*

**Алина:**

*Ал да итәрбез әле,*
*Гөл дә итәрбез әле.*
*Матур җырлар җырлый-җырлый,*
*Бәйрәм итәрбез әле.*

*«Гүзәл туган ягыбыз»(Айдар Минһаҗев сүзләре, Әлфия Һадиева музыкасы) җырын җырлыйлар.*

**Азамат:** Әби, ә «Орчык өмәсе» нәрсәне аңлата? Кайчанрак уза ул?

**Надир бабай:** Менә бит ничек, яшьләр бу бәйрәмнәрне чын мәгънәсендә аңлап бетермиләр икән... Әби, сөйлә әле өмә турында.

**Раушания әби:** Хәзер бөтенләй башка вакыт. Кибеттән теләгән бөтен әйберне алып була. Балалар йонның кайдан алынганын һәм ничек эшкәртелгәнен белмиләр. Ләкин яшьләрне гаепләргә ярамый, вакыты шундый. Орчык бәйрәме бу безгә борын заманыннан калган йола. Ул, җиргә кар яугач, көз көне үткәрелә. Хуҗа кеше күп итеп йон әзерли. Кичтән тәмле ризыклар пешерә. Ул кичкә дусларын, күршеләрен чакыра. Алар җыелып беткәч, күмәк эш башлана. Кемдер йон яза, кемдер эрли, кемдер аны ката

һәм йомгакка чорный. Ә кемдер бәйли. Эшне бар кешегә дә бүлеп бирәләр. Ә күңелле булсын өчен, ул эш бию, җырлау, шигырь сөйләү, табышмаклар һәм мәкальләр белән аралаштырып барыла. Ә эш беткәч, табынга утыралар. Менә бүген, балалар, шундый бәйрәм.

**Илсөя апа:** Эшкә бирелеп китеп, телдән язмыйк тагын. Әйдәгез, «Башы телемдә, ахыры төендә» дигән уенны уйнап алыйк. Мин мәкальнең башын әйтәм, ә сез ахырын.

-Тирләп эшләсәң, *тәмләп ашарсың*.

-Биш әйткәнче, *бер эшлә.*

-Эш беткәч *уйнарга ярый.*

-Карама кешенең сүзенә, *кара эшенә.*

-Эшләмәгән *ашамый.*

-Җәй эшләсәң, *кыш ашарсың*.

-Әткәй – шикәр, *әнкәй – бал.*

-Сүз сөйләсәң, *уйлап сөйлә.*

-Көн – эш өчен, *төн – ял өчен.*

**Раушания әби:** Менә булдырдыгыз, балалар. Эшләгәндә кулыгыз-кулга йокмый, сөйләгәндә телегез дә шулай икән.

**Алия әби:** Балалар, аякларыгыз утырып оеп киткәндер инде. Бер биеп күрсәтегез.

**Азалия*:***

*Без биибез тыпыр-тыпыр,*
*Без биибез тып та тып.*
*Бер башласак, бик тиз генә*
*Булмый безне туктатып.*

**Айдар*:***

*Әйдә, әйдә, катырак бас,*
*Биегәнне күрсеннәр.*
*Баскан җирдән ут чыгара,*
*Безнең яшьләр дисеннәр.*

*Татар халык биюе.*

**Раушания әби:** И балакайларым, сезгә карап, яшь чаклар искә төшеп китте. Апайлар, әйдәгез әле, без дә сезнең белән азрак уйнап алыйк.

*“Кәрия-Зәкәрия” уены уйнала.*

*(Балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Түгәрәктәгеләр бер якка хәрәкәт итеп җырлыйлар. Җырларда уртадагы баланың укуда, хезмәттә, җыр-биюдә булган сәләте, уңганлыгы мактала:*

*Бу - бик яхшы биюче,*
*Бу - бик яхшы биюче.*
*Аның биюе матур,*
*Аннан үрнәк алыгыз.*

*Җырдан соң түгәрәктәгеләр туктап калалар, кул чабып, такмак әйтәләр:*

*Кәрия, Зәкәрия, коммая,*
*Кәрия, Зәкәрия, коммая:*
*Кәри комма, Зәкәр комма,*

*Зәкәрия коммая.*

*Бу вакытта уртадагы бала бер иптәшен алып әйләнеп тора. Әйләнеп туктагач, чакырган иптәшен калдырып, түгәрәккә баса. Тагын җыр башлана:*

*Бу - бик яхшы җырлаучы,*
*Бу - бик яхшы җырлаучы.*
*Аның җырлавы матур,*
*Аннан үрнәк алыгыз.*

*Шулай укучы, буяучы һ.б. дип төрлечә әйтеп, җырлап-биеп, уенны дәвам итәләр.)*

*Уен беткәч, эшкә тотыналар.*

**Солтан:** Әби, ә нәрсәгә сезгә шулай күп йон кирәк?

**Раушания әби:** Кызым, без хәзер өлкән кешеләр. Бик җылы яратабыз. Җылы булган саен, безгә рәхәтрәк. Алла боерса, мин сезгә оекбашлар, бияләйләр бәйләрмен. Минем сезнең кебек үк оныкларым бар. Алар мин бәйләгән әйберләрне бик ошатып кияләр. Менә кайберләренә бәйләдем дә инде. *(Сандыгын ачып, берәм-берәм күрсәтә, аңлата.)* Бәйләп кенә түгел, чигеп тә утыра идек әле. Менә чиккән сөлге, мендәр тышы, алъяпкыч һәм күкрәкчә. Ай, балалар, мин сөйлим дә сөйлим, сез мине тыңлап аргансыздыр инде. Әйдәгез әле, балалар, ярышып алыйк – йомгакны урап карыйк. Кайсыгыз җитезрәк икән?

*«Кем беренче урый» уены.*

*(Ике бала кара-каршы басып, уралган орчыктан җепне йомгакка чорныйлар. Җепне икенче булып, иң ахырына чорнап бетергән балага җәза бирелә.)*

**Солтан:**

*Без уйныйбыз, уйныйбыз,*
*Якты көннән туймыйбыз.*
*Кулны-кулга чаба-чаба,*
*Көләбез дә җырлыйбыз.*

**Надир бабай:** Ай-яй-яй, балалар, шундый матур уеннар беләсез икән. Сезгә карап торам да, сокланып куям. Җеп ураганда, куллары-кулга йокмый. Сезне «Орчык өмәсе»нә өйрәтеп тә торасы юк, туганнан бирле «Орчык өмәсе»нә йөреп, шомарып беткәннәр, дип белерсең. Ярый уйный-җырлый беләсез, ә шигырьләр сөйли беләсезме?

**Ильяс:**

*Туктатмагыз гармунны,*
*Чакырыйк без кызларны.*
*Бергә-бергә җырлыйк әле,*
*Без яраткан җырларны.*

**Данил:**

*Уйныйбыз да, җырлыйбыз да,*
*Гармун кулларыбызда.*
*Алсу гөлләр чәчәк атсын,*
*Йөргән юлларыгызда.*

**Зәмирә:**

*Әйдә, дуслар, җырлыйк әле,*
*Уйнаган гармуннарга.*
*Ал чәчәк күк яшик әле,*

*Туган якларыбызда.*

*“Кояшлы безнең ил” (Айдар Минһаҗев сүзләре, Әлфия Һадиева музыкасы) җырын җырлыйлар.*

**Ильяс:**

Безгә табышмаклар да әйтегез инде.

**Гөлнара апа:**

*Табышмак әйтәм мин сезгә,*
*Йон бирә нәрсә безгә? (Сарык)*

**Илсөя апа:**

*Күрер-күрмәс күзләре,*
*Челтәр бәйли үзләре.*
*Челтәрләре түгәрәк,*
*Эшли алар үрмәләп. (Үрмәкүч)*

**Раушания әби:**

*Биш агайга бер күлмәк. (Бияләй)*

**Надир бабай:**

*Кечкенә генә карчык, зыр-зыр әйләнеп йон җыя. (Орчык)*

**Алия әби:**

*Әйләнгән саен калыная. (Йомгак)*

**Солтан:**

Кызлар-малайлар, «Орчык бөтерү» уенын да уйнап алыйк. Уйныйбызмы?

**Барысы бергә:**

Уйныйбыз!

*“Орчык бөтерү” уенын уйныйлар.*

*(Балалар түгәрәк ясап, тезләнеп утыралар. Бер бала уртада орчык әйләндерә. Орчык кемгә карап туктап кала, шуңа җәза бирелә.)*

**Раушания әби:**Менә бит нинди матур уеннар, җырлар, биюләр беләсез, әйтерсең лә гомер буе «Орчык өмәсенә» йөргәнсез кебек, шомарып беткәнсез.

**Зәмирә:** Кызык. Бәйрәмебез бик күңелле үтә.

**Зөһрә:** Әйдәгез, гөрләтеп, бер татар биюен биеп алыйк.

**Г.Камилә:**

*Ягез, хәзер бергәләшеп*
*Тыпырдап биеп алыйк.*
*Әйе шул, әйе шул,*
*Тыпырдап биеп алыйк.*

**Н.Камилә:**

*Биюченең итәге*
*Бии, бии кыскара.*
*Биючегә сүз әйтмәгез,*
*Бии, бии остара.*

*Парлы татар биюе.*

**Азамат:**Ярый әле килгәнбез. Күп нәрсәләр белдек. Җырладык та, биедек тә, уеннар да уйнадык.

**Раушания әби:** Менә, балалар, “Орчык өмәсе” шулай үтә иде. Эшен дә эшләдек, күңелне дә ачтык. Бүгенгә җитеп торыр.

**Алып баручы:** Хөрмәтле кунаклар! Безнең бәйрәмебез ахырына якынлашты. Гаиләләрегезгә татулык, күңелләрегезгә тынычлык, бәхетле матур киләчәк телибез. Сау-сәламәт булыгыз! Балаларыгызны татар җанлы итеп, милли рухта тәрбияләгез. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

***Зарипова Алина Павел кызы***
*Татарстан Республикасы, Кукмара шәһәре*

**“Ничек без Сөмбеләне эзләдек…”**

**Геройлар:** *Сөмбелә, Шүрәле.*

**Тәрбияче:** Исәнмесез, балалар! Елның сихри фасылында – көн белән төн тигезләшкән вакытта татар халкы «Сөмбелә» бәйрәмен уздырган. Ул - көзге бәйрәм, уңыш бәйрәме. Бу вакытта инде уңыш җыю эшләре тәмамлана. Бәйрәмнең хуҗабикәсе Сөмбелә исемле, сүзгә тапкыр, эшкә уңган кыз була.

Без дә бүген сезнең белән «Сөмбелә» бәйрәмен үткәргә җыелдык. Әйдәгез әле, түгәрәккә басып, көз турында җыр җырлап алыйк. Сөмбеләбез дә безне ишетеп килеп җитәр.

*Яфрак бәйрәме (Р.Еникеева музыкасы, Л.Лерон сүзләре)*

*Яңгыр түгел, кар да түгел,*
*Яфраклар ява җиргә.*
*Көз турында җырлыйм әле,*
*Кушыл син яңа җырга.*
*Кушымта:*
*Сары, сары, сап-сары,*
*Агачның яфраклары.*
*Җил исә, ява яфрак,*
*Көзнең матур чаклары.*
*Оча яфрак, уйный яфрак,*
*Һаваларда әйләнеп.*
*Бүген, бүген, бүген, бүген -*
*Яфракларның бәйрәме!*
*Кушымта.*

*Тавыш ишетелә. Шүрәле керә.*

**Шүрәле:** Әй сез, наяннар! Нинди бәйрәм сезгә! Барыгыз, кайтыгыз! Сөмбеләгезне урладым. Яратмыйм мин көзне. Ул яңгыр ява дисеңме, ул пычрак дисеңме... Җәйдән соң тизрәк кыш кирәк миңа. Чанада, чаңгыда шуармын, кар атышып уйнармын!

**Тәрбияче:** Чү, Шүрәле, тукта әле. Ничек инде Сөмбеләне урладың?! Без бит аннан башка бәйрәм итә алмыйбыз. Сөмбеләне урлап көзне үпкәләтәсең бит. Ничек инде көзне яратмаска була? Көзнең үзенең бер сихри матурлыгы бар. Алтын көз! Көзнең алтынлыгы, аның муллыгы һәм күркәмлеге көзге муллык белән билгеләнә. Шулай бит, балалар?

**Балалар:**

Әйе!

**Тәрбияче:**

Шүрәле, син безнең балаларны тыңлап кара әле!

**1нче бала:**

*Көз көннәре бик күңелле,*
*Бик күп җимешләр пешә.*
*Помидор, карбыз өлгерә,*
*Алмалар өзелеп төшә.*

**2нче бала:**

*Кем ничектер, мин үзем*
*Яратам елның көзен.*
*Бик еш болытлар каплап,*
*Торса да саф күк йөзен.*
*Иссә дә ачы җилләр,*
*Койса да салкын яңгыр,*
*Нигъмәткә бай алтын көз*
*Ямьлерәк күк барыбер.*

**3нче бала:**

*Ни арада җәй үткән,*
*Алтын көз килеп җиткән.*
*Җимешләр өлгергәч, бакча*
*Бигрәк тә матур икән!*
*Алмалар, әй уңганнар,*
*Кызарышып тулганнар.*
*Балга манып алганмыни,*
*Шундый татлы булганнар.*

**4нче бала:** Көз айлары бигрәк матур! Бар дөнья сары, кызыл, алтын төскә керә. Агачлар иң матур күлмәкләрен киеп, көз килгәнен көтәләр. Бакчаларда эшләр төгәлләнә. Уңыш җыеп алына, кыш ашарга базларга салына.

**Тәрбияче:** Ишеттеңме инде, Шүрәле?

**Шүрәле:** Әйе шул... Эх, балалар, ялгыш эшләп ташладым бит әле. Үзем турында гына уйладым... Нишлик инде хәзер? Мин бит Сөмбеләне урманда калдырдым.

**Тәрбияче:** Әйдәгез, балалар, бергәләп Сөмбеләне эзләргә киттек. Аны алып кайтыйк. Бәйрәмебезне дәвам итик.

*Балалар тәрбиячеләр ярдәме белән урманга юл тоталар.*

**Тәрбияче:** Балалар, бүген без сезнең белән урманга сәяхәткә чыгабыз. Безгә башта урманнан рөхсәт сорарга кирәк. Кем шундый серле сүзләрне белә?

**5нче бала:**

*Урман янына килдем,*
*Зурлап башымны идем:*
*— Урман,— дидем,— урманым,*
*Мин үтим әле, җаным.*
*Эчкәрегерәк керим,*
*Сукмакларыңда йөрим,*
*Җимешләрең авыз итим,*
*Гүзәллекләрен күрим...*
*Урман әйтте:*
*— Әйдә, бала, рәхим ит,*
*Син бит дустым минем,— диде,—*
*Түрдән үт! (Резеда Вәлиева)*

**Тәрбияче:**

Балалар, әйдәгез, Сөмбеләне эзләргә.

*Балалар кычкырып, Сөмбеләне эзлиләр.*

**Сөмбелә:**

*Ерактан тавыш ишетеп,*
*Сезнең янга килдем мин.*
*Исәнмесез, балалар!*

**Балалар:**

Исәнмесез!

**Сөмбелә:**

Ә сез беләсезме, мин кем булам?

**Балалар:**

Сөмбелә.

**Тәрбияче:**

Исәнме, Сөмбелә! Балалар! Шүрәлене нишләтик инде?!

**Сөмбелә:**

Балалар, ачуланмагыз аны! Мин сезгә көзге бәйрәм алып килдем. Карагыз әле, көз урманны ничек матур итеп бизәгән. Яфракларның нинди генә юк: сарысы, кызылы, яшеле. Ничек матур монда! Әйдәгез, бу аланда гына бәйрәмне дәвам итик. Шүрәлене дә үзебезнең янга чакырыйк.

*Балалар Шүрәлене чакыра. Аланда уеннар дәвамителә.*

*“Куянкай” уены.*

*Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Түгәрәк уртасына кереп, бер бала чүгәли. Ул — "куян ". Куян, бер кулын иягенә куеп, моңаеп утыра. Түгәрәктәгеләр җырлый-җырлый әйләнәләр:*

*Ак куянга ни булган,*
*Әллә инде авырган?*
*Иптәшен дә табалмый,*

*Урыныннан да торалмый.*

*Куян, куян, син сикер,*

*Иптәшең табып китер!*

*Куян биленә таянып сикерә башлый. Аннан бер иптәшен уртага алып керә. Чакырылган бала куян булып кала. Уен шулай дәвам итә.*

*"Кәрия-Зәкәрия" уены.*

*Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Түгәрәктәгеләр бер якка хәрәкәт итеп җырлыйлар. Җырларда уртадагы баланың укуда, хезмәттә, җыр-биюдә булган сәләте, уңганлыгы мактала:*

*Бу - бик яхшы биюче,*

*Бу - бик яхшы биюче,*

*Аның биюе матур,*

*Аннан үрнәк алыгыз.*

*Җырдан соң түгәрәктәгеләр туктап калалар, кул чабып, такмак әйтәләр:*

*Кәрия-Зәкәрия, коммая,*

*Кәрия-Зәкәрия, коммая,*

*Кәри комма, Зәкәр комма,*

*Зәкәрия коммая.*

*Бу вакытта уртадагы бала бер иптәшен алып әйләнеп тора. Әйләнеп туктагач, чакырган иптәшен калдырып, түгәрәккә баса. Тагын җыр башлана:*

*Бу - бик яхшы җырлаучы,*

*Бу - бик яхшы җырлаучы.*

*Аның җырлавы матур,*

*Аннан үрнәк алыгыз.*

**Тәрбияче:**

Балалар, карагыз әле, монда бик күп яфраклар коелган. Бу яфракларда - табышмаклар. Аларга җавап биреп урманда нинди җәнлекләр яшәвен белербез.

*Сорыдыр төсе,*

*Үткендер теше.*

*Урманда йөри,*

*Бозаулар эзли. (Бүре)*

*Ябалактан курка,*

*Чикләвек ярата.*

*Сызгырса, урманны яңгырата. (Тиен)*

*Җәен соры, кышын ак,*

*Аңа шулай яхшырак. (Куян)*

*Энәсе бар - тотып булмый,*

*Энәсе белән тегеп булмый. (Керпе)*

**Сөмбелә:**

*Җирдә ята сары яфрак –*

*Көз килүнең билгесе.*

*Сары яфрак – көз чибәрнең*

*Төшеп калган көзгесе.*

*Яфрак сибеп уйнау.*

**Сөмбелә:**

*Әйе, дуслар, килмәдем тик*
*Яфрак сибеп уйнарга.*
*Килдем тагын сезне күзге*
*Муллык белән сыйларга.*

*Сөмбелә балаларга күчтәнәчләр өләшә.*

**Тәрбияче:** Балалар! Ничек күңелле бүген! Рәхмәт сиңа, Сөмбелә! Әйдәгез, балалар, бүгенге көннең истәлеге итеп шушы алтын, сары яфракларны җыеп кайтыйк. Без әле монда тагын килербез.

*Тәрбияче балалар белән яфраклар җыя, тирә – юньне күзәтәләр.*

***Миназова Эльвира Мәсхүт кызы***
*Татарстан Республикасы, "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәренең "4нче санлы балалар бакчасы" Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе тәрбиячесе*

## "Бездә бүген Сабантуй"

**Бурычлар:**

1. Татар халкының йөзек кашы булырдай бәйрәме - Сабан туе, аның йолалары, уеннары белән таныштыруны дәвам итү.
2. Бәйрәм турында күзаллауларын киңәйтү, анда катнашырга теләк тудыру.
3. Халык бәйрәмнәре аша балаларда милли рух, күңел күтәренкелеге, шатлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Спорт мәйданчыгы бәйрәмчә төрле төстәге шарлар, чигелгән сөлгеләр белән бизәлә. Ярышлар өчен кирәкле атрибутлар: капчыклар, кашыклар белән йомыркалар, су белән чиләкләр, аркан, чүлмәк белән күсәк, эленгән әйберләр белән бау, көрәш урынын әзерләү, балаларга бүләкләр.

**Алдан эшләнгән эш:** Татар халык бәйрәме Сабантуй турында тулы мәгълүмат бирү, шигырьләр, җырлар, биюләр өйрәнү, алдагы көнне барлык төркем балаларын бәйрәмгә чакыру.

### *Бәйрәм барышы*

*Тантаналы көй астына алып баручылар чыга.*

**1нче алып баручы:**

*Саумы, июнь – Сабантуйлар ае!*
*Саумы, Сабантуйлы киң мәйдан!*
*-Менә шулай матур яшәгез!- дип,*
*Җыйдык әле сезне яңадан.*
*Бәйрәмнәрнең таҗы – Сабантуйлар –*
*Бүләк безгә бөек ходайдан.*

*Бу тормышның бөтен матурлыгын,*
*Хозурлыгын саклый бу мәйдан!*

**2нче алып баручы:**

*Шатлыклар күңелебездә,*
*Ал кояш күгебездә.*
*Килегез, дуслар, кунакка:*
*Сабантуй бүген бездә.*
*Җилферди чиккән сөлгеләр,*
*Сабантуй бездә.*
*Көрәшик тә, ярышыйк та -*
*Килегез сез дә.*
*Шатлыклар өстәп күңелгә,*
*Кояш елмая күктә.*
*Килегез, дуслар, кунакка,*
*Сабантуй бүген бездә!*

**1нче алып баручы:**

Исәнмесез! Кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар, хәерле көн! Без бүген татар халкының олы бәйрәме - Сабантуена җыелдык. Сабантуй — ул хезмәт бәйрәме, Сабантуй — ул дуслык бәйрәме, Сабантуй — ул һәркемнең көтеп алган изге бәйрәме. Котлы булсын Сабан туйлары! Кадерле балалар! Балалар бакчасында эшләүче барлык тәрбияче апаларыгыз исеменнән сезгә бәхетле балачак, ныклы сәламәтлек телим. Алдагы көннәрегез дә бүгенге кебек ямьле, күңелле булсын. Өстәлләребездә ризыклар мул булсын!

*Чигелгән сөлге өстенә куелган икмәк тотып бер бала керә.*

**2нче алып баручы:**

*Уңган икмәк килсен табыннарга,*
*Кыр батырларына дан җырлыйк,*
*Мул уңышлар бирсен ходаебыз,*
*Изге теләк белән күңел ачыйк!*

*Күмәк җыр “Күңелле Сабантуйлары”*

**1нче алып баручы:**

Хөрмәтле балалар, әти-әниләр, килгән кунаклар! Бүгенге көн – безнеке! Әйдәгез, бергәләп күңел ачыйк, халкыбыз элек-электән яратып уйнаган уеннарда катнашыйк, бәйрәм итик, ял итик! Берничә минуттан зур көрәш мәйданында татарча көрәш башланачак.

*Көрәш башланды.*

**Бала:**

*Көрәшкә чыкты Азат,*
*Аның көч - гайрәт харап!*
*Шыбыр тиргә батканбыз,*
*Ул тырышканга карап.*
*Көндәше дә тиң икән,*
*Әйтерсең, төпле бүкән,*

*Күтәреп алам димә,*
*Бил бөгеп салам димә!*
*-Әйдүк!- диеп көч биреп,*
*Кычкырып тавыш бетте.*
*Ниһаять, көчле көндәш*
*Җиргә шапылдап төште.*
*Хәле бетсә дә, Азат*
*Елмайды безгә карап.*
*Шундый дуслар булганда,*
*Җиңүне була яулап!*

*Җыр: "Әссәламәгәләйкүм"*

**Бала*:***
*Капчык киеп йөгерергә,*
*Теләүчеләр күп булдык.*
*Сыбызгы сызгыруга ук,*
*Дәррәү алга атылдык.*
*Чү, ни хәл бу, кинәт кенә*
*Әллә җир әйләндеме,*
*Капчык эчендә адашып,*
*Аяклар бәйләндеме -*
*Яшел чирәмгә сузылып,*
*Ятканны сизмәдем дә.*
*Башкалар узып киткәнен*
*Күрдем дә, күрмәдем дә!*
*Сикереп тордым ачудан,*
*Томырылдым алга табан.*
*Үҗәтлек бушка китмәде,*
*Беренче килдем - арттан!*

*Уен: капчык киеп йөгерү*

**Бала:**
*Бүген бездә Сабантуй,*
*Бар эшеңне читкә куй!*
*Өздереп уйный гармун,*
*Һәр тарафта уен-моң.*
*Килешеп тора көе,*
*Уртага чыгып бие!*
*Ялындырып тормачы,*
*Чакырганны бормачы!*
*Бие-бие җилкенеп,*
*Мәйдан торсын селкенеп!*
*Осталыгың күрсеннәр:*
*- Их, шәп баса!- дисеннәр.*

*Бию “Куш кулым”*

**2нче алып баручы:**

*Авызга кашык каптык,*
*Җыйнаулап торып чаптык.*
*Йомыркалар бииләр,*
*Гел тик торам димиләр.*

*Уен: кашыкка йомырка салып йөгерү*
*Җырлы- биюле уен “Кәрия-Зәкәрия”*

**1нче алып баручы:**

*Чүлмәк ватыш уены -*
*Бигрәк тә кызык инде.*
*Әйдә, уйнап карагыз әле,*
*Бу кызыклы уенны.*

*Уен: чүлмәк вату*

**2нче алып баручы:**

*Күрәсезме, бауга бәйләп,*
*Күпме әйбер элделәр.*
*Күзләрен бәйләп өлгерләр,*
*Теләгәнен кисәрләр.*

*Уен: күзне бәйләп әйбер кисеш*
*Җыр “Кояшлы ил - безнең ил”*

**1нче алып баручы:**

*Менә сиңа сулы чиләк,*
*Көянтә ал иңеңә.*
*Йөгер тизрәк, иң алдан кил,*
*Егыла гына күрмә.*

*Уен: сулы чиләк белән йөгерү*
*Җырлы - биюле уен “Зилем - Зиләйлә”*

**Бала:**

*Бигрәк юан арканы!*
*Бармы икән тартканың?*
*Тезелдек ике сафка,*
*Бүлендек ике якка.*
*Уртада тора - таяк,*
*Билгегә дигән маяк.*
*И, арканны тартабыз,*
*Тирләп чыкты аркабыз.*
*Бер маякка җитәбез,*
*Аннан артка китәбез...*
*Тырыша торгач шулай,*
*Ахры, җиңәбез бугай!*
*Уйлап та өлгермәдем,*
*Чирәмгә тәгәрәдем!*

*Уен: аркан тартышу*

**1нче бала:**
*Сабантуйлар берләштерә,*
*Сабантуйлар көрәштерә.*
*Җиңүләр безгә ят түгел,*
*Җиңелсә дә оят түгел -*
*Шуңа да ул Сабантуй!*

**2нче бала:**
*Сөлгеләрен җилфердәтә,*
*Батырларны җилтерәтә,*
*Биетә дә, җырлата да,*
*Көлдерә дә, елата да -*
*Шуңа да ул Сабантуй!*

**3нче бала:**
*Колгаларга да мендертә,*
*Капчык белән дә йөгертә.*
*Таныштыра, дуслаштыра,*
*Тик барыбер хушлаштыра -*
*Шуңа да ул Сабантуй!*

**2нче алып баручы:** Менә, дуслар, көтеп алынган Сабантуе да тәмам! Барыгызга да саулык-сәламәтлек телибез. Киләсе елга да Сабан туйларында очрашырга язсын. Сау булыгыз!

*Бүләкләр өләшү, җыр “Мин яратам сине, Татарстан”*

***Төхфәтулова Хәлимә Хәким кызы***
*Татарстан Республикасы, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Татар телендә белем бирүче 155 нче гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениясе укытучысы*

## “Ил язмышы - ирләр кулында!”

*Сәхнәдә солдатлар һәйкәл булып, фотодагы кебек басып торалар.*
*Авансценада 1нче алып баручы егет.*
*Музыка.*

**1нче алып баручы:**
*Токымым - пәһлевән ишле,*
*Чыныгып үскән Токым*
*Иле өчен,*
*Җан аямый,*
*Ут аша үткән Токым!*
*Үлемне*
*Йөрәге белән*
*Томалап куйган Токым!*

*Исемен*
*Дан һәйкәленә*
*Мәңгегә уйган Токым!*

*Экранда сугыш башлану күренешләре. Бомба тавышлары.*

**2нче алып баручы:**
*Сандугачлы тыныч зәңгәр кичтә,*
*Шомырт чәчәк аткан чагында.*
*Мәхәббәтнең иркә җилләреннән,*
*Яшь йөрәкләр каккан чагында.*
*Сугыш сүзе, бәлки, кирәкмидер?*
*Җырыгызның сүзен бозам бит.*
*Тик нишлисең?*
*Безнең яшьлегебез сугыш елларында узган бит.*
*Зәңгәр кичне кара төн итеп,*
*Шомырт чәчәкләрен көл итеп,*
*Безнең өстән сугыш узган бит,*
*Безнең язмышларны бозган бит!*

*Авансценадагы 1нче алып баручы егет җырлый.*
*Җыр "Солдатлар" – 1 куплет.*
*Сәхнәнең бер ягыннан икенче ягына таба бара-бара, Ана образы чыга.*

**Ана:**
*Өч баламны, очар кош итеп,*
*Мин очырдым иркен далага.*
*Әйтегезче, зинһар, үз итеп,*
*Сагыш белән кипкән анага:*
*Кайда йөри минем улларым?*
*Ана күңеле тели белергә.*
*Кая илтә язмыш юлларын,*
*Җиңүгәме, әллә үлемгә?*

*Ана солдатлар арасында йөреп, җавап эзли. Ул тирән кичерештә.*
*Музыка.*

**1нче солдат:**
*(бер адым алга чыга)* Мин – Солдат.

Мин – үткән сугышның беренче көнендә үтерелгән солдат. "Үләбез инде, хуш, бәхил бул, газиз Туган ил", – дидек, һәм көйгән иреннәребез белән соңгы тапкыр синең көйгән туфрагыңны үптек.

**2нче солдат:** *(бер адым алга чыга)* Без елый-елый түгел, күзләребезне яшь капласа да, җырлый-җырлый үлдек.

Менә инде 70 еллап йөзләребез белән көнбатышка карап шулай ятабыз. Без һаман ил чигендә, без һаман сакта. Үлгәннәр картаймыйлар.

**3нче солдат:** *(бер адым алга чыга)*

Без, адәм балаларына табигать үзе бүләк иткән җимешләрнең бик күбесен татып карамыйча, дөньядан киттек. Үз каныбыздан яралып, дөньяга энҗе күзләрен ачкан сабыебызны күрмәдек, ата бәхетен башыбыздан үткәрмәдек.

*Моңсу музыка. Сәхнә артыннан ак шәл бөркәнгән тол хатын образы чыга.*
*(Ә. Атнабаевның "Яшьлек белән очрашу" поэмасыннан өзек)*

**Гөләндәм:**

*Улым туды.*
*Шул ук көнне алдым атасының үле хәбәрен.*
*Юк, юк, юк, киләчәктә беркем укымасын хәбәрләрнең мондый хәтәрен.*
*Үлеп булмый үлгән артыннан,*
*Итәк тулы бала күтәреп тә,*
*Ятим калдылар бит әле хатыннар!*
*Иң авыры әле булмады,*
*Сугыш беткәч булды авыры.*
*Май кояшы җиргә нурын сибә,*
*Ява иде ләйсән яңгыры.*
*Бөтен халык каршы ала иде,*
*Сугышлардан җиңеп кайтканны.*
*Шушы көндә улым беренче кат:*
*"Минем әти,- диде,- кайтамы?"*
*"Кайта",- дидем,*
*Мин алдадым аны.*
*Үсә төшкәч, үзе аңлады.*
*Мин үзем дә ничә еллар буе*
*Үз-үземне шулай алдадым.*

*Сәхнәнең икенче ягыннан, сугыштан кайтмый калган сөйгәнен сагынып җырлап, бер кыз чыга.*
*Җыр "Син кайтмадың"*

**Бер кыз:**

*Бакчаларда гөлләр чәчәк атты,*
*Тормышыбыз кебек ямьләнеп.*
*Урман күлләренә аккош кайтты,*
*Сандугачлар килде әйләнеп.*
*Сандугачлар килде, аккош кайтты,*
*Син кайтмадың киткән җиреңнән.*
*Аккош китәр урман күлләреннән*
*Син китмәссең минем күңелемнән.*

**4нче солдат:**

*(кыз янына килеп тезләнә)* Кичерегез безне, аерылганда биргән вәгъдәләрегезгә тугры калып, "Кайтыр!" дип безне көтә-көтә, саргаеп картайган кызлар!

**5нче солдат:**

*(ана янына барып тезләнә)* Кичерегез безне, ялгыз башы дөнья көтеп, уллар һәм кызлар үстереп, вакытсыз сулган аналар!

*Карт анам!*
*Мине тудырганга*
*Үкенмисең...Әйеме?*
*Әйт, анам!*
*Карт анам,*
*Төнлә йомшак түшәгеңдә,*
*Матур төшләр күреп ят, анам,*
*Зинһар өчен...*
*Дөрләп ут янганда,*
*Мине уйлаганда,*
*Кышкы кичтә мичкә карама.*
*Мичләр сүнәр,*
*Өй караңгы калыр,*
*Лампочкалар яндыр, карт анам.*

*Синең күңелеңә мин бары тик*
*Якты булып кына кайталам.*
**Ана:**
*(улын назлап*) *Бер кайгырсам, ике шатланам,*
*Һәр тамчысы хәләл сөтемнең.*
*Илдә мәңге үлмәс ат белән*
*Үлә белгән уллар үстердем.*
**Алып баручы кыз:**
*Матурлыгы өчен бу көннәрнең*
*Кемнәр генә корбан булмаган.*
*Исемнәрен тарих үзе безгә*
*Саклап килә ерак еллардан.*
**6нчы солдат:**
Без – исемнәре калган һәм исемсез югалганнар.
Без - Фучиклар, Мусалар, Алишлар, Карбышевлар һәм алар шикелле меңнәр.
*Муса (Наил) "Ышанма" шигыре.*
**Хәйретдин Мөҗәй:**
*Германия.*
*Дахау.*
*Концлагерь.*
*Мине*
*Фашизмга*
*Буйсынмаган өчен аттылар.*
*Бер минуттан*
*Крематорийга озаттылар.*
*Мин* -
*Илемнең өлкән офицеры.*
*Янган утка керү алдыннан*

*Шигырь сөйлим.*
*Язмасын, дип, минем кулларымны*
*Имгәттеләр, каерып алдылар.*
*Күзләрем – кан,*
*Телем телгәләнгән.*
*Күкрәгемә йолдыз уелган.*
*Тик бер минут,*
*Тик бер минут кына вакытым калган,*
*Гомерем уза минем уемнан.*
*Кояш байый, минем йөрәгемнән*
*Каннар коела.*
*Таммас күз яшем,*
*Мин утларга керәм, Германия,*
*Чыксын өчен синең кояшың.*
*Янам шуңа:*
*Минем оныкларым*
*Сугыш дәһшәтләрен онытсын.*
*Киләчәк...*
*Ул шундый матур булыр:*
*Сугышлар да булмас, дошман да...*
**Фатих Кәрим:**
*(кулында хат)*
*Бәлки бу хат – соңгы хатым булыр,*
*Иң дәһшәтле утка керәмен.*
*Шулай була калса, кояшны да*
*Бүген соңгы тапкыр күрәмен.*
*Үләм икән, үкенечле түгел,*
*Бу үлемнең миңа килүе.*
*Бөек җыр ул - Бөек Ватан өчен*
*Сугыш кырларында үлүе.*
*Мин сугышка керсәм, дошманымның*
*Йөрәгенә төзәп атамын.*
*Үзем үлсәм, балаларым кала,*
*Минем гомерем булып, Ватаным.*
*Сөйләп бетерүгә, әтиләре янына ике бала чыгып, кулларын сузып сөйли башлыйлар.*
**Яшүсмер кыз бала:**
*Әти, җаным, вакыт бит инде –*
*Кайт инде син, әтием, тиз инде.*
*Әти, мин дә, әни шикелле,*
*Бик сагындым инде үзеңне.*
*Инде безгә синсез күңелсез,*
*Инде безгә синсез ямансу.*
*Уйнамыйбыз синсез, көлмибез,*

*Безнең хәлне шуннан аңларсың.*
*(Күзләрендә яшь, өзгәләнү).*

**Икенче кыз:**

*Шаян килеш кайт син яудан да,*
*Миңа тагын кызык ясарга.*
*Их, син кайткач...өйдә яңадан*
*Ипи булыр иде.*
*Әти, җаным, вакыт бит инде –*
*Кайт инде, әтием, тиз инде.*
*Әти! Мин дә, әни шикелле*
*Бик сагындым инде үзеңне.*

**Яшүсмер малай:**

Без – кырык беренче ел балалары.

Миләрдә 2-3 кенә тирән сыр бар.

Аның берсе – сугыш, канкойгыч сугыш турында.

Фронтка икмәк кирәк. Без, атасыз калган тәртипсез малайлар, әнә шул икмәкне кырдан җыеп, загатзернога озатырга тиешбез. Мидә икенче сыр – ашау турында. Кайда гына, кайчан гына авызга кабарлык нәрсә булса, без аны кабарга, йотарга тиешбез. Ә йотарлык әйбер һәр җирдә бар. Алабута, кычыткан, чөгендер, яшь бәрәңге яфрагы – болары ашка китә.

Табигать бай – үз баласын ничек тә саклый. Ә икмәк фронт өчен!

*Сәхнәгә сугыш чорындагы киемдә Айсылу урак, чүкеч төшкән байрак тотып чыга. Башында кызыл косынка.*

**Айсылу:**

Иптәшләр, без дошманны икмәк белән, үзебезнең эшебез белән кыйныйк. Безнең колхозда туган иле өчен, фронт өчен менә шулай җанын – тәнен аямыйча эшләүчелер бармы? Бар, иптәшләр, бар андыйлар, аз да түгел. Сугышның иң кыен вакытында, безнең колхозда гвардиннар бригадасы туды. Нәфисә бригадасының бодай җиреннән генә дә бүгенгесе көнне без 5000 поттан артык ашлык көтәбез. Без аны алырбыз да! Чулпан идарәсе һәм җәмәгать оешмалары Нәфисә бригадасына, фронттагы гвардиннарга көрәшүе өчен шушы кызыл байракны тапшырырга карар итте. Бөтен колхоз исеменнән, партия оешмасыннан бик зур рәхмәт сезгә, туганнар. *(Байрак тапшыра.)*

**Нәфисә:**

Туган илебез шундый авыр көннәр кичергән чагында, кулга корал алып, сугышның үзенә барырга туры килмәде. Моннан торып та фронтка ярдәм итә алуыма бик куанам, иптәшләр! Әнә минем өлешем шул булсын: өстәмә итеп бирелә торган бодаемны бөтен килеш, бөртегенә кадәр, Сталинград сугышчыларына бүләк итеп бирәм!

**Айсылу:**

Бик зур рәхмәт сиңа, Нәфисә, рәхмәт. Монысын да син башлап җибәрдең. Бу – батырлык ичмасам!

*Сәхнәгә очучы киеменнән Мәгүбә Сыртланова чыга. Бомба тавышы.*

**Мәгүбә Сыртланова:**

*Җиңел генә җиңәргә,*

*Өмет итмәсен дошман.*
*Үлемгә каршы үлем,*
*Канга каршы кан.*

Мин – гади татар кызы Мәгүбә апагыз Сыртланова. Өч ел эчендә 23 меңнән артык очыш ясадык, дошман өстенә 3 миллион кг бомба ташлап, аңа һәрьяклап зыян китердек. 23 кызга Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Шуларның берсе Мәгүбә апагыз. Фронтта 1080 көн үткәрдек. Кадерлеләрем, Мәгүбә апагызны онытмагыз, яме. Хушыгыз. Бәхил булыгыз. Мин үз бурычымны үтәдем. Дөнья сезгә кала. Җирне бизәгез, тынычлыкны саклагыз... Шул сезгә соңгы әманәт.

**Алып баручы кыз:**
*(кулында чәчәк) Җиңүчеләр калка һәйкәл булып,*
*Һәйкәл булып баса Батырлар.*
*Ә Батырлар үлми ике тапкыр –*
*Алар хәзер мәңге балкырлар!*
*Таш һәйкәлләр балкый эчтән генә,*
*Җырлый алар акыртын гына.*
*Һәйкәлләргә килик!*
*Гөлләр куйыйк!*
*Һәйкәлләрне тыңлыйк тын гына!*

Ә хәзер Бөек Ватан Сугышында һәлак булганнар өчен бер минутлык тынлык.

**1нче алып баручы егет авансценада:**
*Без батырлык эзләп яшәмибез,*
*Батырлыкка ләкин без әзер –*
*Кирәк булса, үлемебез белән*
*Ныгытырбыз илне,*
*Бизәрбез!*
*Җәлилчеләр кебек!*
*Еллар аша*
*Үрнәкләре тора яктырып.*
*Ватан өчен үлү – безнең бурыч!*
*Батырлыктан туа матурлык!*

**Ана:**
*(алып баручы егет янына килеп)*
*Кабул булса икән теләкләрем:*
*Имин атсын*
*Килер иртәләр!*
*Шул иртәләр*
*Хәтерләтеп торсын.*
*Сиңа, улым,*
*Синең тиңнәргә:*
*Аталарның йөге –*
*Ил язмышы*
*Күчә бара сезнең иңнәргә!*

**Алып баручы кыз:**
*Гел көрәштә ирләр!*
*Яулар өчен*
*Үрләр генә булсын, үрләр генә!*
*Яуланмаган үрләр буламы соң –*
*Исән булсын кыю ирләр генә!*
*Илләр якты,*
*Көннәр якты безнең –*
*Исән булсын илдә ирләр генә!*
*Туган илнең батыр ирләренә*
*Тиңнәр генә булсын, тиңнәр генә!*
**Бергә:**
*Ил язмышы – Ирләр иңендә!*

*Музыка.*
*Тәмам*

***Фирдәвес Әһлия***

## “Туган тел ачкычы”

**Катнашалар:** *Саескан, Бака, Куян, Булат, Аю.*

*Вакыйга җәй көне урманда, күл буенда бара.*

**Саескан:** *(сәхнәгә килеп керә)* Аһ, нинди матур, ялтыравык нәрсә таптым әле мин. *(Әйләндереп карый.)* Нәрсә икән бу, ә? Ояма алып меним әле. Бәлки кирәге чыгар. *(Чыгып китә.)*

**Бака:** *(килеп керә)* Әй, Саескан. Син нәрсә, тимер-томыр, металлом җыясың мәллә, ә? Күл төбендә йокымсырап ята идем, әллә нинди авыр нәрсә башыма килеп төшмәсенме?! Тәмле йокыларым әллә кая очты.

**Саескан:** *(яшеренгән урыныннан чыгып)* Кайда, үземә бир әле. Карыйм әле, нәрсә икән?

**Бака:** Йә, ничек бирим, ди, инде мин сиңа. Су астында, күл төбендә калды ич ул.

**Саескан:** Аһ, харап кына булганмын икән. Йә, ярый, берәр җаен табарга иде бит. Бака апа, җаным-бәгърем, алып бирче миңа ул нәрсәне су төбеннән, ә?

**Бака:** Мин сиңа аквалангист түгел лә, җыен тимер-томыр алам дип, су төбенә чумарга! Үзең төш.

**Саескан:** Үтенеп сорыйм. Ул миңа бик кирәкле нәрсә иде.

**Бака:** Нәрсәгә кирәк шулхәтле?

**Саескан:** Коллекция җыя идем. Бик кирәк иде.

**Бака:**Үзең төш. *(Ул күлгә чума.)*

**Саескан**:*(аны үртәп кала) Бака, Бака, бакылда,*
*Су төбендә ят шунда.*

*Сәхнәгә Куян йөгереп керә.*

**Куян:**Баканы үртәгән буласың тагын. Син үзең дә такылдык ич. Берәр яңа хәбәр әйтсәң иде, ичмаса.

**Саескан:** Ә, кылый! Син икәнсең әле бу. Кил әле бирегә. Сер итеп кенә бер сүз әйтәм үзеңә.

**Куян:** Нинди сер ул? Әйт тизрәк.

**Саескан:** Беләсеңме, менә шушы күлдә алтын балык яши.

**Куян:** Кит аннан. Булмас ла.

**Саескан:** Чын әгәр. Менә шушы балыкны тотсак, ул безнең бөтен теләкләребезне дә үтәп торыр иде.

**Куян:** Мин балык тота белмим шул.

**Саескан:** Бер авырлыгы да юк аның. Кармак кирәк, бетте-китте.

**Куян:** Кар-мак? Нәрсә соң ул?

**Саескан:** Берәр чыбыкка бау бәйлисең дә, таш элеп куясың. Менә, булды да. Тот, әйдә, алтын балыкны!

**Куян:**Такылдама әле. Үзем дә беләм. *(Кармагын алып, күл буена килә, җырлый.)*

*Алтын балык тотармын,*

*Нәрсәдер мин отармын.*

Хоп, булды. *(Яр өстенә бер тимер кисәге килеп төшә. Саескан шундук аның янына килеп җитә.)*

**Саескан:** О, бу бит минем табылдык.

**Куян:** Бик акыллы икәнсең. Аны бит мин тоттым. Яртысы миңа.

*Табылдыкка ике яктан ябышып, тарткалаша башлыйлар.*

**Саескан:** Минеке.

**Куян:** Юк, минеке.

**Саескан:** Аны ничек бүлешәбез инде? Әйдә әле, чыпчыктан сорыйк. *(Куян күккә караган арада, табылдыкны эләктереп кача. Куян да йөгереп китә. Булат керә.)*

**Булат:** Кая гына югалды икән соң инде бу ачкыч, ә? Уку елы башланыр алдыннан әни аны миңа бүләк иткән иде. «Тел ачкычлары мәктәптә бик кирәк була, сакла аны, улым!» дигән иде. Ә мин ачкычны югалттым. Аны тапмыйча өйгә, әнием янына да кайта алмыйм инде. Нишләргә?

**Саескан:** *(качып торган урыныннан)* Әй, малай. Нәрсә эзлисең син? Миңа да әйт әле.

**Булат:** Әйтте, ди, хәзер. Бөтен урманга таратыр идең, ә?

**Саескан:**Юк инде, ярдәмем тимәсме дип кенә соравым. Теләсәң нишлә.

**Булат:** Йә, ярый инде, әйтәм. Ачкычымны эзлим мин.

**Саескан:** Алтын ачкыч түгелдер бит?

**Булат:** Алтынын алтын түгел дә, бик кыйммәтле, зиннәтле ачкыч.

**Саескан:** Ә мин... беләм бугай аның кайда икәнен.

**Булат:** Әйт тизрәк!

**Саескан:** Әгәр дә әйтсәм, миңа ни бирәсең?

**Булат:** Нәрсә сорасаң, шул булыр.

**Саескан:** Оям тузган минем. Яңа өй кирәк иде.

**Булат:** Булыр сиңа яңа өй. Әйт кенә.

*Саескан Булатка ачкычны ташлый. Малай эләктереп ала. Шул чагында урманнан Аю килеп чыга.*

**Аю:** Кайда, нәрсә ул синең кулыңда?

**Булат:** Ачкыч кына, Аю абзый. Нәрсәгә ул сиңа?

**Аю:** Урманымда мин - хуҗа. Бар нәрсә дә монда минеке. *(Булат Аюга ачкычны бирә.)*

О, матур! Ялт-йолт килеп тора. Мин аны, медальон итеп, тагып йөриячәкмен. Күрсеннәр, кем килә.

**Булат**: *(ялварып)* Аю абзый, ә син миңа ул ачкычны бүләк итә алмассың микән, ә?

**Аю:** Нәрсәгә ул сиңа?

**Булат:** Беләсеңме, ул бит... туган тел ачкычы. Анам теле ачкычы. Ачкыч белән бергә Анам теле югала, менә. Миңа аңардан башка яшәү юк.

**Аю:** Шулай ук мыни? Ярый, алайса. Ал үзеңнең ачкычыңны. *(Ул Булатка ачкычны суза.)*

**Булат:** Рәхмәт, Аю абзый. Моның өчен мин урманга, табигатькә, сезнең барчагызга карата мәрхәмәтле булырга вәгъдә итәм.

**Барысы бергә:**

*Газиз ана телебезне,*
*Беркайчан да онытмыйк.*
*Туган телебез ачкычын,*
*Мәңге-мәңге югалтмыйк.*

*Тәмам*

***Закирова Гөлнара Шамил кызы***
*Татарстан Республикасы, Казандагы катнаш төрдәге 355 нче балалар бакчасы I категорияле музыка җитәкчесе*

## “Яңа ел мажарасы”

*Балалар залга кереп, шигырь сөйлиләр, җырлыйлар. Араларында шүрәле балалары, кар бөртекләре булып киенгән балалар бар.*

*Балалар урындыкларга утыралар. Ут сүнә. Шүрәле булып киенгән балалар чыршы артыннан чыгып, кар бөртекләрен алып чыгып китәләр. (Ф. Яруллинның “Шүрәле” балетыннан өзек кулланыла.)*

*Ут яна, барлык балалар урындыкларга утыра.*

**Алып баручы:** Нәрсә булды бу, балалар?

**Бала:**

*Шүрәле балалары*
*Килделәр дә чыктылар.*
*Безнең кар бөртекләрен*
*Алып чыгып киттеләр.*

**Алып баручы:** Нишлибез инде, балалар?

**Бала:**

*Кар бөртекләрен*
*Эзлик бергәләп.*
*Кар кызы безгә*
*Килсен ярдәмгә.*

**Алып баручы:** Бик дөрес әйтәсез. Бергәләп Кар кызын чакырыйк!

**Бергә:**

*Кар кызы, кил монда,*
*Син кирәк әле безгә!*

*Кар кызы керә.*

**Кар кызы:**

*Ишетәм сезне, дусларым!*
*Исәнмесез, матурларым!*

**Бергә:**

Исәнме, Кар кызы!

**Кар кызы:**

*Бәйрәмгә җыелгансыз:*
*Чыршыны бизәгәнсез.*
*Үзегез дә, балалар,*
*Бик матур киенгәнсез.*
*Тик, йөзләрегез моңсу,*
*Ни булды сезгә, Алсу?*

**Алсу:**

*Шүрәле балалары*
*Килделәр дә чыктылар.*
*Безнең кар бөртекләрен*
*Алып чыгып киттеләр.*

**Бала:**

*Кар бөртекләрен*
*Коткарыйк бергә.*
*Син дә, Кар кызы,*
*Ярдәм ит безгә!*

**Кар кызы:** Әлбәттә, булышам! Ләкин, нишләргә? Шүрәле балалары дисезме?

**Бергә:** Әйе!

**Кар кызы:**Шүрәлеләр кайда яши?

**Бергә:**Урманда!

**Кар кызы:** Димәк, кар бөртекләрен дә шунда алып киткәннәр. Ә урманда минем дусларым күп, булышмый калмаслар. Балалар, урманга киттек!

*Кар кызы һәм балалар чыршы тирәли әйләнәләр. Чыршы каршына куяннар чыгып баса, калган балалар урындыкларга утыралар.*

**Кар кызы:** Исәнмесез, нәни дусларым - озын колакларым!

**1нче куян:**

*Нишләп йөрисез монда -*
*Кышкы салкын урманда?*
*Әллә адаштыгызмы,*
*Юлны югалттыгызмы?*

**Кар кызы:**Юк, куянкайлар, адашмадык. Без шүрәле балаларын эзләп йөрибез. Ул явызлар чыршы бәйрәменнән кар бөртекләрен урлап качканнар.

**2нче куян:** Бәйрәмнән? Кар бөртекләрен? Шүрәленең кайда торганын белмибез. Аны бүре белән төлке белә.

**3нче куян:** Без юл күрсәтербез, сез безне дә бәйрәмгә аласызмы?

**Кар кызы:** Алырбыз. Сез нәрсә эшли беләсез соң?

**Куяннар:** Оркестрда уйныйбыз!

*Куяннар уен коралларында уйныйлар.*

**Кар кызы:**Ай, матур уйнадыгыз. Рәхмәт. Юлыбызны дәвам итик, төлке белән бүре янына барыйк.

*Кар кызы, куяннар, балалар чыршы тирәли әйләнәләр. Балалар урындыкларга утыралар, чыршы алдына бүре белән төлке чыга.*

**Кар кызы:** Исәнме, бүре, исәнме, төлке.

**Бүре, Төлке:** Исәнме, Кар кызы!

**Бүре:**

*Нишләп йөрисез монда* -
*Кышкы салкын урманда?*

**Төлке:**

*Әллә адаштыгызмы,*
*Юлны югалттыгызмы?*

**Кар кызы:** Юк, юк, дусларым, адашмадык. Без шүрәле балаларын эзләп йөрибез. Алар чыршы бәйрәменнән кар бөртекләрен урлап качканнар.

**Төлке:** Бәйрәмнән? Кар бөртекләрен? Шүрәленең кайда икәнен белмибез, аны аю белә.

**Бүре:** Без юл күрсәтербез, сез безне дә бәйрәмгә аласызмы?

**Кар кызы:** Әлбәттә, алабыз. Бәйрәмдә нишләрсез, һөнәрләрегез бармы?

**Төлке:** Без бии беләбез!

*Бүре белән төлке биләр, аларга кушылып балалар да бии.*

**Кар кызы:** Бик матур биедегез. Юлга чыгарга вакыт, киттек аю янына!

*Чыршы тирәли әйләнеп чыгалар.*

*Балалар утыралар, чыршы төбендә аю йоклап утыра.*

**Кар кызы:**

*Әй, аюым-аюкай,*
*Уян әле син, дускай!*

*Аю икенче якка борыла, уянмый.*

**Кар кызы:** *Әй, аюым-аюкай,*
*Уян әле син, дускай!*

*Аю икенче якка борыла, уянмый.*

**Кар кызы:**Балалар, нишлибез инде? Һич кенә уятып булмый аюны.

**Бала:**

*Әйдәгез, җырлап карыйк!*
*Аны шулай уятыйк.*

*Балалар күмәк җыр башкаралар.*

**Аю:**

*Кем җырлап йөри монда,*
*Мин тәмләп йоклаганда?*

**Кар кызы:**

Исәнме, аю дус!

**Аю:**

*Исәнме, Кар кызы!*
*Нишләп йөрисез монда -*
*Кышкы салкын урманда?*
*Әллә адаштыгызмы,*
*Юлны югалттыгызмы?*

**Кар кызы:** Юк, юк, аюкай, адашмадык. Шүрәле балаларын эзлибез. Алар чыршы бәйрәменнән кар бөртекләрен урлап качканнар.

**Аю:** Бәйрәмнән? Кар бөртекләрен? Әлбәттә, булышам. Кара әле син аларны!

*Балалар, җәнлекләр, Кар кызы чыршыны әйләнеп чыгалар да, урындыкларга утыралар. Чыршы каршында зур мишурага уралган кар бөртекләре, аларны сөңге тоткан шүрәле балалары саклап тора.*

**Кар кызы:** Балалар, кар бөртекләрен эзләп таптык, ләкин аларны коткару бик авыр. Монда Кыш бабайсыз булмас, аның ярдәме кирәк. Чакырыйк аны тизрәк!

**Бергә:**

Кыш бабай!

**Кар кызы:**

Ай, ишетми, тагын чакырыйк.

**Бергә:**

Кыш бабай!

*Кыш бабай керә.*

**Кыш бабай:**

Ау, ау, ишетәм сезне, балаларым! Исәнмесез, оныкларым!

**Бергә:**

Исәнме, Кыш бабай!

**Кыш бабай:**

*Ни булды әле сезгә?*
*Борчыласыз сез нигә?*

**Кар кызы:**

Әй, Кыш бабай, күр әле син бу шүрәле балаларын?! Бәйрәмебезне бозып, ямьсезләнеп йөриләр.

**Кыш бабай:**

Ах, аларны! Хәзер, булышам (*сихерли).*

*Җилләр, җилләр, исегез,*
*Сез бирегә килегез.*
*Шүрәле балаларын*
*Сыннар итеп куегыз!*

*Җил сызгыра, шүрәле балалары сыннар булып катып калалар. Кар бөртекләрен тотып торган "богаулар" өзелә. Кызлар бииләр дә, Кыш бабай янына йөгереп киләләр.*

**1нче кар бөртеге:**

*Рәхмәт сиңа, Кыш бабай,*
*Рәхмәт сиңа, Кар кызы!*

**2нче кар бөртеге:**

*Рәхмәт сезгә, балалар,*
*Һәм урмандагы дуслар!*

*Кар бөртекләре утыралар.*

**Кар кызы:**

Кыш бабай, бу шүрәле балалары бәйрәмнең ямен алып торалар.

**Кыш бабай:**

Нишлик соң, балалар?

**Балалар:**

Җебетик, ачуланыйк!

**Кыш бабай**:

(сихерли) *Җилләр, җилләр исегез,*
*Сез бирегә килегез.*
*Шүрәле балаларын*
*Үз хәленә кертегез!*

*Җил сызгыра, шүрәле балалары әйләнәләр дә, үз хәлләренә кайталар. Кыш бабайдан ераграк басалар, аннан куркалар.*

**Кыш бабай:**

*Ник алай кыландыгыз?*
*Ник бәйрәмне боздыгыз?*

**1нче шүрәле баласы:**

*Кызларга бүләкләр бар,*
*Малайларга бүләк бар.*
*Безне искә алучы юк,*
*Ә бит без дә балалар!*

**2нче шүрәле баласы:**

*Яңа елда Кыш бабайдан*
*Без дә көтәбез бүләк.*
*Тик күпме генә көтсәк тә,*
*Үтәлми безнең теләк.*

**Кыш бабай:**

Эх, шайтан балалары! Бүләкне матур итеп сорап алалар, я Кыш бабайга хат язалар. Әти-әниләренең сүзләрен тыңлаган, аларга булышкан балаларга алып киләм мин бүләк. Ә сез нишләдегез?

**Шүрәле балалары:**

Без бит белмәдек! Бүтән алай эшләмибез! Гафу итегез безне!

**Кыш бабай:**

Нишлибез, балалар? Гафу итәбезме?

**Бергә:**

Итәбез!

**Кыш бабай:**

*Алай булгач, бергәләп,*
*Ясыйк әле түгәрәк!*
*Чыршы тирәли йөрик,*
*Күңелле җырлар җырлыйк!*

*Балалар җырлыйлар, Кыш бабай белән уйныйлар, аңа шигырьләр сөйлиләр.*
*Кар кызы капчыктан палас тартып чыгара.*

**Кар кызы:**

Бабай, бу нинди палас?

**Кыш бабай:**

Кагыла күрмә, кызым, ул палас сихергә ия. Аны идәнгә җәйсәң, аякларны туктатып булмый - бииләр дә бииләр!

**Кар кызы:**

Юктыр, бабай, юри әйтәсең син.

*Паласны идәнгә җәя һәм бии башлый.*

**Кар кызы:**

Бабай, мин ардым инде, коткар мине!

*Кыш бабай, аңа булышмакчы булып, кулын суза, ләкин паласка баса да, ул да бии башлый.*

**Кар кызы:**

Бабай, туктат инде!

**Кыш бабай:**

Туктамый шул ул. Залдагы барлык балалар биемичә, туктатып булмый аны.

**Кар кызы:**

Балалар! Коткарыгыз! Чыгыгыз тизрәк биергә!

*Күмәк бию. Биегән арада, сиздермичә генә зур Шүрәле кереп, Кыш бабайның капчыгын алып чыгып китә. Музыка туктый.*

**Кар кызы:**

*(паласны җыеп ала)* Бабай, яшереп куй моны тизрәк. Каян гына тапкансыңдыр!

**Кыш бабай:**

Бир, кызым, урынына куярмын. Кая соң капчык? Юкка чыккан!

**Кар кызы:**

Нишлибез инде? Бүләкләр өләшер вакыт та җитте.

**Кыш бабай:**

Борчылма, кызым, курыкмагыз, балалар. Хәзер беләбез ул каракны! *(сихерле)*

*Җилләр, җилләр, исегез,*
*Сез бирегә килегез.*
*Кем капчыкны урлаган*
*Монда алып килегез!*

*Җилләр исә, җилгә ияреп, әйләнә-әйләнә, зур Шүрәле керә. Кулында Кыш бабай капчыгы.*

**Кыш бабай:** Ах, син, карак! Китер монда капчыкны!

**Шүрәле:** Хәзер, шулай иткән ди! Үземә дә бик кирәк. Балаларга конфет, шоколад, бүләкләр, ә миңа нәрсә?

*Бала шүрәлеләр йөгереп чыгалар.*

**Бала шүрәле:** Шүрәле абый, бир син капчыкны!

**Шүрәле:** Ах, сез дә мондамени? Мин бит сезне секретный заданиега җибәрдем. Кая Кар бөртекләре?

**Шүрәле балалары:** Юк, без андый әшәке булмыйбыз!

**Шүрәле:** Сатылдыгызмы? Абзагызны саттыгызмы? Ах, сезне!

*Балаларны куркыта, алар качалар.*

**Кыш бабай:** Ни кыланасың әле син, урман сарыгы? Нишләтик моны, балалар? Бигрәк әшәкеләнә бит.

**Кар кызы:** Бабай, паласка бастырабызмы әллә?

*Паласны җәеп сала. Шүрәлене шунда басарга чакыра.*

**Шүрәле:** Тапканнар җәза! Басам, басам! Рәхәтләнеп басам!

*Шүрәле паласка баса да бии башлый. Капчыгын саклый, аны кочаклап бии. Бераз биегәч, "җибәрегез", – дип ялвара башлый. Капчыкны Кыш бабайга бирә. Музыка туктый, Шүрәле аксый-аксый чыгып китә.*

**Кыш бабай:** Явызлардан котылдык, бүләк өләшер вакыт җитте.

*Бүләк өләшкәч, Кыш бабай белән Кар кызы саубуллашып чыгып китәләр.*

*Тәмам*

***Хәсәнова Ралия Ринат кызы***
*Татарстан Республикасы*

## "Чын дуслык"

**Катнашалар:** *Мөхтәр абый, Зәйнәп апа, Әтәч, Тавык, Акбай, Мияу, Керпе, Куян, Төлке, Бүре*

*Борын-борын заманда бер матур чиста зур өйдә Зәйнәп апа белән Мөхтәр абый бик тату яшәгәннәр. Аларда йорт хайваннары да булган. Алар арасында Акбай, Әтәч, Тавык һәм чебиләр дә булганнар. Хайваннар хуҗаларга гел булышып торганнар. Бер матур җәйге көндә Әтәч иртән-иртүк уянып, хуҗаларын уяткан. Мөхтәр абый йорт алдына чыгып, Әтәч янына килгән.*

**Мөхтәр абый:** Хәерле иртә, Әтәч!

**Әтәч:** Хәерле иртә! Хәлләр ничек?

**Мөхтәр абый:** Әйбәт, рәхмәт. Хәлләр ничек, Әтәч?

**Әтәч:** Әйбәт түгел, бездә зур кайгы - чебиләребезне Төлке урлады.

**Мөхтәр абый:** Ничек булды мондый хәл? Акбай сакларга тиеш иде йортыбызны. Хәзер мин аның белән сөйләшәм.

*Мөхтәр абый артыннан Зәйнәп апа чыккан һәм Тавык янына килгән.*

**Зәйнәп апа:** Исәнме, Тавык. Хәлләр ничек?

**Тавык:** *(елап)* Исәнме, Зәйнәп апа. Әйбәт түгел. Төнлә Төлке килеп, чебиләремне урлады.

**Зәйнәп апа:** Елама, хәзер Мөхтәр абыең берәр нәрсә хәл итәр. Борчылма.

*Капка төбендә Акбай җәелеп йоклап яткан, бабай аның янына килеп сөйләшә башлаган.*

**Акбай:** Исәнме, Мөхтәр абый. Хәлләр ничек?

**Мөхтәр абый:** Әйбәт түгел. Син нигә төнлә йортны сакламыйсың? Төлке кереп, чебиләрне урлап киткән бит! Безгә мондый саклаучы кирәкми, бар, чыгып кит өйдән, чебиләрсез кайтма!

*Акбай башын иеп, чыгып та киткән. Бара-бара, дусты Мияуны очраткан.*

**Мияу:** Исәнме, Акбай.

**Акбай:** Исәнме, Мияу.

**Мияу:** Хәлләр ничек, Акбай?

**Акбай:** Әйбәт түгел. Мине хуҗам өйдән куып чыгарды. Төлке урлаган чебиләрне табып кайтырга кушты.

**Мияу:** Борчылма, мин сиңа булышырмын. Әйдә, бергәләп эзлик.

*Акбай белән Мияу урманга чебиләрне эзләп киткәннәр. Бара-бара, аларга кечкенә генә Керпе очраган.*

**Акбай:** Исәнме, син кем?

**Керпе:** Мин - Керпе. Син кем?

**Акбай:** Мин - Акбай.

**Мияу:** Ә мин - Мияу.

**Керпе:** Хәлләрегез ничек?

**Мияу:** Әйбәт түгел. Безгә чебиләрне табып кайтырга кирәк. Төлке аларны урлады.

**Керпе:**Бүген мин аны Бүре белән күргән идем. Капчыкта нәрсәдер сөйрәп, урман эченә кереп баралар иде.

**Акбай:**Рәхмәт бик зур. Без кечкенә чебиләрне коткарырга тиеш.

*Безнең сәяхәтчеләребез урманда йөри-йөри, караңгы төшкәнен сизми дә калганнар. Шулвакыт аларга дер-дер калтыраган Куян очраган.*

**Акбай:**Исәнме, син кем?

**Куян:**Мин - Куян. Син кем?

**Акбай:**Мин - Акбай.

**Мияу:**Ә мин - Мияу. Хәлләр ничек, Куян?

**Куян:** Әйбәт түгел. Мин караңгы урманнан бик куркам, төнлә монда Бүре белән Төлке эзләнеп йөри. Алардан качар өчен урын табарга кирәк. Сезгә дә монда озакка калмаска киңәш итәм. Сау булыгыз *(сикерә-сикерә качарга җыена.)*

**Акбай:** Тукта, тукта, Куянкай, аларны ерак күрдеңме? Ул хәйләкәр Төлке бүген төнлә хуҗамның чебиләрен урлаган. Мин аларны табып алып кайтырга тиеш.

**Куян:** Алай булгач, алар менә монда икәүләшеп йөриләр иде *(урманның уң ягына төртеп күрсәтә).*

**Акбай:** Рәхмәт, Куян. Саубул.

*Караңгы төшеп беткәч, урманда бернәрсә күренми башлаган. Акбай белән Мияу тиздән Бүре белән Төлке тавышларын ишеткәннәр. Алар бер агач артына качып*

*утырганнар да, чебиләрне коткару планын кора башлаганнар. Ерткычларның тавышлары якынайганнан якынайган, алар капчыкны сөйрәп, ашарга утырырга урын эзләп йөргәннәр.*

**Бүре:** Төлкекәем, бир инде миңа берәр чебине, үлеп ашыйсым килә.

**Төлке:**Тукта әле, мин дә ач бит. Түз әз генә. Хәзер утырырбыз.

*Шул арада Акбай белән Мияу зур гына бау табып, агачка бауның бер башын бәйләп, икенчесен икенче агачка урап, бушайтып куйганнар.*

**Акбай:** Алар бу урыннан барганда, син бауның икенче башын нык кына иттереп тартырсың. Төлке белән Бүре аугач, мин капчыкны алырмын да, икебез тиз генә аларны бәйләп куярбыз. Аңладыңмы?

**Мияу:**Әйе. Мин синең белән ризалашам.

*Бүре белән Төлке, ашыга-ашыга барган арада, җирдә яткан бауны күрмичә калганнар. Шул арада Мияу бауны тартып, ерткычларны еккан. Акбай капчыкны кырыйга алып куеп, Мияуга аларны бәйләргә булышкан. Төлке белән Бүре шаккатып калганнар.*

**Мияу:** Бу оятсызларны авылга алып кайтыйк. Шунда хуҗаң белән бергә аларга нинди җәза бирергә икәнлеген киңәшербез.

**Акбай:** Ярар, дустым. Бик зур рәхмәт сиңа! Син - минем чын дустым! Миңа бик булыштың.

*Шулай сөйләшеп, авылга кайтканнар. Мөхтәр абый белән Зәйнәп апа бик шатланып, аларны каршы алганнар. Акбайны кичереп, Мияу белән икесен бәлеш, чәк-чәк, гөбәдия белән сыйлаганнар, рәхмәтләрен әйтә-әйтә кочаклаганнар. Ә Төлке белән Бүре, гафу үтенеп, бүтән мондый эшкә бармаска вәгъдә иткәннәр. Хуҗалар, аларны да кичереп, урманга җибәргәннәр. Чыннан да, бу вакыйгадан соң авылда беркайчан да шундый начарлыклар булмаган.*

*Акбай белән Мияу гел дус булганнар, бер-берсенә гел булышканнар. Бер сүз белән әйткәндә, дуслык – зур байлык, дип татар халкы юкка гына әйтмәгән инде. Дусларны сакларга һәм кадерләргә кирәк!*

***Мөхәммәтшина Эльмира Госман кызы***
*Татарстан Республикасы*

## “Малай һәм кояш”

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Пәрдә ачылганчы, баянда талгын музыка уйнала.*

*Кечкенә генә матур агач йорт,ишегалдында бер кечкенә малай – Ансаф, 5-6 яшьләр тирәсендә, планшет белән уйнап утыра. Ансафның әнисе – Нәфисә кер юа,*

*икенче бер читтә бабасы Шәриф абзый ат арбасы ремонтлап маташа. "Беренче мәхәббәт” җыры агыла, Нәфисә үзе эшен эшли, үзе җырлый. Шәриф баян белән уйнап җырлый. Ә Ансафның үз эше, планшетта уен уйный, кулларын күтәреп - күтәреп ала... Җыр тәмам... Пауза.*

**Нәфисә:** Ансаф, улым, аш суына, ашарга кер, күпме әйтергә була сиңа, вакытында ашамасаң – кечкенә каласың.

**Ансаф:** Хәзер инде, әни, хәзер, уенның иң кызык җиренә җиттем бит, өлгерермен әле.

*Ансаф, әтисе калдырып киткән планшет белән уйнавын дәвам итә. Өйдән әбисе – Мәликә карчык чыга.*

**Мәликә:** Ансаф, улым, әйдә инде, уен качмый ул, ашап ал. Һай, бу балалар, бер генә дә уеннан аерыла белмиләр, ник кенә биргәннәрдер шул уенчыкларын! Атасын әйтер идем, без үскәндә кулыбыздан урак, көрәк, сәнәк төшми иде, хәзер балалар ул әйберләрнең нәрсә икәнен дә белмидер, юктыр, юктыр...

*Сөйләнә-сөйләнә, Мәликә карчык – Ансафның дәү әнисе, өйгә кереп китә. Ансаф үзе уйный, үзе вакыт-вакыт кычкырып куя.*

**Ансаф:** Урррааа, безнекеләр җиңә, беләсезме ничә балл булды?

*Ул арада Нәфисә керен юып бетерде дә, өйгә керешли әтисе – Шәриф карт янына килә.*

**Нәфисә:** Әти, ичмасам син әйтеп кара әле шул балага, атасыннан башка бер кешене тыңламый бит, шушы планшетны алып биргәннән бирле, нишләтергә дә белгән юк бу баланы! Син әйтсәң, ирләр сүзе – ирләр сүзе булыр иде әле.

*Нәфисә, сөйләнә – сөйләнә, өйгә кереп китте. Бабасы Ансаф янына килеп утырды.*

**Шәриф:** Ну малайка, беләсеңме, олылар әйткәнне тыңламаган өчен безне нишләтәләр иде элеккеге заманда – без кечкенә чакта?

**Ансаф:** Соң, бабай, син кечкенә идеңмени, әйт әле, ни эшләтәләр иде соң?

*Шәриф карт кет-кет килеп көлеп алды да, оныгын күтәреп алдына утыртты, арт ягыннан кулы белән чәбәкләп сөеп алды.*

**Шәриф:** Әй улым, улым, сезгә бик әйбәт замана килде хәзер, кадерен генә белегез инде.

**Ансаф:** Бабай, бабай, ә синең бабаң син сүз тыңламасаң ни эшләтә иде соң?

**Шәриф:**Минеме? Минем бабай бәк коры кеше иде ул, сезне генә хәзер иркәләп бетерделәр. Ә сүз тыңламаган өчен почмакка бастыра иде.

**Ансаф:** И-и-и, шул гынамы, мин дә баса алам ул почмакка. Тагын ни эшләтә иде, бабай, әйт әле.

**Шәриф:**Тал чыбыгы ашата иде *(үзе көлә.)*

**Ансаф:**Тал чыбыгы?!? Ха-а-а!!! Тәмлеме соң ул...? Тал чыбыгы! *(башын кашып тора.)* Юу-у-у-к, ашамыйм!!! Лучше мин әбинең боткасын кереп ашыйм, бабай, яме. Ә тагы, тагы… Бабай, тагы ни эшләтә иде сине бабаң?

*Ансафның бабасы алдына утыргач, йокысы килеп китте, авызы ачылып-ачылып китә.*

**Шәриф:** Тагымы, минем бабам, мин сүз тыңламасам, ”Кояш чыраен күрсәтмим, урамга адым да атламыйсың, валлахи билләһи” дия торган иде.

**Ансаф:** Кояш чырае? Ә нигә кирәк аның чырае, әнә бит ул кояш, көннәр буе *(авызы ачыла, йокысы бар)* безнең белән урамда, но безнең янга төшми никтер, курка, ахрысы, миннән – күктә генә утыра һаман, әллә безнең белән уйнарга әнкәсе кушмый микән. Әгәр төшсә, әйеме, бабай, мин аңа үземнең планшетны бер сәгатькә биреп торыр идем. Әгәр минем белән дуслашса, ике сәгатькә дә биреп торыр идем әле... Әллә бабай, теге син сөйләдең бит әле миңа Габдулла Тукайның “Су анасы”, “Шүрәле” әкиятләрен, бәлки кояш шулардан куркып төшми торгандыр безнең белән уйнарга, ә, бабай*?(авызы ачыла)*

*Шәриф карт көлеп куйды, башын чайкап алды.*

**Шәриф:** Улым, ә ник кояш куркырга тиеш әле алардан, Шүрәле белән Су анасыннан!

**Ансаф:** Соң, бабай, үзең сөйләдең бит, су анасының тарагын минем күк кечкенә малай урлаган дип, Тукай бабай шигырендә, оныттыңмени!!! Тик мин кояшны урламам, ә менә Шүрәле белән Су анасына *(авызы ачыла)* ышаныч юк. Алар урларга да мөмкин...

**Шәриф:** Ник алай дисең, улым, ник кирәк булсын икән Су анасы белән Шүрәлегә безнең кояш, ә?

**Ансаф:** И-и-и, бабай, шуны белмисеңме... Кояш безнең белән көн буе – без су кергәндә, качышлы уйнаганда да, җиләккә барганда да, ә Шүрәле, Су анасы безнең янга килеп тә карамый, шуны да белмисең *(йокысы килә - авыз ачыла.)*

**Шәриф:** Э-э-э, менә бит, имәндә икән бит чикләвек...

**Ансаф:** Бабай *(йокы аралаш),* ә, бабай, кояш булмаса ни була?

**Шәриф:** Абау, абау, әстәгафирулла, әстәгафирулла, улым, кап-караңгы, бушлык була, улым.

**Ансаф:** Кирәкми караңгы, яратмыйм, урлатмыйм кояшны, үзем саклыйм. Әнә каракай белән бергә саклыйбыз аны... Мин бит бабай бик күп укыйм, күп беләм. Тукай бабайның барлык әкият геройларын диярлек беләм... Албасты, Дию, Шайтан, Җен, Убырлы кап-кара урманда яши. Ә Су анасы - елгада....*(Талгын музыка.)*

*Ансаф тирән йокыга тала... Төш күрә башлый...*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Кара урман аланы. Тирә-якта агачлар. Уртада өстәл урынына зур имән төбе. Түр башында бик мөһим кыяфәттә Албасты утыра, уң ягында Шайтан, Убырлы утыралар. Сул ягында Җен, Шүрәле (барысының да алларында планшетлар, Шүрәледә генә юк, анда кәрәзле телефон) Шомлы,талгынмузыка...*

**Албасты:** *(Барысына да каш астыннан сөзеп карый. Тынлык. Шомлы.)* Компик, планшетларыгызны яки телефоннарыгызны көйләп куегыз. Бүген теләсә кайсы вакытта "үзе" *(өскә күрсәтә)* сезгә турыдан-туры чыгарга мөмкин. Аны карагыз, уен уйнап утырды юк!!! Тотсам, үпкәләштән түгел. Сез беләсезме, ни өчен мин сезне бүгенге чираттан тыш җыелышка җыйдым?

**Барысы да:** Юк, юк, белмибез, белмибез!!!

**Шайтан:** Безнең юлбашчыбыз – сез! Сез генә, Албасты Бастыевич, барысын да беләсез! Сез - галим!

**Убырлы:** Сез - даһи! Уңган! Булган!!!

*Албасты карашын Җен ягына күчерә...*

**Җен:** Сез - безнең арада иң - иң абруйлы җитәкче ! Сез ... Сез ...

**Албасты:** Ярар, ярар, Җен, булды, булды ... Син үзең дә "Әшәкелек һәм явызлык" фәннәрен укыган чакта, мәрхүм остазыбыз Пәри әфәнденең уң кулы идең, гел бишлегә генә укыдың ... *(Пауза. Залга карап, янындагылар ишетмәсен дип, авызына кулларын кушырып куеп әйтә).* Миңа да шактый булыштың, ату утырып кала идем... Бу кәнәфи миңа тәтеми иде, гупчим да!!! Менә боларның берсе менеп утыра иде анда...

**Албасты:** (*Шүрәлегә текәлә, үтәли тишеп карый)* Я, син ни әйтерсең?!

**Шүрәле:** *(куркып кына)* Барысын да әйттеләр... Миңа сүз дә калмады... Ни әйтим икән инде Сезгә...

**Албасты:** Синең шул булыр инде... *(үртәп сөйли)* Тә-ә-әк! Тыңлыйм, сөйләгез! *(барысы да, бер-берсен бүлдереп, сөйли башлыйлар)* Берәмләп, конкретно, кайда, кайчан, ничә! Кайчан эшләргә өйрәнәсез сез, ә?! У-у-у-у-у-у-ф-ф-ф-ф...

**Шайтан:** Албасты әфәнде, узган җыелыштан соң бүгенге көнгә кадәр яшьләр белән бик актив эшләп алдым, аракы, пиво һәм башка спиртлы эчемлекләр белән адәм баласын агулау - минем профиль, беләсез... Конкрет әйтәм - үлүчеләр узган елгыдан 5 процентка артты!!! Кайбер авыл мәктәпләренә дә үтеп керә башладым, дөрес, авыррак бара! Чөнки күп авылларда балалар мәчеткә йөри, дога укырга өйрәнәләр!

**Албасты:** Молодец! Менә бу үрнәк сезгә! Убырлы, премия яз шайтанга, адәмнәрне юлдан яздыру өлкәсендәге уңышлары өчен! Сүз - сиңа, Убырлы, сөйлә!!!

**Убырлы:** Төп эшем - адәмнәрне динсез итү, денсез итү, хатын-кызларны аздыру! Чөнки дингә ышанган, дога укый белгән, намаздагы хатын-кызга, һай-й-й тешем үтми-и-и!!! *(усаллана)* Җитмәсә, хәзер мәчетләр бик күбәйде, эшне бик тоткарлый шулар!

**Албасты:** Зур эш эшлисең, бик хуп!!! Хатын-кыз динсез булса, денсез була, ә бу безгә - кара көчләр өчен файда, андый хатыннар белән идарә итү җайлы! Во-о-о!!! Балаларны мәчет юлыннан биздерергә кирәк, укытучылары да ак абыстайларга якын килмәсен! Дога, намазны онытсыннар олылары, яшь укытучылар бөтенләй диннең ни икәнен белмәсен! Күбрәк телевизор, компик, кәрәзле телефон, интернатмы әле??? *(моңа сиздерми барысы да көлә.)* Менә безнең ярдәмчеләр!!! Монда эш фронты зур әле, убырлы!!! Эшлә дә эшлә, премия сиңа юк! *(убырлының борын салына.)*

**Җен:** Мин, Албый абый, үзең беләсең, ирләрне исертәм, аздырам, юлдан яздырам! Әле менә Иблис белән киңәшеп, мөселманнарга апперкод удары ясадык, ягъни искәрмәстән эчкә сугу! Ничек дисезме, аңлатам: татар телен киметтек мәктәпләрдә, факультатив итеп калдыру өстендә эшлибез. Ярый, татар таркау икән, элеккечә, хәтерлисеңме, 1554 елда Явыз Иванга Казанны алырга булыштык?! Сатлык татар морзалары Сөембикә ханбикәне дә, башка бик күп татар зыялыларын тотып бирделәр урысларга! Ул сатлыкҗаннар - безнең юлдаш һәм булышчыларыбыз! Ярар,

тарихка бик кермим әле. Татар телен кысу башлангач та шул ук татар үзе булышты !*(көлә)* Маңкортлар җитәрлек икән бит!!! Менә шулай, Албый абый... *(башын ия.)*

**Албасты:** *(басып кул чаба, аңа башкалар да иярә)* Афәри-и-ин!!! Икеләтә премия сиңа! Гаять зур эш эшләгәнсең - урыстан соң икенче урын биләгән татарга гаять үтергечски бәргәнсез, маңкортларга да рәхмәт!!! Молодец!!! Татар барда, хәтәр бар, онытмагыз! Сер итеп әйтәм: бик батыр, чиста-пөхтә булган халык, элек-электән алар белән алышу авыр булды безнең ишеләргә! Диннәре бик көчле! Шуңа күрә, татарны татардан кыйнатырга кирәк! Тик ызгышып ятсыннар үзара!!! *(көлә)*

**Албасты:** *(Шүрәлегә яратмыйча карый)* Я, сине тыңлыйм, сөйлә! Адәмнәргә нинди этлек эшләдең?

**Шүрәле:** Мин ... Мин ... Теге вакытта Былтыр *(каушый, курка)* бармакларымны кыскач, курыктым бик нык... Ә Былтыр миңа бүтән тимәде, балаларга да зыян салмады... Мин, үз чиратымда, аларга тимәдем, бик авырдан яши алар болай да, ярлылар күп, толлар күп, авырулар күп, сырхауханәләрдә акчаң булса гына дәвалыйлар, үз даруларыңны алып килергә кирәк, уку да түләүле, эш хаклары бик аз, өйсез сукбайлар, эшсезләрнең чуты юк! Бер-берсеннән көнләшәләр, этлек эшлиләр! Инде мин дә аларга этлек эшләсәм... Юу-у-ук! Булмый!!! Эшләмим!

**Албасты:** Нәрсә-ә-ә?! Бунт?! Син Шүрәлеме, әллә адвокатмы?! Мин сине беләсеңме, ни эшләтәм... Моның өченме?! *(башын кашый, убырлы белән җен ике яктан колагына нидер пышылдыйлар. Пауза)* Әһә, уйлап таптым!!! Хәзер үк барып, Кояшны урлыйсың, ярдәмгә Су анасын ал! Кешеләр кояшны күп кулландылар, менә аннан башка яшәп карасыннар әле! Аннан соң бәлки һава, суга да чират җитәр... Сиңа бер көн, бер төн бирелә. Әгәр Кояш урынында калса, минем күзгә бүтән күренмә! Мөгезеңне сындырып, шул адәмчекләр янына җибәрәм, шуларга йомышчы малай булып тик йөрерсең, кара аны! Аннан соң балаларыңны тотып ашыйм, вәйт!!! Бар, тиз бул! *(Шүрәле сүлпән генә чыгып китә.)* Киңәшмә тәмам! Эшне башлыйк!

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Төн. Ай яктысы. Күл буе. Бака тавышлары, ара-тирә төнге су кошлары кушылып ала. Басмада Су анасы, алтын тарак белән чәчен тарап утыра. Аның янына Шүрәле килә.*

**Су анасы:** *(сискәнеп китә.)* Нәрсә Шурулла, тарагымны урларга килдеңме монда, беләм мин сине, синең ишеләрне, тикмәгә генә бу вакытта йокы калдырып йөрмисеңдер, әйдә бар, юлыңда бул, бу минем биләмәләрем! Синең кара урманыңа гомер барганым юк, бармыйм да! Җыен жулик шунда, ачуым килмәсә әйтмәс идем, бар, бар, әйдә, сыпыр моннан, участковыйны чакырганчы!

**Шүрәле:** Ашыкма, кызма әле, Сусылу, ник кирәк ди ул миңа синең алтын тарагың, тарак кайгысы түгел әле монда, ул тарак белән "янар" хәлем юк. Теге малай шул тарак урлап тотылгач, син аны төнлә барып кире алгач, мескен малай атна буе урамга чыкмаган икән, дип сөйләде убырлы! Шулай булгач, синең ул тарагың – "тамгалы"!!! Бер эш бар, Сусылу.

**Су анасы:** Нинди эш инде ул?

**Шүрәле:** Менә уйлап кара, кояш көне буе балалар белән уйный, аларны җылыта, уйната, аларга нурын сибә. Ә безгә Ай гына кала, синең белән миңа.

**Су анасы:** Әйе шул, ә нәрсә эшләп була соң?

**Шүрәле:** Кояшны урлыйбыз!!! Янар тау артыннан чыкканын көтеп торабыз да, шалт!!! Ай да, кояш та бездә була!!! Менә шуннан соң без дөнья тоткасы булабыз, барлык балалар да, олы адәмнәр дә безгә ялыныр!

**Су анасы:**Ничек урлыйбыз, кая куеп торабыз аны? Аннан соң синең ул кара урманыңдагы Дию пәрие, Албасты, Җен белән Шайтаннан бик нык куркам, бигрәк усал, явыз алар! Убырлы карчык белән ерак булса да кардәшлек бар, анысы миңа зыян салмас шәт, инша Аллах.

**Шүрәле:** *(көлә)* Курыкма, мин *(як-ягына каранып ала)* нәкъ менә шуларның боерыгын үтәп синең янга килдем дә инде. Урман җыенында Албасты әфәнде үзе алга сөрде бу фикерне – бер көн, бер төн вакыт бирде. Бөтенебезне бик нык сүгеп атты, миңа да эләкте.*(Елап ала.)* Ә менә Җенгә берни әйтми, ул, гомумән, галстук такмый, ФИЗОга да йөрми безнең күк! *(Сусылуның колагына әйтә*). Бергә укыганнар ди... Шул чакта Җен, бик нык булышкан ди Албастыга, контрольныйларын да эшләп биргән дип әйтеп әйтәләр, ди, Албастының! Үзең беләсең, баш дигән әйбер бик үк эшләп бетерми бит, юкарак аның башы! Менә шул үрмәкүч ятьмә үреп бирде, урман штабында план төзедек: Янар тау итәгендә синең белән качып утырабыз да, ятьмә атып, кояшны эләктереп тә алабыз, шуннан соң Көмеш күлгә батырып та куябыз. Бу – *(күккә карап тын кала бер мәлгә)* даһи план!

**Су анасы:** Аңладым, план әйбәт… Әйдә, утыр минем җилкәгә, су юлы белән барсак, таңга кадәр өлгерәбез!

*Таң атканчы, Шүрәле белән Су анасы Янар тауга килеп җитеп көтеп тордылар, чыгып килүче кояшны ятьмә белән эләктереп тә алдылар. Якындагы күлгә батырып, яшереп тә куйдылар.*

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Урман аланы. Төн караңгылыгы. (Зәңгәрсу-караңгы, сүрән ут яктылыгы сәхнәдә.) Урман аланында барлык җәнлек-җанвар, ерткычлар, әтәч, тавык җыелган, алар арасында көчеге Каракай белән Ансаф та бар. Ансаф "Туган тел" җырын башкара.*

**Ансаф:** Кем күрде, кояшыбыз кайда?

**Тавык:** Менә Әтәч кычкырмады, шуңа кояш чыкмады, кичтән әз генә әйткәләшеп алган идек, шуңа ачу итте. Кот-кот-кот!!!

**Әтәч:** Кояш чыкмагач, ничек кычкыры-ы-ыйм, тити ба-а-аш, тавышым чыкмый, вә-ә-әт!

*Кычкырышалар үзара, кем алган Кояшны!!! Бәхәсләшәләр. Аю бүрегә, бүре төлкегә, төлке куянга сылтады.*

**Аю:** У-у-у-у-у-у-у, у-у-у-у-у-у-у-у.., бүр-р-ре эше бу-у-у-у-у-у-у... Шул гына алга-а-ан у-у-у-у-у-у-у...!!!*(бүрегә җикеренә.)*

**Бүре:** Ыр-р-р-р, ыр-р-р... Алмады-ы-ым, юу-у-ук, ник алы-ы-ыйм? *(арлы-бирле йөренә, төлке каршына туктый)* Ә-ә-ә, көлтә койрык!!! Беләм ми-и-ин, синең эш!

Чокырчаның бөтен тавыгын ашап бетердең теге елны... Синең эш бу, бир-р-р тизрә-ә-әк, юкса-а-а...!!! *(төлке өстенә килә.)*

**Төлке:** *(көлә)* Ой-ой-ой, бүре абзый, ой-ой-ой!!! *(Ялагайлана, койрыгын болгап мактана, йөренә.)* Тавык, тавык инде ул, кояш түгел! Кояшны ашап булмыйдыр да әле ул! *(Аягы белән тибеп куя.)* Мин түгел!!! *(Шулвакыт, аның каршысыннан узып баручы куянны күреп ала, каршысына чыга.)* Тапты-ы-ым, менә ул Кояшны урлаучы!!! Качмакчы иде! Ә мин, тоттым!!! Ля-ля-ля, ля-ля-ля! *(бии.)*

*Куян, юаш булгач, берсенә дә сылтый алмый, арлы- бирле йөренеп килә.*

**Куян:** Я, ярый, эзләп карыйм, миндә булса бирермен – дип *(башын иеп, бик кайгырып)* китә башлый.

*Шунда куак артыннан карлыккан тавыш килә:"Туктагыз!!! Мине көтегез! Мин беләм, ишеттем, күрдем!"*

**Ансаф:** Сабыр итик, көтик.

*Көтәләр көтәләр – юк теге!*

**Аю:** *(улап җибәрә)* У-у-у,у-у-у,у-у-у....!!! Алдады-ы-ы, саескан булганды-ы-ыр-р-р!!! (*Ул арада, куак арасыннан бер түгәрәк йомгак килеп чыга да телгә килә.)*

**Керпе:** Син үзең саескан, мыскыл итә тагын, кечкенә булгач та, шундый каты йөгердем, шундый йөгердем – тыным калмады, валлаһи билләһи газим! Әп-пәс абый, мыскыл итсәң – йөгереп киттем бардым булыр яме, шуны бел!!! Тик мин китсәм, гомергә кояшны кем урлаганын белмәссез*! (Шунда йомгакның керпе булуы ачыклана.)*

**Ансаф:** Ярый, сөйлә, керпе дус.

**Керпе:** *(борынын тартып куйды да сөйләргә тотынды)* Кояшны Шүрәле белән Су анасы урлады, үзем күрдем барысын да, ишеттем. Кичке ауга чыккан идем, тычкан-мазар эләкмәсме дип, карыйм, болар сөйләшәләр. Ну, шуннан соң йөгер сезнең янга.

**Ансаф:** Керпе абзый, мөмкин булса, җентекләп сөйли алмассызмы?

**Керпе:** Алам, ник алмаска! Күрде-е-ем!!! "Янар тау артыннан чыккан вакытта ятьмә белән тотып алып, тау янындагы көмеш күлгә батырып, яшереп куябыз", – диделәр, вәйт! Ишеттем!!! *(кычкыра.)*

**Ансаф:** Рәхмәт, керпе абзый! Кояшны коткарырга киттек! Кем минем белән?

**Керпе:** Туктагыз!!! Әйтеп бетермәдем бит әле! *(Мөһим тәкәббер кыяфәт белән арлы-бирле йөри.)* Сезнең бер тәүлек вакытыгыз бар, аңарчы кояшны коткармасагыз, бүтән аны күрә алмассыз!!! Ашыгыгыз, мин үзем дә сезнең белән барыр идем, тик монда йөгереп килеп бик арыдым шул! Ярый, хәерле сәгатьтә, дуслар!

**Ансаф:** Кем минем белән бара?

*Барысы да "мин, мин" дип кычкыралар.*

**Ансаф:** Безнең вакыт бик аз, тәүлек эчендә кояшны коткару өчен, бик тиз барырга кирәк! Юлда Шүрәленең дуслары - Убырлы карчык, Албасты, Җен һәм Шайтан очрарга мөмкин, аларның бу эшне бергә сөйләшеп эшләгән булулары да бар. Минем белән Аю, Бүре,Төлке, Куян, Тиен бара. Урман кошлары – барыгыз да разведкага! Каракай, ә син минем урынга монда каласың! Мин кайтканчы, тәртип булсын, яме, дустым.

**Каракай:** Һа-а-а-у-у-у, бик барасым килсә дә, хуҗам әйткәч – берсүзсез буйсынам мин, һа-а-у-у!!!

**Әтәч:** Ә мин! Кояшны чыгаруга ук, кем кычкырып җиһанны уятыр?!

**Тавык:** Син барсаң – мин калмыйм! Аннан соң миндә ашагач йоклата торган тары боткасы бар, бик тәмле ул...

*Мутланып, әтәч тирәсендә сикергәләп биеп ала да, аның каршына килеп, башын ия.*

**Әтәч:** Кот, кот, кот, кот...*(арлы-бирле йөренә башлый, текә кыяфәт чыгара)* Синең шул булыр инде, анасы ...Хм... Ярар, барырсың!

*Озакламый Ансаф командасы белән юлга чыга, аның белән Аю, Бүре, Төлке, Куян, Тиен, Әтәч, Тавык китәләр. Менә алда Убырлы карчык алачыгы күренә.*

**Аю:** Мин карчыкны сөйләштереп торам, сез барыгыз.

*Ансаф, дуслары белән юлын дәвам итә. Күп тә үтми, сайрар кошлар алда Албасты булуын хәбәр итәләр.*

**Төлке:** *(кыланып)* Чират минеке, мин албасты белән үзем сөйләшәм, сез ашыгыгыз.

*Юлны дәвам итәләр. Инде урманны чыгарга да күп калмады. Ансаф белән аның дусларына кошлар яңа хәбәр ирештерделәр: алда, юлның бер ягында Җен, ә икенче ягында Шайтан сакта торалар икән. Бу юлы Куян белән Тиен алга сикереп чыктылар.*

**Куян:** Зыян юк, болары безнеке.

**Тиен:** Аларны алдавыч юлдан икесен ике якка алып китәрбез.

БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Янар тау итәге. Төн. Сүрән караңгылык. Таудан ерак түгел көмеш күл ялтырап күренеп тора. Ә күл янында Шүрәле белән Су анасы сөйләшәләр.*

**Су анасы:** Карале, Шурулла, минем тамагым бик ачты, иртән әби биргән ботканы да киреләнеп ашамаган идем! Эх, хәзер шул бер миски ботка булса, уртасына май салып ашап куяр идем...

**Шүрәле:** Хы, үзем дә әйтми генә тора идем. Бабам әйтте, аш ашамый чыгып китмә, ирләргә аш кирәк, диде! Тыңламадым, ашамадым... Менә хәзер ашар идем дә – юу-у-ук!

*Ансаф дуслары белән боларны тыңлап тора. Шүрәле белән Су анасын үзләре генә җиңә алмыйлар алар, көчләр тигез түгел, монда хәйлә кирәк. Ансаф, тавыкның колагына нидер пышылдап аңлатты, өйрәтте, тавык башын ия-ия тыңлады.*

**Тавык:***(Ансафны тыңлап бетергәннән соң)* Булыр, булыр, кот-кот-кот...

*Үзе Шүрәле һәм Су анасы янына китте, үзе белән бер миски тары боткасын да алырга онытмады. Су анасы белән Шурулла, тавыкны күргәч,бик шатландылар.*

**Шүрәле:** Менә бит, бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына, әт-тәт-тәт, әт-тәт-тәт.

*Шүрәле һәм Су анасы бии үк башлыйлар.*

**Шүрәле:** Кил, кил, тавык, курыкма, мин синең шулпаңны би-и-ик яратам, м-м-м-м-м...

**Су анасы:** Әйе. Мин дә... би-и-ик яратам... *(Су анасы телен ялмап куйды.)*

**Тавык:** *(бер дә исе китмәгән кыяфәттә, ә үзе дер калтырый, мескен.)* Ә-ә-ә, Шурулла абзый, Сусылу апай, сез икәнсез әле, кемнәрне күрәм мин, күптән күрешкән юк иде, онытылып бетә язгансыз, валлахи билләхи! Зыян юк, минем аңлавымча, сезнең ашыйсыгыз килә бугай.

**Шүрәле:** Әйе!

**Су анасы:**Шулай.

*Икесе дә урыннарында сикереп куялар.*

**Шүрәле:**Тиздән синең шулпаңны ашарбыз.

**Су анасы:** Ашарбыз, ашарбыз. *(Шатланып кулларын уалар.)*

**Тавык:** Казанда шулпага су кайнаганчы, әгәр каршы килмәсәгез, мин сезне тары боткасы белән сыйлыйм.

**Шүрәле:** Кая, бир тизрәк, ашыйк.

*Сусылу белән Шурулла тавык биргән тәмле тары боткасын бик тәмләп ашый башлыйлар. Ботка шулкадәр тәмле, туклыклы була ки, Сусылуның да, Шурулланың да йокылары килеп, авызлары ачыла башлый. Тиздән алар тирән йокыга талалар. Ул арада күл янына, бу хәлләрне читтән күзәтеп торган Ансаф белән Әтәч килеп җитәләр, Тавыкка рәхмәт әйтәләр.*

**Ансаф:** Әйдәгез, болар уянганчы, тиз генә кояшны коткарыйк, иреккә чыгарыйк!

*Шуннан өчәүләп ятьмәне тартып, дуслар кояшны күлдән тартып та чыгаралар. Бөтен дөнья яктырып, матурланып китә, тирә-якка сап-сары алтын нурлар сибелә. Кояш, тоткынлыктан котылганнан соң, әз генә ял итә дә, җирдән әкрен генә үз тәхетенә – күккә юл ала. Ул арада, бөтен урманнарны, болын-кырларны, тауларны, басу, елга буйларын яңгыратып, Әтәч кычкырып җибәрә: - Кикри-кү-ү-үк!!! Шушы мизгелдә Ансаф уянып та китә! Йөгереп барып тәрәзәдән тышка карый, кояш урынында – бик нык кыздыра иде. Аның тиз генә урамга чыгып, уйныйсы килә. Тик ул бик тә тамагы ачканны исенә төшерә, өстәл янына килеп, әнисе әзерләп куйган майлы ботканы ашый башлый. Бабасы аңа еш кына "Ашау эшне дә, уенны да калдырмый", – дип әйтә иде... Хәзер инде Ансаф, бу сүзләрне, алай гына да түгел, олы кешеләр әйткән, укытучылар әйткән сүзләрне төгәл үтәргә, тыңларга, каршы әйтмәскә икәнен тәгаен белә. Моннан соң вакытында ашап, вакытында уеннан кайтып, вакытында йокларга ятарга кирәклеген дә белә... Ә сез, балалар, ашадыгызмы соң әле?*

*Тәмам*

***Чирикова Эльвира Илһам кызы***
***Ногманова Фирдәүсә Минап кызы***
***Гәлиева Нурания Раил кызы***
***Маштакова Александра Михайловна***

**"Сугыш авазы"**

**Катнашучылар:** *Алып баручы, әби, әни, кыз, малайлар-солдатлар, балалар.*

**Максат:** борынгы әби-бабаларыбызның милли киемнәре, гореф-гадәтләре, татар халкының танылган язучылары, композиторлары белән таныштыру, алар белән горурлану; бәйләнешле фикерләү сәләтен үстерү; балаларда халкыбызның тарихына карата кызыксыну уяту.

*Зал җәй күренеше белән бизәлгән, кояш елмая, чәчәкләр үсә, авыл күренеп тора.*

*Залга йөгереп бала керә, күңеле шат, кулында туп. Шатланып шигырь сөйли:*

*Иркен һәм матур,*
*Туган илебез.*
*Гөрләп үсәбез,*
*Туган илдә без.*

*Ямьле илдә без,*
*Иң матур гөлләр,*
*Гөрләп үсәбез,*
*Без бәхетлеләр!*

*Шау-шу килеп, көлешеп, балалар керәләр.*

**Кыз:**

Малайлар, кызлар, әйдәгез, уйныйбыз! *(Кызлар чүгәләп утыралар.)*
*Без-без-без идек,*
*Без унике кыз идек.*
*Келәткә кердек - май ашадык,*
*Базга төштек - май каптык,*
*Ам-том авыз йом!*

*Берсе көлеп җибәрә, аңа җәза бирелә (уен шулай дәвам итә).*

*Балалар туп, машина, пирамидка белән уйныйлар, скакалкада сикерәләр. Кинәт сирена тавышы ишетелә. Радиодан сугыш башланган хәбәрне әйтәләр. Балалар, куркып, төрле якка йөгерәләр.*

*Сәхнәгә улы белән әни булып киенгән бала керә. Ана, елап, баласын сугышка озата. Улы чыгып китә.*

**Бала:**

*Озатып вокзаллар каршында,*
*Маңгайдан үптеләр аналар.*
*Тузанлы юллардан үттеләр,*
*Дөньяны күрмәгән балалар.*
*Балалар керделәр утларга,*
*Балалар сүз бирде тупларга.*
*Күпләре төренеп шинельгә,*
*Калдылар еракта йокларга.*

*Ана улын сугышка озата, маңгаеннан үбә, кульъяулыгын селкеп кала.*

*Фронт күренеше: учак янында солдатлар утыралар, берсе хат яза, берсе укый, берсе гармунда уйный. "Сөекле, улым" – хат уку.*

*"Сөекле, улым!*

*Сагынып сиңа хатлар язам. Сеңелең һәм күрше-күлән сиңа кайнар сәламнәрен җибәреп калалар. Колхозда эш бик күп. Иген урыр вакыт җитте, бакчада да эш җитәрлек. Бик авыр, улым. Синең өчен бик борчылабыз. Сау-сәламәт бул, тизрәк дошманны тар-мар итеп, туган авылыңа әйләнеп кайт. Без сине сагынып көтәбез.*

*Сәлам белән кадерле әниең.*

*19 август 1942 ел."*

*Тыныч тормыш вакыты, мәңгелек ут яна, бала һәйкәл янында баскан, кулында чәчәкләр.*

**Бала:**

*Тыныч йокла, солдат, синең хатың*
*Килеп җитте безнең буынга.*
*Ул өйрәтте безне туган җиргә,*

*Туган илгә тугры булырга.*
*Ирек яулаганда безнең өчен,*
*Һәлак булдың сугыш кырында,*
*Баш иябез синең алда бүген,*
*Пуля төшкән хатың янында.*

*Музыка тавышы, 9нчы май бәйрәме.*
*Әби керә, моңсу, яшен сөртә.*

**Малай:**
*Яз сулышы белән бергә,*
*Бәйрәм йөри авыл буйлап.*
*Күрше Сәрби әби генә,*
*Яшен сөртә авыр сулап.*
*Мин чәчәкләр җыям аңа,*
*Бүлмәсенә ямьнәр тулсын.*
*Җиңү белән бергә илгә,*
*Улы кайткан кебек булсын.* (*Бала әбигә чәчәкләр бирә.)*

**Әби:**
Рәхмәт, балам, улым кайткан кебек булды *(баланы кочаклый)*.

*Шау-гөр килеп, төрле милләт киемнәреннән балалар керәләр.*

**Бала:**
Язлар белән Бөек җиңү килде,
Дөнья матур, дөнья түгәрәк.
73 еллык җиңү көнен бүген,
Каршылыйбыз, бар халык белән бергәләп!

*Балалар башларын ияләр.*
*Тәмам*

***Шәйхулова Гөлназ Фаяз кызы***
*Татарстан Республикасы*

**“Туфан васыятьләрен үтәрбез”**

**Катнашалар:**
*Укучы - 8 сыйныф укучысы, пөхтә итеп киенгән, чәче ике толымга тасмалап үрелгән*
*Туфан Миңнуллин - түбәтәйдән, һәрвакыттагыча кыю, көр тавышлы*
*Акбай*
*Тәмлетамак*

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

*Татар теле кабинеты. Диварда Туфан Миңнуллин портреты. Сүрән генә ут яна. Укучы татар теле, әдәбияты дәреслеген күкрәгенә кысып тотып, Туфан портреты янына килә.*

**Укучы:**Исәнмесез, Туфан абый! Мин күңелемдәге уйларымны, кичерешләремне Сезгә сөйләргә булдым әле. Сезнең юклыкны белсәк тә, йөрәккә боерып булмый, күңел Сезнең белән сөйләшә, ярдәм-киңәшләр көтә.

Туфан абый! Сез минем генә түгел, бик күпләрнең хәтер сандыгында Туры Туфан булып сакланасыз. Гомерегезнең соңгы көненә кадәр тел, милләт дип янган кеше дә Сез. Кызганыч, бүгенге көндә телебез һәм милләтебез аянычлы хәлдә. Мәктәпнең туган тел бишегендә тибрәткән сыйныф бүлмәләре безне моңсуланып каршы ала. Бу бүлмәләргә бик сирәк керәбез инде без. Чөнки дәресләр кыскартылды.

*Туфан ага сыйныф ишегеннән килеп керә, йөзендә борчу.*

**Туфан ага:** Мин барысын да күреп, борчылып ятам, кадерле укучым. Күр әле, күпме тел мохитен сыйдырган диварлардан бүген салкынлык бөркелә. Таш булып таш та бу күренешләрдән ыңгырашып, сыкрап куйган төсле тоела. Ыңгырашыр да шул... Күпме үз эшенең остасы булган телчеләр монда дәрес биргән, күпме балалар телебезнең матурлыгын, аһәңлеген шушында тойган, туган телнең илаһи төшенчәләрен дә, гүзәл әдәби әсәрләрен дә шушында ишеткән. Һәм менә шушы эшләр берәм-берәм җыелып, тупланып, баеп, баетылып бер киштәгә рәт-рәт итеп тезелеп куйгач, бер талпынуда төртеп аударылган.

**Укучы:** Туфан ага, Сез бик борчылмагыз әле, татарлар көчле һәм горур алар. Көн дә телебезнең кимсетелүен искәртеп торсалар да, бөркетләр сыман, көчле һава агымын күкрәкләре белән ярып, һаман алга баралар. Мәктәп – телебезне саклап торган бердәнбер учак икәнлеген аңлап, кулларын пешерә-пешерә, шул учакка утын өстәп торалар. Менә әле күптән түгел генә без укытучыбыз ярдәме белән Сезнең “Авыл эте Акбай” әсәрен сәхнәләштердек.

*Кабинеттагы ут яктырып китә. “Авыл эте Акбай” әсәреннән өзек сәхнәләштерелә.*

**Туфан ага:** *(йөзе яктырып китә, көр күңел белән*) Рәхмәт, укучылар. Сез мине шатландырдыгыз. Саубуллашыр алдыннан, сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә. Гасырлар буенча чарланып, иң камил телләр дәрәҗәсенә күтәрелгән телебезне, уч төбендә утлы чәчәкләр итеп үстереп, күк йөзенә якты йолдыз итеп чәчәрлек кыю, горур, милләтпәрвар булып үсегез.

**Укучы:**

Тырышырбыз, Туфан ага, Сезнең васыятьләрне үтәргә!
*Туган тел – иң әйбәт шигырь,*
*Туган тел – иң әйбәт җыр.*
*Туган тел – иң әйбәт китап,*
*Туган тел – иң якын тел. (Р. Миңнуллин)*

*Пәрдә ябыла.*

***Вәлиуллина Зөһрә Энгел кызы***
*Татарстан Республикасы*

## “Карурман хикмәтләре”

**Максат:** Балаларда әйләнә-тирә табигатькә, урманга, дару үләннәренә карата сакчыллык, миһербанлылык сыйфатлары, экологик культура тәрбияләү; табигатьтәге үзара мөнәсәбәтләрне күрә белү сәләтен, диалогик сөйләмне үстерү.

**Катнашалар:** *Урман хуҗасы, Ирек, Ләйлә, Убырлы оныгы, Аю малае, Бүре малае, Куян кызы Наян; Ромашка, Мәтрүшкә, Үги ана яфрагы, Бака яфрагы, Кычыткан, Тузганак.*

*Пәрдә ачыла*

*Сәхнә урман аланы итеп бизәлгән. Агачлар арасында чәчәкләр, җиләкләр үсә. Кошлар сайраган тавышлар. Карурман хуҗасы керә.*

**Карурман хуҗасы:**

Менә мин урманымны карап, барлап йөри идем әле. Бөтенесе дә исән-саулар микән, ә урманымда тынычлык микән? Ах! Кошлар сайрый, ничек матур тавышлары! Менә минем агачларым, менә минем чәчәкләрем! (*тавышлар ишетелә*) Әй, анда ниндидер тавышлар ишетелә түгелме? Нишләп йөриләр икән? Агач сындырып, кош оялары туздырып йөрүчеләр түгелме икән? Качып карап торыйм әле. (*Агач артына кача.*)

*Музыка астында Ирек һәм Ләйлә керәләр, кулларында тырыс.*

**Ләйлә:** Менә без дә килеп җиттек!

**Ирек:** Нинди матурлык! Кошлар сайрый!

**Ләйлә:** Җиләкләр пешкән!

**Ирек:** Ләйлә, әйдә, җиләк, дару үләннәре җыйыйк!

**Ләйлә:**Әйдә!

*Балалар музыка астында җиләк җыялар.*

**Ләйлә:** Ирек, минем кәрзин тулды!

**Ирек:** Минеке дә тулды!

**Ләйлә:** Әйдә, бер биеп алабыз!

*Балалар тырысларын куялар. Татар халые көенә бииләр.*

**Ләйлә:** Ирек, кайткач, җиләктән как, кайнатма ясыйк!

**Ирек:** Дару үләннәре дә киптерик. Кыш көне кирәк булыр!

*Балалар чыгып китәләр. Карурман хуҗасы чыга. Ул сөйләгәндә, Убырлы оныгы, кача-поса, артта йөри.*

**Карурман хуҗасы:** Курыккан идем аны. Бик тәртипле, акыллы балалар булдылар әле болар. Матур гына килеп, матур гына кайтып киттеләр. Әле бит җиләкнең, дару үләннәренең файдасы турында да беләләр.

**Убырлы оныгы:** Нәрсә, адәм балаларына сокланып йөрисеңме? Ә үзеңнең урманыңда нәрсә барын белмисеңдер әле. Әнә, Аю малаеның эче авырта, Куян кызының башы чатный, ә Бүре баласына суык тигән!

**Карурман хуҗасы:** Шулаймыни? Син бер дә кайгырма, безнең урманда дару үләннәре, файдалы чәчәкләр бик күп. Шулар белән без аларны дәваларбыз. Ромашка, бака яфрагы, мәтрүшкә, тузганак, үги ана яфрагы, кычыткан!

*Бер-бер артлы дару үләннәре чыга, чәчәкләр биюе бииләр. Карурман хуҗасы белән Убырлы оныгы читтән карап торалар.*

**Карурман хуҗасы:** Әйдәгез, дусларым, ярдәмгә ашыгыйк!

*Карурман хуҗасы артыннан тизелеп күңелле музыка астында бөтенесе дә чыгып китә. Салмак музыка яңгырый. Авыру җәнлекләр керәләр. Бүре малае, йөткерә-йөткерә, агач төбенә утыра. Эчен тотып, Аю малае керә, Куян кызы Наян башын тотып керә*

*һәм икенче агач төбенә утыра. Карурман хуҗасы, Убырлы оныгы, дарү үләннәре күңелле музыка астында керәләр.*

**Карурман хуҗасы:** Нәрсә, дусларым, чирләп киттегезмени?

**Убырлы оныгы:** Әйе, чирләделәр! Берсе дә әниләренең әйткән сүзләрен тыңламады. Куян кызының башына эссе сукты, чөнки башына панама кимәде. Ә Бүре баласы чишмәдән суык су эчте – ангинасы шеште! Ә Аю баласы - бер тәпән бал ашап бетерде. Шуңа эче авырта!

**Карурман хуҗасы:**Әйе, әниләрнең сүзләрен тыңларга кирәк. Шулай итсәгез, беркайчан да чирләмәссез. Ә хәзер без сезне дәваларбыз. Кая әле, Бүрекәй, башта сине дәвалыйк! Суык тигәннән Ромашка булыша! (*Ишарә белән Ромашканы чакыра. Ромашка музыка астында чыга.*)

**Ромашка:**

*Дәвалыймын, чирләсәгез,*
*Терелтермен һәммәсен.*
*Табам тик ярдәмдә генә*
*Яшәвемнең мәгънәсен.*

*Карурман хуҗасы Ромашка янына савыт белән килә. Ромашка савытка бер яфрагын сала. Тылсымлы музыка. Шул даруны Карурман хуҗасы Бүрегә эчертә. Бүре терелә, йөгереп чыгып китә.*

**Карурман хуҗасы:**

Менә бит Бүре малае терелде. Кая әле Куян кызы Наян, сине мәтрүшкә белән дәваларбыз. (*Ишарә белән Мәтрүшкәне чакыра. Мәтрүшкә музыка астында чыга.)*

**Мәтрүшкә:**

*Дәвалыймын ютәлләрне,*
*Татлы хуш исем белән.*
*Авырудан арынуның*
*Мең төрле серен беләм.*

*Карурман хуҗасы Мәтрүшкә янына савыт белән килә. Мәтрүшкә савытка бер яфрагын сала. Тылсымлы музыка. Шул даруны Карурман хуҗасы Наянга эчертә, Наян терелә.*

**Наян:**

Рәхмәт сезгә, терелттегез,
Башым инде авыртмый.
Йөгерәм әни янына,
Панаманы онытмыйм! *(йөгереп чыгып китә)*

**Карурман хуҗасы:**

Менә бит Куян кызы да терелде. Ә хәзер без Аю малаен да терелтербез. Без аны Үги ана яфрагы белән дәваларбыз. (*Ишарә белән Үги ана яфрагын чакыра. Үги ана яфрагы музыка астында чыга.)*

**Үги ана яфрагы:**

*Чирләсәгез, авырсагыз,*
*Син яхшы дару диләр.*
*Кешеләр өчен сихәтнең,*

*Мең төрле серен беләм.*

*Карурман хуҗасы Үги ана яфрагы янына савыт белән килә. Үги ана яфрагы савытка бер яфрагын сала. Тылсымлы музыка. Шул даруны Карурман хуҗасы Аю малаена эчертә.*

**Аю малае:**

(*сикереп тора, сөенә.*) Мин сәламәт! (*йөгереп кереп китә.*)

*Карурман хуҗасы савытын куярга агач янына килә. Иелгәндә, биле авырта башлый.*

**Карурман хуҗасы:**

Ах-ух сызлый, авырта! (*Кычыткан йөгереп килә.*)

**Кычыткан:**

Нәрсә булды, Карурман хуҗасы?

**Карурман хуҗасы:**

Буыннарым авырта, ах, ух!

**Кычыткан:**

*Мин – кычыткан, авыртса кул-буыннар,*
*Яфрагымда, тамырымда, яшәү көче, шифа бар!*

*Кычыткан тылсымлы көйгә Карурман хуҗасы тирәли бии, аны "дәвалый".*

**Карурман хуҗасы:**

Рәхмәт, сиңа, Кычыткан! Бөтен авыртуларым юк булды!

**Убырлы оныгы:**

(*агач артыннан чыга.*) Синең авыртуларың бетте, сиңа рәхәт. Ә менә минем аягымның җәрәхәте һаман төзәлми. Кичә аш пешергәндә, кайнар суга пешкән идем, беләгем һаман авырта (*елый.)*

*Тузганак белән Бака яфрагы музыка астында Убырлы янына чыгалар.*

**Тузганак:**

*Борчылма син, Убырлы,*
*Мин – Тузганак, шифалы мин,*
*Янган, пешкән җирләргә.*
*Тамырымның төнәтмәсе*
*Сиңа килер ярдәмгә.*

**Бака яфрагы:**

Җәрәхәтеңне дә дәваларбыз, Убырлы оныгы.
*Исемем – Бака яфрагы,*
*Мине бик хөрмәтлиләр.*
*Киселсә дә, канаса да,*
*Иң әйбәт дару, диләр.*

*Тузганак белән Бака яфрагы Убырлы тирәли әйләнәләр, "дәвалыйлар".*

**Убырлы оныгы:** Рәхмәт сезгә, дару үләннәре, бөтен авыруларым юк булды!

**Карурман хуҗасы:** Менә бит безнең урман нинди бай: анда матурлык та күп – карагыз, нинди матур агачлар, нинди матур чәчәкләр. Шул байлыкны саклый, күрә белергә кирәк! Безнең сәламәтлек шул байлыктан тора. (*Соңгы сүзләрдә бөтен катнашкан персонажлар чыга*.)

**Барысы да:**
Сәламәт булыйк, дуслар!

*Җыр* (*С.Наминның “Мы желаем счастья вам” җыры мотивына*)

*Кояш җылы нурларын сибә,*
*Бар дөнья яктыга күмелә.*
*Табигать тә уяна,*
*Сөенә һәр бала.*
*Бәхетле, сәламәт булыйм, дисәң,*
*Йөз яшькә кадәр яшим дисәң,*
*Табигатьтән тап шифа,*
*Куллан һәм дәвалан!*
*Кушымта:*
*Һәрвакыт сәламәт бул,*
*Авырма, дустым, беркайчан.*
*Урманнарда син йөр,*
*Саф һава сула һәрчак.*
*Табигать баласы – без!*
*Саклыйкчы аны бергәләп,*
*Шунда килер бәхет*
*Һәм саулык килер безгә.*

*Пәрдә*

***Садыйкова Миләүшә Сәлих кызы***
*Татарстан Республикасы*

## “Бездә бүген Нардуган”

**Максат:** Татар халкының үткәненә, гореф-гадәтләренә, бәйрәмнәренә, халык авыз иҗатына кызыксынучанлык уяту.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

*Татар авыл урамы күренеше.*
*Ир балалар кич утыру өчен йорт эзлиләр.*

**1нче бала:** Нардуган кичәсен үткәрер өчен өй кирәк! Кемнең өенә барабыз?

**2нче бала:** Бану әбигәме?

**3нче бала:** Бәлки Мария түтәйгәдер!

**4нче бала:** Ә Зәйтүнә әбигә барсак?

**5нче бала:** Әй, Бану әбинең аяклары бик начар йөри, ул өйдән еракка китә алмас. Иртә кайтыр!

**1нче бала:** Ә Мария түтәй усалрак. Җаен таба алмабыз аның белән!

**2нче бала:** Әйдәгез, Зәйтүнә әбигә барыйк. Аның өе иркен дә, зур да!

**3нче бала:** Ничә кеше булырбыз икән?

**4нче бала:** Безнең монда бөтенебез дә юк әле!

**5нче бала:** Калганнар соңрак килерләр!

*Зәйтүнә әби капкасын кагалар.*

**Әби:** Кем анда? Кем бар?

**Балалар:** Зәйтүнә әби... без бу! Нардуган кичәсен уздырыр өчен бер кичкә генә өеңне бирә алмассыңмы?

**Әби:** Ә-ә... кич утырырга гына түгелдер әле! Сезгә минем өем таңга кадәр кирәктер әле?

**Балалар:** Кирәк шул!.. Өеңә зыян салмабыз, яхшы, тәртипле бәйрәм итәрбез!

**Әби:** Хе!.. Сез бит үзегез генә булмассыз? Күрше авылдан чакырган кунакларыгыз да булыр, тукылдатып биерсез, идәннәремне бозарсыз! Юк! Юк! Мин риза түгел...

**Балалар:** Ярар инде... әби, без тәртипле булырбыз... Сөйләштекме?

**Әби:** Эй, ... ярар, ярар, балакайларым, рәхәтләнеп бәйрәм итегез!

*Әби әйберләрен төенчеккә җыеп, матур киенеп, ахирәтенә китә.*

**Балалар:** Рәхмәт, Зәйтүнә әби, син кайтышка өең тәртиптә булыр!

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

*Авыл урамы буйлап, ят киемнәргә киенеп, үзләрен танытмый гына катнашучылар өйдән-өйгә йөриләр, такмаклар әйтәләр, йорт хуҗаларына Яңа елда муллык, иминлек, бәхет телиләр.*

*1. Нардуган, Нардуган килә*
*Теләк теләп матур көйгә.*
*2. Нардуган, Нардуган,*
*Бәйрәм мөбәрәк булсын!*
*3. Нардуган бәйрәме котлы булсын,*
*Эче тулы нур булсын!*
*4. Торыгыз, тор, хуҗалар!*
*Нардуган җитте, беләсезме?*
*5. Нардуганым нар булсын,*
*Эче тулы нур булсын;*
*Нардуган көен кем көйләсә,*
*Ул дәүләтле бай булсын.*

*“Нардуган” җырын җырлап катнашучылар әбинең өй эченә узалар* (*өй эче чиста матур итеп җыелган)*.

*Нардуган, Нардуган,*
*Нардуган, хуҗалар,*
*Котлы, мөбарәк булсын,*
*Тормыш түгәрәк булсын.*
*Мал-туарыгыз артсын,*
*Колыннарыгыз чапсын,*
*Игеннәрегез уңсын –*
*Йомыркадай тук булсын,*
*Бәйрәмнәр гөрләп торсын.*
*Күкләр гел аяз булсын,*
*Җир йөзендә бар балалар*
*Бәхетле, таза булсын!*

ӨЧЕНЧЕ СӘХНӘ

*Әбинең өендә кич утыру күренеше. Ярымтүгәрәк ясап кызлар кулъяулыклар чигәләр, ир балалар кызларны сөйләндереп торалар. Алар янына, кызык киенеп, кунаклар керәләр, такмаклар әйтәләр.*

-Исәнмесез-саумысыз, нигә кәҗә саумыйсыз?

-Әтәчегез күкәй салган нишләп чыгып алмыйсыз!

-*Үгез сука сукалый,*

*Бозау тырма тырмалый.*

*Егет булып үскән чакта,*

*Төрле хәлләр булгалый.*

*Киенешеп кергән кунаклар барсын да күңел ачарга, җырлар җырларга өндиләр:*

-Бүген Нардуган бәйрәме! Бергә куңел ачарбыз!

-Бөтенебез җыелгачтын матур җырлар җырларбыз!

**Балалар арасыннан берсе:** Нардуган кичәсе багусыз буламы соң?

**Барысы бергә:** Булмый!

*Багу өчен инештән суны бер сүз дәшмичә алып кайтырга кирәклеген аңлаталар һәм бер парны (ир бала һәм кыз) сайлап, инешкә суга җибәрәләр.*

**1нче бала:** Кемне инешкә җибәрәбез?

**2нче бала:** Без барабыз.

**1нче бала:** Чиләк, балта, сөлге алыгыз да, бер сүз дәшмичә инешкә төшегез. Багу өчен су алып кайтыгыз.

*Инештән су алып кайтканчы, катнашучылар төрле озынлыктагы уклау белән багалар. Уклауларны чиратлашып, бер-бер артлы куеп баралар, кемнең уклавы капкадан чыгып китә, шуның теләкләре чынга аша.*

**1нче бала:** Дуслар, әйдәгез әле, уклау белән багабыз! Кемнең уклавы капкадан чыга, шуның теләге кабул була!

**Барысы да:** Әйдәгез.

*Кызлар үзләренең уклауларын идәнгә берсе артыннан берсе тоташтырып куялар.*

- Минем уклау капкадан чыкты! Миңа киләсе елда зур курчак бүләк итәләр!
- Минем уклау да капкадан чыкты! Минем теләгем кабул була!
- Ә минем уклавым чыкмады. Минем теләгем киләсе елга әле үтәлмәячәк.

*Калганнар юату сүзләре әйтәләр.*

*Инешкә киткән пар су алып кайта. Кызлар шул суга багу өчен йөзекләрен төшерәләр.*

**Алып баручы:** Инеш суы килеп җитте. Йөзекләрегезне тылсымлы инеш суына салыгыз.

*Йөзекләрне судан алып торучы кыз бер йөзекне ала һәм сорый:*

- Бу йөзекнең җыры кемдә?

**1нче бала:**

Миндә! *(Җыр җырлый, теләген белдерә.)*

-Алыгыз миңа курчак,

Алыгыз миңа курчак.

Кайтсын әле кире балачак,

Алыгыз миңа табып, күп кенә уенчыклар,

Бала булып мин калыйм һәрчак.

**Йөзекләрне судан алып торучы кыз:**
Бу йөзек кемнеке?
- Минеке!
**Балалар:**
Әй, сиңа матур курчак алып бирәләр икән.
Йөзекләрне судан алып торучы кыз. Бу йөзекнең җыры кемдә?
**2нче бала:**
Миндә!.. (*җырлый)*
- *Эх, тизрәк үссәмче,*
*Дәү кыз булып җитсәмче.*
*Ничек тизрәк үсәсе,*
*Дәү кыз булып җитәсе.*
**Йөзекләрне судан алып торучы кыз:**
Бу йөзек кемнеке?
**Йөзек хуҗасы:**
Минеке!
**Балалар:**
Әй, син мәктәпкә укырга китәсең икән...

**Йөзекләрне судан алып торучы кыз:**
Бу йөзекнең җыры кемдә?
- Миндә!..
*(Барлык йөзекләрнең дә хуҗалары табылгач, багу тәмамлана.)*
**Алып баручы:**
-Дуслар, әйдәгез әле, бер күңелле уен да уйнап алабыз. “Чабата “уены. Түгәрәккә бастык. Алып баручыны сайлыйбыз *(санамыш ярдәмендә алып баручы сайлана):*
-*Каенда – карга,*
*Имәндә – чыпчык,*
*Җирдә –елан,*
*Һавада –кош,*
*Бар, син дә оч!*
*Бу бала көй яңгыраганда түгәрәк тирәли йөри, чабатаны бер бала артына калдыра. Басып торучы бала шуны сизеп, чабатаны алып, кара-каршы йөгерәләр. Беренче булып шушы урынга йөгереп килеп басарга кирәк, кем урынсыз кала - шуңа җәза бирелә.*
**Алып баручы:**
Нинди җәза бирәбез?
**Катнашучылар:**
*Такмак җырласын!*
*Әнә килә автомобиль,*
*Төягәннәр алкалар.*
*Су салырга төшкән идем,*
*Узышалар бакалар.*
*Иртән торып тышка чыксам,*

*Тараканнар кар көри.*
*Ә чебеннәр итек киеп,*
*Көрәгән җирдә йөри.*
*Иртән торып тышка чыксам,*
*Тычканнар гулять итә.*
*Кара сыер гармун уйный,*
*Үгез танцевать итә.*
*Ике песи суга бара,*
*Көянтә-чиләк асып.*
*Ике тычкан карап кала,*
*Капка төбенә басып.*
*Ике сарык юлга чыккан,*
*Кулларында чемодан.*
*Иреннәрен буяганнар,*
*Ә битләре юмаган.*
*Киенешеп килгән кунаклар, барысын да мактый – мактый, шатланып йөриләр.*
- Матур җырлыйсыз, уйныйсыз, оста багасыз! Чын нардуганчылар икәнсез!
- Нардуган бәйрәме биюсез буламы соң?

**Барысы бергә:** Булмый!
*Кызлар үзләренең чигүле кульяулыкларын баш аркылы артка аталар һәм егетләргә шундый сүзләр әйтә*
1.- Минеке батыр булсын!
2.- Минеке матур булсын!
3. - Минеке оста булсын!
4. - Минеке акыллы булсын!
5.- Минеке бай булсын!
Егетләр үзләренә тиешле кульяулыкны тотып, аткан кыз белән парлашып бииләр.
Такмаклар әйтәләр:
Бие, бие Хәйбулла,
Биегән кеше бай була.
Биегән кеше өстәлендә,
Ипи белән май була.
Татар биюе башкарыла һәм сәхнәдән бии-бии китәләр

*Тәмам*

***Кашапова Гөлүсә Васил кызы***
*Татарстан Республикасы*

**“Кызыл алмалар”**

**Катнашалар:**

Нәзифә әби, Бибинур әби - толлар.

Әлфинә - Нәзифә әбинең оныгы, 8нче сыйныфта.

Миләүшә, Алинә - Әлфинәнең сыйныфташлары.

Фәрит - 1сыйныф укучысы.

Фәнил - күрше малае, 5-6 нчы сыйныфларда.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Вакыйга безнең көннәрдә бара.*

*Капка төбе. Утыргыч. Койма аша агачта кып-кызыл алмалар күренә. Койманың ярты ягы заманча эшләнгән, ярты ягы - читәннән. Койма буенда савытларга утыртылган чәчәкләр. “Әбиләр чуагы” җыры ишетелә. Әкрен генә Нәзифә әби чыга. Алмагачка озаклап карап тора.*

**Нәзифә әби:** Тагын көзләр җитә... Сагыш... Моң да бар бу көздә. Бүген нигәдер күңелем тыныч түгел. Нәкъ кырык бернең көзе кебек. Кызарып алмалар пешкән... Утырткан чәчәкләр дә шул урында... Чәчкәләре генә ул түгел... Соң ул чорда мондый затлы чәчәкләр бар идемени?! Унсигез яшьлек кызга ул көз бәхет китерергә тиеш иде бит. Их, шул Гитлер мәлгунь сугыш башламаса... Сәфәргалием белән чөкердәшеп яшәп яткан булыр идек менә... (*Кычкыра-кычкыра, күрше малае килеп керә.)*

**Фәнил:** Нәзифә әби! Нәзифә әби!

**Нәзифә әби:** Әү, балам, әү! Әллә оныгым кайтканмы дип торам. Күршем икән. Әйдә, әйдә, ял итеп китәрсең. Сабак уку – бик кыен эш ул.

**Фәнил:** Нәзифә әби, бүген мәктәптә “Уңыш бәйрәме” була. Кунакка чакырырга кердем, барасыңмы?

**Нәзифә әби:**(*Фәнилне сөеп*) Чакырган җиргә бармый калып булмас, барырмын, улым, барырмын.

**Фәнил:** Былтыргы кәрҗинең белән кил яме, әбекәй!

**Нәзифә әби:** Һай, хәйләкәр! Классыгыз белән хитрый булдыгыз. Тикмәгә генә чакырмыйсыз инде, беләм. И балакаем, ул кәрҗинне күптән кып-кызыл алмалар белән тутырып куйдым инде.

**Фәнил:** Нәзифә әби, әле син пешергән кабак бәлеше дә тәмле була!

**Нәзифә әби:** Һай, рәхмәт төшкерләре! Ярый соң, кабак бәлеше дә пешерермен. Үземә караганда, шуларны яратасыз шул сез *(көлеп, аркасыннан сөя.)* Улыкаем, минем оныгымны күрмәдеңме соң ?

**Фәнил:** Ә... Аларның бәйрәме иртәгә. Җырларын кабатлап калдылар. Ярый, Нәзифә әби, әзер тор, кереп алырмын!

**Нәзифә әби:** Ярый, улым, ярый, барырмын. *(Малай чыгып китә.)*Ут бөрчәсе, бигрәк ут бөрчәсе инде бу Фәнил... *(Бибинур әби күренә. Кулында бер-ике утын кисәге.)*

**Бибинур әби:** Ахирәт, кемне озаттың син? Әллә Сәфәргалиең кайттымы? *(сөйләнә-сөйләнә, утыргычка килеп утыра.)* Нигә эндәшмисең? Яратмаган булып кыланасың.

**Нәзифә әби:** И Бибинур, нәрсә дим соң? Күрше малае – Фәнил кергән.

**Бибинур әби:** Сәфәргали тавышына охшаган бит.

**Нәзифә әби:** *(кычкырыбрак)* Колагым каты дисең, үзең әллә каян ишетәсең.

**Бибинур әби:** Ник шулай кычкырасың?! Ишетәм лә мин. Катык оеттым дисеңме? И, синең сыерың бар шул. Сыерың... Катык та оетасың. Сәфәргали ашадымы соң? Сагынганмы катыкны?

**Нәзифә әби:** Соң, каян килеп чыксын Сәфәргали? Могҗиза булса гына инде... Сугыш беткәнгә дә җиде дистә ел үтеп бара... И Бибинур, "хәбәрсез югалды" дигән кәгазь алсам да – гомерем буе көтеп яшәдем Сәфәремне.

**Бибинур әби:** *(шатлана төшеп)* Менә, менә, мин дә Зарифулламны көтәм. Кайтачак ул! "Көт, кайтырмын," дип китте.

**Нәзифә әби:** И гомерләр... Яшьлекне дә, ирләрне дә харап итте ул сугыш.

**Бибинур әби:** *(елап, калтыранып).* Нәзифәкәем, синең әле Сәфәргалиеңнән улың калды. Итәк тутырып оныклар карадың. Килenең дә бик һәйбәт булды. Мин бит Зарифулла белән өч көн дә яши алмадым. Бигрәк үкенечле булды инде. Сугыш башлану белән алдылар да куйдылар җаныкаемны. *(Күз яшьләрен сөртә).*

**Нәзифә әби:** Кияүгә сорап килделәр бит үзеңне, чыкмадың... Балаларың, оныкларың булыр иде.

**Бибинур әби:** *(ачуланып)* Менә ахмак. Карт сантый. Нәрсә сөйләп утыра. Үзең нигә чыкмадың соң? Карт башың белән, оялмыйча, кияүгә чыкмадың дип утырасың! Зарифулладан башка берәү дә кирәкми миңа. Менә кайтыр әле, күрерсең... Синең белән сөйләнеп утырам тагын, кайтыйм әле, Зарифуллам кайтса, өем җылы булсын, учакны сүндермәскә кирәк. *(Сөйләнә-сөйләнә чыгып китә башлый.)*

**Нәзифә әби:** *(колагына якын килеп.)* Китми тор, оныгым кайта хәзер, бергәләп чәй эчәрбез. Мичтә ипи пешә.

**Бибинур әби:** Ишетәм бит мин, кычкырма әле шулкадәр. Нинди мунча керү ул! Көпә-көндез. Кайтыйм, кайтыйм, өйдә булмасам, Зарифуллам үпкәләр. Учакны сүндермәскә кушты... Учак сүнсә, тормыш сүнә... Өмет сүнсә, учак сүнә... *(Чыгып китә, Әлфинә килеп керә.)*

**Әлфинә:** Әбекәем, мин кайттым *(кочаклап ала.)* Сине сагынып кайттым. Бигрәк сагындым инде!

**Нәзифә әби:** И бәбкәм, мин дә сагынып көтәм бит сине. Син дә чыгып китсәң, өйнең яме калмас инде...

**Әлфинә:** И әбекәй, мин сигездә генә бит әле.

**Нәзифә әби:** Алай димә, кызым, дүрт ел үтә дә китә ул. Кызым, кереп кабак бәлеше тыгыйм әле. *(мактанган кебек)* Кунакка чакырды бит мине Фәнил.

**Әлфинә:** Бар, әбекәй, бар. Алар сине бик яраталар. Җырлар, биюләр өйрәнделәр. Рәхәтләнеп күңел ачып кайтырсың.

*Әби кереп китә. Миләүшә, Алинә үтеп баралар.*

**Миләүшә:** Әлфинә, әле һаман кайтып җитмәдеңмени? Әллә безне көтәсеңме?

**Әлфинә:** И кызлар, көне соң, көне! Әбиләр чуагы, алма исе! Өйгә керәсе дә килми.

**Алинә:** Көзге яңгырлар башланса, утырырсың капка төбендә?! Ничек йөгереп кайтканыңны да сизмәссең.

**Миләүшә:** Әлфинә, бәйрәмгә нигә синең әбиеңне дә чакырмыйбыз. Ул да тыл ветераны бит.

**Алинә:** Нәзифә әби бик шаян, кызык сүзле ул. Күңелле дә булыр.

**Әлфинә:** Кызлар, ул бәйрәмгә җыена инде. Фәнилләр чакырган. Ә без Бибинур әбигә эндәшик. Гомере буе ирен көтеп яши бит ул.

**Алинә:**Миләүшә белән без дә шулай уйлап кайта идек әле. Тик бер ягы бар бит аның: колагы бик яхшы ишетми, әллә нәрсәләр сөйли башлый.

**Миләүшә:** Ярый, аны бөтен авыл белә. Көлмиләр дә. Аннан безнең малайлар аны бик кызганалар, гел ярдәм итеп торалар. Чакырабыз, әле май бәйрәменә кадәр бик ерак, рәхәтләнеп тәмле-тәмле күчтәнәчләр белән чәй эчеп китәр.

**Әлфинә:** Сәер яклары минем әбиемнең дә бар инде ул. (*читәнгә күрсәтеп*) Менә читән койманы гына ал.... “Әнкәй, әйдә заманча таш бизәкле койма коябыз”,- ди этием. “Юк, атаң шушында читән үрде, шунда күзем төшсә, аны күргәндәй булам”,- ди әбекәй.

**Миләүшә:** *(гаҗәпләнеп)* Читән шулай озак торганмыни?!

**Алинә:** Аумагандамы?!

**Әлфинә:** Кит инде, әбекәй гел яңартып тора. Әле мине дә үрергә өйрәтте. Үземә дә ошый башлады. Чәчәкләрне уратып алам әле. Ә менә бу алмагачны күрәсезме? *(алмагач янына килеп)* Бу урында бабам сугышка киткәндә дә алмагач булган. Әнә шулай кызарып алмалары өлгергәндә, аны сугышка алганнар. Әбием шул агачның үсентеләрен карап кына үстерә.

**Миләүшә:** Нәзифә әби бәхетле. Бабаң кайтмаса да, сез бар.

**Әлфинә:** Кызлар, чакырыйк Бибинур әбине. Ичмасам ике-өч сәгать безнең белән юаныр. Бигрәк кызганыч инде. Авылның иң чибәр кызы булган бит ул. Картайгач, без дә әллә нәрсәләр сөйләп йөрербез әле.

**Миләүшә:** Зарифулласын яратканга, шулай саташа ул. “Кайтачак. Менә күрерсез”, - ди бит.

**Әлфинә:** Ярату... Аерылу... Кызлар, бигрәк моңсу бу көз.

**Миләүшә:** Сап-сары яфраклар... (*“Әбиләр чуагы”җырының беренче куплетын җырлый.)*

**Әлфинә:**Бигрәк хисле инде син, Миләүшә!

**Алинә:** (*каранып*) Әнә Фәрит кайтып килә, тагын “сайратыйк” әле үзен. Фәрит, әй Фәрит! Бу якка чык әле, бергә кайтырбыз.

*1нче сыйныфта укучы Фәрит керә.*

**Миләүшә:** Үскәнем, спортзалга күз салдыңмы?

**Фәрит:** Күзне салмадым, үз урынында бит!

**Әлфинә:** И, бигрәк тапкыр җаваплы инде син. Әле мәктәптә волейбол уйнаучылар калдымы?

**Фәрит:** Бөтен малайлар шунда әле. Рәхәтләнеп чабалар.

**Алинә:**Тугыздан Сәетов Алмаз бар идеме?

**Фәрит:** Бар инде! Иң шәбе ул йөгерә. Ник аны гына сорыйсың?

*Кызлар бер-берсенә ым кагышып кына елмаялар.*

**Миләүшә:** Ярата бит ул аны, шуңа сораштыра. Ә син кемне яратасың?

**Фәрит:** Әти белән әнине яратам! Үзебезнең апаны яратам! “5”ле куйган көнне бигрәкләр нык яратам... Аннан соң кабыклы бәрәңге яратам! Тоз сибеп ашап җибәрәсең...(*эчен уып*) Шул була торгандыр ул ярату!

**Әлфинә:** Ә кызлардан?

**Фәрит:** Ә безнең класста кызлар юк. Кемне яратырга соң?

**Алинә:** Я-я, юк-бар белән баланың башын катырмагыз. Фәнил, укудан бүген нәрсә үттегез? (*башыннан сыйпый.*)

**Фәрит:** Начар әйбер... 1941елда сугыш башланган... Муса Җәлилнең “Бүреләр” шигырен укыдык. Апа укыды инде... Без җыладык...(*борынын тарта,аннары җанлана төшеп.*) Әле җыр да керде. Әйдә, җырлап күрсәтәм. *(көй ишетелә, “Солдатта булган диләр” җырын солдатлар кебек атлап җырлый.)*

**Миләүшә:** Булдырдың!!! *(кызлар мактап алалар.)*

**Әлфинә:** Кызлар, карагыз әле нинди милицияме...солдатмы...майормы...килә ул?

**Миләүшә:** Бөтенесен дә санамадың (*көлеп.)* Полковникмы, генералмы...

*Хәрби киемнән ир- егет килеп керә.*

**Хәрби кеше:** Исәнмесез, кызлар! Басыйровлар шушы өйдә торамы?

**Әлфинә:** Әйе, ә сезгә кем кирәк соң? Мин – Басыйрова Әлфинә.

**Хәрби кеше:** Миңа Басыйрова Нәзифә апа кирәк иде.

**Әлфинә:** Минем әбекәй бит инде ул. (*Кызлар бер-берсенә карашып алалар да)*

**Миләүшә:** Ярый, Әлфинә, без киттек. Бибинур әбигә керә торабыз. *(Чыгып китәләр.)*

**Хәрби кеше:** Менә кунакларың да китте. Әбиең янына керик әле.

**Әлфинә:** Әнә үзе дә чыгып җитте. Кунакка бара ул, мәктәпкә, очрашуга. (*Нәзифә әби алма тутырылган кәрҗин,төенчек күтәреп чыга.*)

**Нәзифә әби:** Нинди солдат килгән безгә? Үтүчеме? Кунаккамы? Исәнме, балакаем!

**Хәрби кеше:** Нәзифә апа димме?.. Әбекәй димме...

**Нәзифә әби:**Улыкаем, әби диген. Олы кеше бит инде мин.

**Хәрби кеше:** Өйгә керик, әбекәй, сөйләшәсе бар.

**Нәзифә әби:** Улыкаем, мәктәпкә барам, балаларны көттерергә ярамый. Хәзер кайтып җитәрмен, өйгә кер, кунак булырсың.

**Хәрби кеше:** Ярый, әбекәй, утыр әле.

**Нәзифә әби:**Утырыплар торыйм микәнни инде... Әйдә, алайса.

**Хәрби кеше:** Кем, әбекәй, Басыйров Сәфәргали сезгә кем була?

**Нәзифә әби:** Кем булсын?! Никахлы ирем... Улымның – атасы, менә бу кызымның – бабасы. (*Елап)* Кайта гына алмады, “Хәбәрсез югалды” дигән кәгазь генә килде.

**Хәрби кеше:** Әбекәй, кайсы тирәдә сугышканын беләсезме соң? Хатларын алдыгызмы?

**Нәзифә әби:** Соңгы хаты нинди күл әле, ә Ладуга буеннан килде. Ладугы, Ладугы яныннан...

**Әлфинә:** Әбекәй, Ладога күле. “Тормыш юлы” дип йөрткәннәр.

**Хәрби кеше:** Әбекәй, менә бу йөзекне таныйсызмы?

**Нәзифә әби:** (*күзләренә якынайтып, әйләндерә-әйләндерә карый. Кинәт йөзе үзгәрә. Сәер тавыш  белән кычкырып җибәрә.)* Сәфәргалием! Аның балдагы! Менә “Нәзифә” дип язылган. Миндәгесенә (*ашыгып сала*) “Сәфәр” дип язган иде... Үзе ясаган балдаклар... Көмештән коеп ясаган балдаклары... Менә, менә...

**Хәрби кеше:** Әбекәй, борчылма, тынычлан. Мин “Кар десанты”ннан. Сугыш барган җирләрдә эзләнү эшләре алып барабыз. Менә бу гильза эчендә адрес һәм шул тирәдә генә балдак табылды. Үзем дә бу яклардан булганга, алып кайттым. Шул урында табылганнарны күмү киләсе атнаның җомгасында була. Бара алсагыз, үзем алып барам, кайтарып куям.

**Әлфинә:** Әбекәй, ишетәсеңме?! Бабай турында сөйли, ишетәсеңме?! Мин әти янына йөгердем (*йөгереп чыгып китә.*)

**Нәзифә әби:** Ничек?! Ничек күмәсез?! Шул гомер Сәфәргалием җир өстендә ятканмыни?!

**Хәрби кеше:** Әбекәй, алай ук түгел инде ул. Табигать тарафыннан күмелгәннәр инде алар. Снаряд шартлагач, балчык астында калучылар күп бит инде ул.

**Нәзифә әби:** И, күрәчәгең булгач... Төннәрен генә түгел, көндезләрен дә күземә күренә бит ул. Барам, улым, барам. Кайдан тапкан урыннарын да күрсәтерсең (*хәрби кешегә карап.*) Малаемны да алырбыз инде, улым. Әтисен гел күрмәде бит ул.

**Хәрби кеше:** Бик яхшы булыр.

**Нәзифә әби:** И Ходаем, Сәфәргалиемне күрер көннәрем дә бар икән!? Ул яткан җирне кочаклап, аны ничек сагынуымны, ничек сагынуымны сөйләр идем. Менә бу-улың, рәхмәт сиңа, улың өчен, дияр идем. (*бөгелеп төшә, койма буйлап килә.)*

**Хәрби кеше:** Әбекәй, әйдә керик, арып киттең, бугай. (*шул арда Фәнил керә*)

**Фәнил:** Нәзифә әби!Мин кереп тә җиттем. *(Ят кешегә карап)* Исәнмесез.

**Хәрби кеше:** Әбиең арып китте бит әле. Кая барырга җыенган идегез?

**Фәнил:** Мәктәпкә. Уңыш бәйрәменә. Нәзифә әби, кая алмаларыңны күтәрим.

**Хәрби кеше:** Ай, егеткәй, әбиең бара алмас, (*әби янына килеп*), әйдәгез, кереп ятып торыгыз.

**Нәзифә әби:** Юк балакаем, укучылар чакырган икән – барам. 65ел сабыр булганны бу хәбәргә бөгелеп төшәргә ярамый. Хәзер... әз генә... тын алыйк та...(*Фәнилгә карап*) Улыкаем, кил әле яныма. Менә бу кунак абыең бик зур хәбәр алып килгән. (*хәрби кешегә карап.*) Кара, балакаем, вакытың бармы? Әйдә, мәктәпкә. Нинди изге эштә булуыгызны, нәрсәләр күрүегезне балаларга да сөйләрсез. Әле минем дә башыма бер нәрсә дә барып җитмәде.

**Хәрби кеше:** Без укучылар белән гел очрашып торабыз. Тик сезнең якларда булган юк әле. Авырып китмәсәгез генә инде. Мин барырга риза.

**Нәзифә әби:** Аллага тапшырдык, балалар (*чыгып китәләр*).

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Талгын гына җыр ишетелә (Ә. Авзалова башкаруында “Син кайтмадың”җыры яңгырый. Мансур Мозаффаров көе, Сәхаб Урайский сүзләре). Бибинур Нәзифәләрнең өе янында йөри. Үрелеп, коймадан эчке якка карый.*

**Бибинур:** Кайтмаганнар... Бүген төшкә кадәр кайтып җитәләр, дигәннәр иде бит. Инде ничә тапкыр килдем... Ахирәткәемне капка төбендә үк каршы аласым килгән иде. (*Елап җибәрә. Күзләрен сөрткәләп, эскәмиягә килеп утыра.*) Сагындым үзен. Минем

сагынып кешем Зарифулла да, Нәзифә генә булды бит... И, яшь гомерләр... Яшьлеге дә үтеп китте, картлыгы да үтеп бара. (*Көй көчәя. Бибинур алъяпкычының эчке кесәсеннән фотосурәт ала. Күзләренә якын китереп карый, битенә куя. Иләп кенә сыпыра, сурәткә карап сөйли)*. И Зарифулла, син кайткан булсаң, итәк тутырып, кыз-уллар үстерер идек. Хәзер оныклар карар идек. Мин дә болай, ялгыз каз кебек, каңгырап йөрмәс идем. “Кайтам, көт”, - дип киттең дә, югалдың. Әнә, Нәзифә Сәфәрен җирләп кайта. Авыр булса да, җаны тынычлана. Ә мин? (*Йөренә, күзе урам каршысындагы солдат һәйкәленә төшә. Сәер хәлгә кереп кычкырып җибәрә.)* Зарифуллам! Кайттыңмы?! Кайткан, кайткан! Менә берәү дә ышанмады. “Бибинур хыялланган, һаман Зарифулласын көтә”, - диләр иде. (*Әле бер, әле икенче тамашачы янына килеп, фотосурәтне күрсәтә- күрсәтә сөйли.)* Карагыз, карагыз! Гел дә үзгәрмәгән. Шул ук буй-сын *(һәйкәлгә күрсәтеп),* шул ук мыек. “Каен төбендә очрашырбыз, көт кенә”, - дигән иде. Кайткан, кайткан! Мине каен төбендә көтә. (*Ашыга, кабалана, абынып егыла. Тора, тагын егыла. Үзе көлә дә, елый да.)* Зарифуллам, мин монда! (*В.Толкунова башкаруында Марк Минков көе, Игорь Шаферан сүзләренә “Әгәр сугыш булмаса”җыры кинәт кенә яңгырап китә, ахырга кадәр озата бара.)*

*Йөгереп, Әлфинә килеп керә.*

**Әлфинә:**Кем бар анда? Ярдәм итегез! Бибинур әби һәйкәл янында егылган! Ярдәм итегез! (*Йөгереп чыгып китә. Бераздан Әлфинә, Алинә, Миләүшә керәләр.)*

**Әлфинә:** И кызлар, шундый курыктым, шундый курыктым! Ярый, Филиза апа авырулар яныннан кайтып килә иде.

**Миләүшә:** Бибинур әби үлмәсен иде әле, кызлар. Әбиләр – авылның бизәге бит ул.

**Алинә:**Шифаханәгә барып эләккәч, аякка бастыралар инде аны, кайгырмагыз.

**Әлфинә:**Мескенкәем, бүген безгә әллә җиде тапкыр килде инде. Һаман әбекәйләрнең кайтуын көтте. Бигрәк дус булып яшәгәннәр бит алар. Солдат-һәйкәлне гел Зарифулласына охшатып йөри иде. Саташып, каен янына йөгергән.

**Алинә:** Күпме кайгы-хәсрәт китергән бу сугыш! Күпме ятимнәр, толлар күз яше түгелгән! Ир-егетләр таш сыннар булып кына кайтты шул.

**Миләүшә:** Сугыш дигән афәтне беркемгә дә күрергә язмасын!

*Җыр көчәя. Катнашучылар сәхнә алдына чыгып баса.*

*Тәмам*

***Гаффарова Зөлфия Рәфис кызы***
*Татарстан Республикасы*

**“Әбиләрдә кунакта!”**

**Катнашалар:** *Әби, Күрше әби, Ләйлә, Ислам, Алинә, Азат*

*Авыл өе янында җәйге бакча күренеше. Бакча уртасында түгәрәк өстәл, кошлар сайраган тавыш ишетелә. Әбинең кулында орчык.Ул утыргычта йон эрли.Үз-үзенә сөйләнә.*

**Әби:** И-и-и, тиздән оныкларым саф һава суларга, балык тотарга, комлыкта уйнарга кайтып җитәрләр. Бик сагындым инде үзләрен. Кая, машина туктаган тавыш ишетелде,

әллә кайтып та җиттеләрме балакайларым! *(Әби киртәдән үрелеп карый. Кулларына зур сумка аскан кыз белән малай килеп керәләр.)*

**Ләйлә:** Исәнме, дәү әнием!

**Ислам:** Исәнме, дәү әни! *(Иңнәренә барып сарыла.)*

**Ләйлә:** Безне көттеңме дәү әни? Сагыныплар беттек үзеңне! Су буйлары, сайрар кошлар, челтерәп аккан чишмәбез бик сагындырды.

**Әби:** Балакайларым, исән-сау гына кайтып җиттегезме? Юл бик арыткандыр, сабыйларым. Чәй кайнаттым, мунча яктым, тәмле чәк-чәкләр пешереп көттем үзегезне. Хәзер кулларымны гына юам да, чәйникне бакчага алып чыгып, бабагызның истәлеге түгәрәк өстәлдә бер тәмле итеп чәйләр эчеп алырбыз. *(Әби йөгерә-йөгерә өстәл әзерли, чәк-чәк алып чыга).*

**Ислам:** Апа, дәү әнидә интернет тотмый, җәй буе вакытны ничек уздырырбыз?

**Ләйлә:** Әти белән әни күпме әйтте инде сиңа, ташла шул телефоныңны, утырма интернетта дип. Ни бар анда?

**Ислам:** Ничек инде? Монда бит минем синнән башка рәхәтләнеп уйнарга бер дустым да юк.

**Ләйлә:** Чү, дәү әнинең кәефен төшермик. Дуслар табыла ул.

**Әби:**

*(җырлый-җырлый)*
*Их, тәмле шул чәйләребез,*
*Оныкларым янымда!*
*Ни теләсәң - шул өстәлдә*
*Шикәре дә, балы да!*

**Күрше әби:** Саулармы сез, күршеләр - иң-иң якын кешеләр.

**Барысы бергә:** Исәнмесез! Саумысыз!

**Күрше әби:** Авылыбызны сагынып кайттыгызмы, балакайларым! Әти-әниләрегез исән-саулармы?

**Ләйлә:** Яхшы гына, сезгә күп итеп сәлам юлладылар!

**Күрше әби:** Быел минем дә оныкларым, алла теләсә, җәйне минем янда уздырырга теләк белдерделәр. Шуларның кайтканнарын күнозын көтеп йөрим әле.

**Әби:** Кайтырлар-кайтырлар, исән-сау булсыннар, күршекәем. Әйдә безнең белән саф һавада бер мәтрүшкәле чәй эчеп, чәк-чәктән авыз итеп, дога кылып алыйк әле, рәхим ит.

*Урамда тавышлар ишетелә: "Бабуленька! Родная! Ты где?"*

**Күрше әби:** Абау, минекеләр түгелме соң бу? Каршы да ала алмадым үзләрен. *(Йөгерә-йөгерә чыгып китә.)*

**Әби:** *(Ләйлә белән Исламга карап.)* Ярар, балакайларым, мин тавыкларны ашатып керим, сез ял итегез. *(Әби чыгып китә.)*

**Ләйлә:** Ислам! Ташла шул телефоныңны! Әйдә әбигә булышабыз, күршеләр белән танышабыз.

**Ислам:** Тукта инде! Кая теге карачкының эшләпәсен киеп, бер селфи гына ясап алыйм әле. *(Телефонына үзен төшерә.)* Шәһәргә баргач, тел шартлатырлык, рәхәтләнеп бер мактанырлык булсын!

**Ләйлә:**Егет булачак кешегә бер дә масаю килешми! Кызлар шикелле юк-бар кыяфәттә фотога төшеп йөрмә инде, энекәш.

*Күрше кызы белән күрше малае килеп керәләр.*

**Алинә:** Привет. Мы хотим с вами познакомиться! Я - Алина, это мой братик - Азат.

**Ләйлә:** *(бик теләми генә)* Ләйлә булам!

**Ислам:**Ә мин - Ислам!

**Алинә:** Очень приятно.

**Азат:** Смотри у меня айфон, хочешь покажу?

**Ислам:** (*күзләре ялтырый)* Хочу! (*Берсен-берсе уздыра-уздыра, телефоннары турында сөйләшә-сөйләшә чыгып китәләр.*)

**Ләйлә:** Без дә бик шат.

**Алинә:** А может прогуляемся?

**Ләйлә:** *(Ислам белән Азат чыгып киткән якка карап.)* Башланды!... Алинә! Безне дәү әниебез туган телебездә сөйләшмәсәк бик нык орыша.

**Алинә:**Почему? А наша бабушка сама с нами разговаривает на русском языке.

**Ләйлә:**Ә мин менә, горурланып, үз телемдә сөйлим, үз телемдә көйлим. Тукай бабай урысча да яхшы бел, татарча да яхшы бел дигән. Бик матур, бик камил минем туган телем! *(Чиләкләр тотып, әби килеп керә.)*

**Әби:**Абау! Күрмичә дә торам! Күрше кызы безгә кунакка кергән икән бит.

**Ләйлә:**Дәү әнием, син кая җыендың?

**Әби:**Чишмәгә суга төшеп менәм әле, кызым.

**Ләйлә:** Юк, дәү әнием, мин үзем*! (Күз ачып йомганчы, Ләйлә чиләкләрне алып чыгып йөгерә.)*

**Әби:** Алинә, балам, нигә бик моңаеп басып торасың, балтаң суга төшмәгәндер бит, кызым?

**Алинә:** Вот думаю. Как я сюда попала!

**Әби:** Ничек инде суга упала? Әле Ләйлә чишмә буена барып та җитмәгәндер, кызым.

**Алинә:** Я говорю не упала, а попала.

**Әби:** *(бик уйга калып)* Папалы да инде кызым, мамалы да инде алар. Киләсе елларга кайтырлар, атна уртасында эшлиләр шул. *(Алинә әбинең сөйләгәннәренә бик аптырап карап тора)*. Алинә кызым, җиләкләрем дә өлгергәннәр, әйдәгез, авыз иттерәм үзегезгә.

**Алинә:** Спасибо! Сами кушайте!

**Әби:** Кош ите диме? *(Үз-үзенә.)* Нинди кош ите булсын? Җиләкләрем өлгерде дим, кызым. *(Әби җиләк җыйган арада, Алинә чыгып югала).* Аңламассың бу бала-чаганы. Их, ата-аналары гына гаепле балаларыбызның туган телебезне белмәвенә. *(Күрше әби керә.)*

**Күрше әби:** Ахирәткәем, минекеләрне күрмәдеңме? Сезгә кермәделәрме?

**Әби:** Әле генә монда иде алар. Ерак китмәгәннәрдер.

**Күрше әби:** Саниякәем! Оныкларым туган телебездә бер сүз дә сөйләшмиләр. Бик читенсенәм инде. Ояты гына ни тора дим *(елый).*

**Әби:** Балавыз сыгып утырыр вакыт түгел, мәҗбүр ит син аларны туган телебездә сөйләшергә. Балачакта канга сеңгәнне беркайчан да онытмаслар алар. Әле кичә генә,

белмәгән урысчаңны вата-сүтә, оныкларына нидер аңлатып утырганыңны ишеттем. Ишетмәмешкә салыш син аларны. Аңламаган булып кылан! Берәр нәрсә бик кирәксә, синнән сорап алырга үзләре өйрәнерләр. Менә күрерсең!

**Күрше әби:** Әле тагын, мин әйтәм, бала-чаганың кулында теге ни, әй исемен дә оныттым инде шунда, ниндидер айфун диме... Көннәр буе шуңа кадалып утыруларын күр. Уенчык дисәң, уенчык түгел. *(Бик гаҗәпләнеп)* Әле аның бәясе дә бер ат бәясендә ди! Кая бара бу дөнья дигәннәре?

*Көлешә-көлешә, Ислам белән Азат килеп керәләр. Шуның кадәр телефонга мавыкканнар, әбиләрен күрмиләр дә.*

**Ислам:** Әйттем бит мин сиңа, күпме генә тырышсаң да, монда интернет юк дип.

**Азат:** *(татарча.)* Ислам, алай булгач монда бер кызык та юк инде, шәһәргә кайтып китми булмас.

**Ислам:** Әллә соң, мин әйтәм, су коенырга күлгә төшәбезме? Кармакларны да алырбыз.

**Азат:** Әйдә соң булмаса, тиз генә җыенийк та. *(Чыгып йөгерәләр, телефоннарын өстәлдә онытып калдыралар.)*

**Күрше әби:** (*гаҗәпләнеп, башын тотып)* Беләләр, беләләр икән бит, белмәмешкә генә салышалар икән бит болар! Кирәкләрен бирермен үзләренә! Кычыткан белән бер кундырмый булмас! Кыланмышларын күр! Тәрбиясезләр!

**Әби:** *(телефонның берсен кулына алып.)* Бик күптәннән тотып карыйсым килгән иде бу нәрсәне, ай-яй шома нәрсә икән. Үзе ялтырый тагын. *(Иснәп карый, баскалап карый.)*

**Күрше әби:** Тыштан ялтырый, эчтән калтырый torгандыр, Саниякәем. Балачакның иң кадерле, алтын минутларын урласын әле шушы кечкенә генә пыяла кисәге. *(Телефоннарны кесәсенә салып куя).* Их, безнең балачак авыр елларга туры килсә дә, бик күңелле иде шул. Ул таудан йомырка тәгәрәтүләр, яңгыр чакыру йолалары, аулак өйләр искә төшә.

**Әби:** Искә генә төшәме соң? Төшләргә керә.

*Чишмә сулары белән Ләйлә кайтып керә, артыннан башын аска иеп, Алинә керә.*

**Ләйлә:** Чишмәбездән күп сәлам үзегезгә!

**Күрше әби:** Рәхмәт, аппагым! *(Алинәгә карап.)* Минем кызым да чишмә буенда булдымы?

**Алинә:**Әйе, дәү әни. Син безне гафу ит, без бер дә дөрес эшләмәдек! Ләйлә мине бик матур су буена алып төште, авыл белән таныштырды. Дустым буласың килсә, туган телебездә сөйләш, диде. Җәй буе авылда торсаң, әле тагын бик матур шигырьләр, җырлар өйрәтәм дип сүз бирде.

**Әби:** Рәхмәт, кызым! *(Ләйләне аркасыннан сөя.)*

*Ислам белән Азат килеп керәләр, кулларында кармак, чиләк.*

**Азат:** Ого, все здесь. *(Өстәлне карыйлар, эзләнәләр.)*

**Ләйлә:** Кая җыендыгыз болай?

**Ислам:** Безгә ияреп барыр идегез бугай.

**Алинә:** Нишләп бармаска ди, кызларга балык тоттырмыймени?

**Ислам:** Бака эләксә генә инде сезгә? Күп сөйләшеп бөтен балыкны куркытып бетерерсез.

**Азат:** Ничего себе? *(Алинәгә карап.)* Это ты?

**Алинә:**Әйе, мин!

**Әби:** Нәрсә эзлисез соң сез, улларым! Баядан бирле кабалана-кабалана.

**Ислам:** Менә шушында өстәлдә генә калдырган идек телефоннарыбызны, керүебезгә юкка чыкканнар.

**Азат:**Это наверно девочки спрятали. Дәү әни, син дә күрмәдеңме?*(онытылып)*

**Әби:** Менә, күршекәем, бик кирәк булса үзебезнең туган телебездә сорый дидем бит үзеңә. Сорады.

**Күрше әби:** Күр бу кыланчыкны! 80 яшьлек әбисен интектереп не понимаю дип сөйләнде бит көнозын. Кая микән кычыткан? Әбиләр шундый алар! *(Койма буена кычытканга үрелә.)*

**Әби:** Улым, күз нурым! Дәү әниегез белән туган телебездә генә сөйләшергә, башка кыланмаска сүз бирәсеңме? Өлкәннәрне алдарга ярамый!

**Азат:** *(елый-елый башын аска иеп.)* Гафу ит, дәү әни! Барыгыз да гафу итегез мине! Сүз бирәм! Мин башка беркайчан да алай эшләмәм!

**Әби:** Бу кыйбатлы телефоннарыгызны бик кирәк чакта гына кулланырга, үзегез белән авыл буйлап күтәреп йөрмәскә сүз бирәсезме? *(Икесенә дә карый.)*

**Азат, Ислам:** *(бергә)* Сүз бирәбез!

**Әби:** Сабыйларым, бала-чагыгызның иң кадерле минутларын истә калырлык матур итеп табигать кочагында уздырыгыз. Матур итеп ата-ана телебездә дусларыгыз белән аралашыгыз! Сез дә сакламагач, телебезне кем саклар соң?

**Күрше әби:** Туган телебезне саклагыз, яклагыз! Кайда гына яшәсәгез дә, телебез югалмасын! Теле барның иле бар!

**Ләйлә:**

*Туган телем - татар теле минем,*
*Безнең өчен иң-иң якыны!*
*Саклыйк аны, яклыйк аны, дуслар!*
*Һич тидертми язмыш салкынын!*

*Пәрдә төшә.*

***Мурзина Лилия Миннәхмәт кызы***
*Татарстан Республикасы*

## “Сөрән - сабантуйга чакыру”

*Белешмә.*

*Авылда - сөрән!!! Бу төндә авылның ник бер кешесе йокласын... Капкалар төбенә кадәр ачык, һәр ишегалдында өстәл әзерләнгән, анда тулы сый-нигъмәт. Барысы да сөрәнчеләрне көтә. Җомгага каршы төндә бала-чагалар да, карт-корылар да йокламый. Шәһәрдә яшәүче авылдашлар, эшләреннән ял алып, авылга ашкыналар.*

*Кукмара районы Күкшел авылы сабантуйга әнә шулай әзерләнә. Әлеге гореф-гадәт башка бер авылда да сакланмаган. Сөрән салу инде ничә гасыр яшәп килүен күкшелләр үзләре дә белми.*

*Сөрәнчеләрнең тарихы бик еракка барып тоташа икән. Үзләренең җырлары, такмазалары, бүләк җыю алымнары бар. Авылның бер аксакалы сөрән салуны*

*балачактан ук хәтерли. “Ата-бабалар бу йоланы безгә сеңдереп калдырган, бүген дә шулай дәвам итә. Нинди генә авыр заманнарда да аны тыя алмадылар”, – ди ул.*

*Тыеп кара син аларны, алып батырдай егетләрне... Әнә авыл башында сәгать теле нәкъ төнге берне сукканда җыелдылар. Башына түбәтәй, өстенә ап-ак күлмәк, кара чалбар, аягына киез итек кигән, биленә чигелгән сөлге бәйләгән егермеләп егет шаулатып бер биеп алды да, авылның беренче өенә юл тотты. Ни өчен аякта итек дисезме? Анысы сөрән салучының традицион аяк киеме икән. Орып яңгыр яуса да, өстән кояш кыздырып торса да, итекләрен салмый алар. Чөнки бүләк җыюны төнге бердән башлаган егетләрнең эшләре фәкать җомга көн кичкә авышканда гына тәмамлана. Ә авылны иңләп-буйлап йөргәндә, итектән дә уңайлы аяк киеме юк икән.*

*Бу бәйрәмдә иң кызыгы шунда: авыл халкы көтүе белән сыйланып йөри. Әмма сөрәнчеләрнең урыны түрдән булырга тиеш, кагыйдәне һич кенә дә бозарга ярамый.*

*Уйсу җирдә су җыела,*
*Анда казлар коена.*
*Без дә, дуслар, рәхмәт әйтик,*
*Миннәхмәт абый сыена.*

*Егетләр бу такмазаларны тигез һәм көр тавыш белән җырлый. Әлеге җырларны камил белү өчен май буе авыл башындагы “Алмагач” бакчасында репетицияләр ясыйлар. Шул ук вакытта урамны иңне-иңгә куеп, тигез атларга, ишегалдына чабышып керергә кирәк. Өй хуҗасында озак тоткарланырга ярамый. Чөнки сөрән сәгатенә сыеша алмаячаксың.*

*Егетләрнең бурычлары бик авыр. Алар җыр җырлап, бүләк җыеп кына калмый, ә авылның яшь киленнәрен, кунак кызларын барлап йөри.*

*Әйе шул, шулай шул,*

*Яшь киленнән сөлге, – дип такмаклап торучы сөрәнчеләр, бүләк алганчы, колга белән өй стенасына кагып торалар.*

*Бу авыл кызына өйләнгән яшь кияү дә игътибарсыз калмый.*

*Сөрәнче егетләр аны күккә чөя.*

*Күкшел авылында милли бәйрәмгә бер генә кеше дә битараф түгел. Кунакчыллыгын, гореф-гадәтләрен оныта башлаган барлык татар халкының күңеленә сөрән салырга кирәк бүген. Уятырга кирәк аларны...*

**Бәйрәм барышы**

**Максат:** Үзебезнең туган якка, аның тарихына, мәдәниятенә, милли мирасына хөрмәт тәрбияләү.

**Бурычлар:**1. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны милли йолалар һәм аларны үткәрү тәртибе белән таныштыру;

2. Татар халкының онытыла башлаган гореф- гадәтләренә игътибар арттыру;

3. Сөрән бәйрәмен сәхнәләштерү.

**Катнашалар:** *егетләр, кыз, Йорт хуҗасы, яшь килен, яшь кияү, кунак кызы*

*Сәхнә алдына татар халык киеменнән кыз керә.*

**Кыз:**

Иртәгә бездә сөрән, сабантуена бүләк җыю бәйрәме була. Бәйрәмгә каршы төндә яшь егетләр ак күлмәктән, түбәтәйдән, билләренә чиккән сөлге бәйләп, аякларына киез итек киеп, урам әйләнәләр. Мондый гореф - гадәтләр сакланып калган авыллар бик

сирәк ул. Әлеге бәйрәмнең кайчан башланып киткәнен белүче кеше дә юк инде. Бүләкне, минем әтием дә, бабаем да җыйган. Менә шулай буыннан буынга мирас булып күчеп килә бу матур йола. Әйдәгез, дуслар, сез дә безнең бәйрәмебезгә рәхим итегез, кадерле кунагыбыз булырсыз.

*Сәхнә кырыена табын әзерләнгән. Йорт хуҗалары бүләк җыючы егетләрне көтәләр. Егетләр җырлап керәләр.*

*Әйдә, дуслар, җырлыйк әле,*
*Барыбыз бергә чакта.*
*Озакламый таралырбыз ,*
*Төрлебез төрле якка.*
*Карлыганнар тәмле була,*
*Тәмле була каралгач.*
*Бер-беребезне сагынырбыз,*
*Чит җирләргә таралгач.*
*Яулы-ы-ы-к!*

**Хуҗа:**

*Ничек килдегез сез безгә,*
*Батмаенча диңгезгә.*
*Кадерле кунак сез безгә,*
*Ни җырлап бирим сезгә?*

**Егетләр:**

*Атлар иярләдеңме лә,*
*Тайлар йөгәнләдеңме?*
*Җыен - бәйрәм җитә диеп,*
*Бүләк әзерләдеңме?*

**Хуҗа:**

Әзерләдем, егетләр, әзерләдем, хәерле бәйрәмнәр булсын! Илләр тыныч, табыннар мул булсын. *(Колгага бүләк бәйли.)*

**1нче егет:** Сәрия апаның Сабантуй бәйрәменә биргән бүләге өчен: Ура! Ура! Ура!

**2нче егет:** Дуслар, бу елда Салават абыйның улы Инсаф өйләнде. Яшь киленнән чиккән сөлге сорыйк әле.

**Егетләр:**

*Әйдәгез, әйдәгез,*
*Әйе шул, шулай шул,*
*Яшь киленнән сөлге.*
*Әйе шул, шулай шул,*
*Яшь киленнән сөлге.*

**Яшь килен:**

*Сөлге чиктем асыл җепләр белән,*
*Йөрәк хисем салып бу җырга.*
*Насыйп булса иде бу бүләгем,*
*Мәйданнарда җиңгән батырга.*

**Егет:** Яшь киленнең Сабантуй бәйрәменә биргән бүләге өчен: Ура! Ура! Ура!

**Егетләр:** Дуслар, кияү кайда соң әле безнең, кияү кайда? *(йөгерешеп эзләп табалар.)* Яшь кияүне чөябез. *(Кияүне чөю.)*

**Хуҗа:** Егетләр, бездә кунак кызы да бар әле.

**Егетләр:**

*Оооо, кунак кыздан кульяулык!*
*Әйе шул, шулай шул,*
*Кунак кыздан кульяулык.*
*Әйе шул, шулай шул,*
*Кунак кыздан кульяулык.*

**Кунак кыз:**

*(кульяулык бирә)*
*Ефәк җепләр белән яулык чиктем,*
*Уртасында бизәк, гөл генә.*
*Җиңеп алсаң, егет, бу бүләкне,*
*Вәгъдә бирәм сиңа мәңгегә.*

**Егет:** Кунак кызның Сабантуй бәйрәменә биргән бүләге өчен: Ура! Ура! Ура!

**Егет:** Егетләр, әйдәгез, бер биеп алабыз! *(күмәк бию)*

**Хуҗа:** Егетләр, әйдәгез, табынга рәхим итегез: минем мәтрүшкәле чәйләремнән, тәмле коймакларымнан авыз итегез. *(Хуҗалар егетләрне сыйлыйлар.)*

**Егет:** Егетләр, безгә кузгалырга вакыт...

**Егетләр:**

*Уйсу җиргә су җыела,*
*Анда казлар коена.*
*Әйдә, дуслар, рәхмәт әйтик,*
*Хуҗаларның сыена.*
*Өй артындагы умартаң,*
*Ел да саен аерсын.*
*Безне шушылай хөрмәтләсәң,*
*Ел да саен баерсың.*
*Биек икән тавыгыз,*
*Каршы ява карыгыз.*
*Без килдек тә кунак булдык,*
*Инде үзегез барыгыз!*

*(Егетләр җырлап чыгып китәләр.)*

*Күкшел бит ул, Күкшел бит ул,*
*Күкшел бит зур авыл.*
*Күкшел дигән зур авылдан,*
*Аерылу бик авыр.*

***Насибуллина Миләүшә Рәүф кызы***
*Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авылы "Умырзая" балалар бакчасы тәрбиячесе*

**"Кирлемән мажаралары"**

**Катнашучылар:** Мәликә, Акбай, Мырау.

**Мәликә** (чыга һәм уртада туктала, киреләнә, битен куллары белән каплый).

Кулларымны юмыйм мин,
Ашарга да теләмим.
Көне буе елыйм мин,
Беркемне дә тыңламыйм.

Акбай белән Мырау читтән Мәликәне карап торалар, кызга карап акрын гына сөйләшәләр.

**Акбай.** Безнең Мәликә белән нәрсә булды икән? Ул елый, кычкыра, бер нәрсә эшлисе килми.

**Мырау.** Без аның белән сөйләшик, юатыйк үзен. (Мәликә янына киләләр).

**Акбай.** Бүген урамда нинди рәхәт, әйдә йөреп керик.

**Мәликә.** Мин матур көн булуын теләмим, яңгыр яусын. (елый).

**Мырау.** Яңгыр яуса, син юешләнерсең бит.

**Мәликә.** Юешләнсә ни! (елый)

**Акбай.** Ә бәлки синең ашыйсың киләдер, мин сиңа...

**Мәликә.** (сүзен бүлә). Берни дә теләмим, кәнфит тә, кәтлит тә, чәй дә, сөт тә. (Елый)

**Мырау.** Туңдырма да ашыйсың килмиме?

**Мәликә.** Туңдырма да, пирожный да! (Елый)

**Акбай.** Ә бәлки сиңа салкындыр? Яулык алып килимме?

**Мәликә.** Миңа җылы да, салкын да түгел! Миңа берни кирәк түгел! (Елый)

**Акбай.** Ә ни өчен син елыйсың да, елыйсың?

**Мәликә.** Нигә мине борчыйсыз?

Елыйсың дип сорыйсыз.
Киреләнәм күпме кирәк,
Миндә бары шул теләк.

**Акбай.** Ә бәлки син авырыйсыңдыр? А – а – а диген әле!

**Мәликә.** Бә – ә – ә!

**Мырау.** Сула әле!

**Мәликә.** Үзегез сулагыз.

**Акбай.** Хәзер без сине тыңлап карарбыз. (Төрле яклап Мәликәне колаклары белән тыңлыйлар)

**Мырау.** Булган бу.

**Акбай.** Ай – яй – яй.

**Мәликә.** Нәрсә булган соң миңа?

**Мырау.** Булган инде менә.

**Мәликә.** Нәрсә турында сөйлисез сез?

Акбай белән Мырау читкә китеп сөйләшәләр.

**Акбай.** Ярар Мәликә, булса булсын, сер итеп кенә әйтәбез сиңа.

**Мырау.** Тик берәүгә дә сөйләмә.

**Мәликә.** Берәүгә дә әйтмәм, нәрсә булганын әйтегез генә.

**Акбай.** Син Кирлемәнне йоткансың!

**Мырау.** Ул монда очып йөргән дә, син елаган вакытта авызыңа очып кергән.

**Мәликә.** Мин Кирлемәнне йоткан? Ә нинди соң ул?

**Акбай.** Ул бик усал һәм саран,

Юынмаган куркыныч хайван.

Елаганны саклап торган да,

Синең эчеңә кереп утырган.

**Мырау.** (Мәликәнең эчен күрсәтә.) Монда ул, монда! Якында гына! Исеме аның – Кирлемән.

**Акбай.** Ул синең эчеңә кереп утырган  һәм син үзең Кирлемәнгә әйләнгәнсең!

**Мәликә.** Минем Кирлемән буласым килми.

**Акбай.** Алай булса кычкырып әйт: - Минем Кирлемән буласым килми. Мин кирелекләр башка эшләмәм. Кирлемән, чыгып кит минем эчемнән!

**Мәликә.** Кирлемән буласым килми! Кирлемән чыгып кит!

**Акбай һәм Мырау**. Очып чыкты! Әнә ул, әнә ул, куыгыз аны! (Йөгерәләр, тәпиләре белән селкиләр)

**Мәликә.** Ә хәзер кая очып китте Кирлемән?

**Акбай.** Ул, авызын ачып  елап, киреләнеп утыручы балаларны эзли. Аларның авызларына очып керә дә, балалар Кирлемәнгә әйләнә.

**Мәликә.** Мин башка  еламаячакмын.

**Бергә:** Нәни дуслар сезгә әйтәбез:

Тәртипле, акыллы булыгыз!

Ә Кирлемәнне усалны,

Тизерәк еракка куыгыз!

*Тәмам*

**«МӘКТӘП СӘХНӘСЕ»**
**РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ПЬЕСАЛАР ҺӘМ ТЕМАТИК СЦЕНАРИЙЛАР БӘЙГЕСЕ**
**(АЛЬМАНАХ)**

**Редакторы:**
**Насыйбуллина Фәнзилә Габбаз кызы**

Формат 60х90 1/16. Объем 8,72 усл. печ. л.
Печать офсетная. Тираж 1230 экз. Заказ № 1334

Отпечатано в типографии ЗАО «Алгоритм+»
420044, г. Казань, пр. Ямашева, д. 36
Тел.: (843) 519-69-47
E-mail: info@algoritmplus.ru.